ИЛЬТАНИ ИЛЯЛОВА

# ФУАД ХАЛИТОВ

Истәлекләр, мәкаләләр, әңгәмәләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145.0
ББК 84 (2Рос=Тат)-4
Ф81

*Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 100 еллыгына багышлана*

Автор һәм төзүче

***Ильтани Илялова***

**Фуад Халитов:** Истәлекләр, мәкаләләр, әңгәмәләр / Авт.-төз. И.И.Илялова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. — 96 б., рәс. белән.

ISBN 5-298-04028-4

50 ел буена сәнгатькә хезмәт иткән СССРның халык артисты Фуад Халитов турындагы әлеге китапта аның тормыш юлы һәм иҗаты яктыртыла.

Рольләр, рольләр... Катлаулы иҗат юлында аларның уңайлары да, тискәреләре дә, көлкеләре дә, яшь егетләр дә, ак сакаллы картлар да бар. Болар артистның һәр рольне камиллек дәрәҗәсенә җиткереп уйнавы һәм киң диапазонлы булуы хакында сөйли.

ISBN 5-298-04028-4
© Татарстан китап нәшрияты, 2006
©Илялова И.И., авт.-төзү, 2006

ХАЛИТОВ ФУАД ИБРАҺИМ УЛЫ

Туган вакыты — 18 февраль, 1909
Туу урыны — Казан шәһәре
Белеме — урта, махсус — Татар дәүләт эшче театры каршындагы театр студиясе
Театрда эшли башлавы (Татар дәүләт Эшче театры) — 1932
Татар дәүләт академия театрында — 1937—1981
Мактаулы исемнәре — ТАССРның атказанган артисты — 1943
ТАССРның халык артисты — 1956
РСФСРның халык артисты — 1957
СССРның халык артисты — 1975
Вафат булган көне — 15 март, 1981

*Безгә аның белән эшләве җиңел. Режиссерлар фикерен, образда алар күрергә теләгән эчке холык-сыйфатларны ул тиз «тотып ала», үзенең фикере, таланты белән аларга ярдәмгә килә. Һәм еш кына үзе уйныйсы рольләргә кагылышлы булып кына калмыйча, бүтән артистлар иҗат итә торган образларга карата да әйтер сүзләре күп аның. Бу хәл тамашаны сәхнәгә куярга әзерләнгәндә генә түгел, спектакль ун-егерме тапкыр уйналгач та дәвам итә әле.*

*Марсель Сәлимҗанов*

* * *

Уйламаган булыр кендек әби,
Каптырганда аңа бал-маен,
Октябрь кояшы җылытыр дип
Чабаталы татар малаен.

Һәм бу кояш аның турысыннан
Сабыр гына көлеп үтмәде.
Иҗат нуры өстәп күкрәгенә,
Юлларына гөлләр түшәде.

Кысып йөрәгеңне очкан чакта
Җәлил, Шадрин кебек бөркетләр,
Белсәң иде, күпме артты икән
Чәчләреңдә көмеш бөртекләр.

Сәхнәгә чыкканчы Әхтәм булып,
Керфек какмый үткән ничә төн.
Шуңа Насретдинның, Исмәгыйльнең
Тамашачы аңлый кыйммәтен.

Үзе җырлы, үзе моңлы,
Горур һәм шат татар халкының
Ярты гасыр инде сәхнәсендә
Саф энҗесе син, алтыны.

Ярты гасыр узгач, барысы өчен
Рәхмәт әйтә бүген йөрәкләр.
Көчле ташкын булып һәр йөрәктән
Агыла, ургый изге теләкләр.

Иҗат чишмәң мәңге саекмасын,
Гөл сибелсен барыр юлыңа.
Чәчәк белән бергә кайнар рәхмәт хисен
Тапшырабыз синең кулыңа.

*Казан медицина училищесы директоры*
*М.И.Закирова*

***Ильтани Илялова***

**ЭШЧЕ ҺӘМ ЭШЧЕ ТЕАТРЫ**

XX гасыр башының Иске Казандагы Татар Болак арты өлеше...

Хәзерге Нариман, Татарстан, Тукай, Мәрҗани, Ф.Кәрими, Гражданская урамнары районы. Инде танылган сәүдәгәрләр — Юнысовларның, Апанаевларның таш өйләре төзелеп беткән, Шамил йорты да матур гына калкып тора. Салмак кына тормыш бара. Иртәләрен якындагы мәчетләрдән, яңа көн башлануын игълан итеп, азан тавышы яңгырый...

Бу районның Тегәрҗеп (хәзерге Гражданская) урамында Фуад исемле малай дөньяга килә. Еллар үткәч, үзенең тәрҗемәи хәлендә бу «малай» менә нәрсә язган: *«Мин, Халитов Фуад Ибраһим улы, 1909 елның 18 февралендә Казан шәһәрендә туганмын. Әтием мулла иде, аның гаиләсендә 1925 елга кадәр яшәдем. 9 яшемдә әнисез калдым һәм шул вакыттан алып абыем — укытучы Гомәр Ибраһим улы Халитов тәрбиясенә күчтем».*

Аның гаиләсе халыкның укымышлы катламына карый. Алай гына да түгел, туганнан туган абыйсы Фатих Халиди әле революцияләргә кадәр үк, татар театры туганчы ук инде, XIX гасыр ахырында, милли драматургиягә нигез салучыларның берсе булган. Ул, әлбәттә, булачак артистның рухи формалашуына зур йогынты ясаган.

Сәнгать мәсьәләләре гаиләдә «тыелган җимеш» булмый. Менә шуңа күрә Фуадның театр белән бик нык мавыгып китүе дә тиргәлми, каргалмый. Ул кечкенә вакытында ук, үзенең яшьтәшләрен җыеп, «театр уйный».

Соңрак Фуад Халитов ул елларны сагышлы елмаю белән исенә төшерә торган иде... Һәм әлеге искә алуларның барысында да күз алдына бала вакытта уйнаган спектакльләре килеп баса иде. Менә ул шәһәрнең татарлар яшәгән өлешенең яртысын диярлек кара көйдергән коточкыч янгын турында сөйли. Аларны, бар мөлкәте һәм өе янып беткән кешеләр буларак, уттан сакланып калган мәчеткә урнаштырганнарын исенә төшерә. Хәтта менә шундый вазгыятьтә дә аның башына ниндидер спектакль уйнаулар килә торган булган. Аннан соң инде татар һәм рус мәктәпләре... *«Монда инде без ниндидер юк-бар әйбер куймый торган идек, ә Островскийның «Фәкыйрьлек — кимчелек түгел» әсәрен куя идек,* — дип сөйли актер. — *Спектакльләр түләүле була торган иде, ә алардан кергән акчага урам балаларына киемнәр сатып ала идек...»*

Октябрь инкыйлабы башланганда, аңа 8 яшь була. Ул совет власте елларында үсә һәм шәхес буларак формалаша, үз иленең актив, чын күңелдән бирелгән ватанпәрвәре була.

1920—1930 елларда, бөтен Советлар иленең какшамас төсле тоелган гөмбәзләре җимерелгәндә, ул искиткеч ярсулы һәм ялкынлы, дәртле чор кичерә. Бу әлегәчә беркайда ишетелмәгән һәм күрелмәгән хезмәт дәрте, каһарманлык һәм дистәләрчә еллар үткәч кенә ачыкланган якты киләчәккә беркатлы ышану вакыты иде.

Әмма ләкин кеше һәрвакытта үз чорының җимеше булып кала. Шуңа күрә Халитов та тулысынча әлеге чорга бирелә һәм соңыннан үзенең урынын театрда таба.

Ләкин һөнәри сәнгатькә килгәнгә кадәр, ул күптөрле белгечлекләр буенча эшләп карый, тормышта үз урынын эзли. *«Минем хезмәти тормышым,* — дип яза Халитов үзенең тәрҗемәи хәлендә, — *1928 елда Казанның М.Вахитов исемендәге сабын кайнату заводында кара эшче булып башланды... 1929 елда совет эшенә күчтем. ТАССРның Норлат районында крестьян җәмгыятьләренең район комитеты сәркатибе булып эшләдем, бер үк вакытта район китапханәсе мөдире дә булдым һәм район драмтүгәрәгенә җитәкчелек иттем. 1930 елда ВКП(б)ның Норлат райкомы каршындагы алты айлык ярдәм партия мәктәбен тәмамладым. Шул ук елда, Казанга әйләнеп кайткач, 1 нче санлы мех фабрикасы каршындагы мехчылар курсына укырга кердем. Бу курсларны тәмамлагач, фабрикада тиренең эчке ягындагы йомшак ярысын салдыручы булып эшли башладым. 1932 елда Кызыл Армия сафларына чакырылдым...»* Армия хезмәтен үткәч, ниһаять, ул тормышын театр сәнгате белән бәйли.

Балалык һәм үсмерлек вакытын белә башлаганнан алып, ул үзен башта күптөрле үзешчән түгәрәкләрдә, аннан соң спектакльләрдә катнашучы буларак күрә. Фуад әнә шул — театрга ташкын булып һәм аның яңа тарихын булдырырга дип килеп кергән 1920—1930 еллардагы унсигез-егерме яшьлек егетләр һәм кызлар сафында була. Әлеге буын тәрбияне иң элек тормыш мәктәбендә ала, ләкин сәхнә белем үзләштерү буенча зур эш алып баруны таләп итә, һәм яшьләр карт остазлардан үзләренең беренче сүзләрен әйтергә өйрәнә. Алар арасында төрле дәрәҗәдәге талант ияләре һәм сәнгатькә төрле эзләнү юллары белән килүче аерым шәхесләр бар иде, ләкин аларның барысы өчен дә бер үк бурыч, бер үк максатка омтылыш хас булды.

Яшь Халитов очраткан остазларның иң беренчесе Шакир Шамильский була. Аның алдында табынуны, аңа карата дулкынландыргыч мөнәсәбәтен актер үзенең бөтен гомере буена дәвам итә. Аны ук ул үзенең укытучысы итеп саный. Ш.Шамильскийның турыдан-туры җитәкчелегендә 1928

елда М.Вахитов исемендәге заводтагы үзешчән түгәрәк әгъзалары Б.Лавреневның «Разлом» әсәрен сәхнәләштерәләр, Фуад монда Годунны уйный, һәм, табигый ки, моңа кадәр күптән түгел Академия театрында шул ук рольне уйнаган Ш.Шамильскийның ярдәме әйтеп бетергесез зур була.

Көндезләрен Фуад заводта вагонеткада эшли, ә кичләрен репетицияләр, үзешчән түгәрәктәге спектакльләр, осталык буенча дәресләр. Буш кичләрендә яшь эшче егет Академия театрына йөгерә һәм халык күренешләрендә сәхнәгә чыга, шәһәр буйлап афишалар ябыштырып йөри. Ул тулы канлы тормыш белән яши. Бераз гына буш вакыты булса, хәтта еш кына йокы исәбенә дә, ул китап укырга, бигрәк тә театр сәнгатенә багышланган әсәрләр укырга керешә. Бу очракта да аңа армый-талмый үзлегеннән белем күтәрү, үз-үзен камилләштерү белән шөгыльләнүче һәм театрга гына түгел, ә әдәбиятка да гашыйк булган чын зыялы кеше — Ш.Шамильскийның йогынтысы зур була.

1920 еллар ахырында үзешчән сәнгать түгәрәге әгъзалары ул вакытларда киң танылган пьесаларны — К.Тинчуринның «Американ», Ш.Камалның «Ут» әсәрләрен сәхнәләштерәләр һәм шулар белән үзләренең завод эшчеләре алдында чыгышлар ясыйлар.

Бу елларда ул үзенең киләчәге турында бик еш уйлана башлый. Аңа инде 20 яшь тула. Тормышта әлегә кадәр чынлап торып билгеле бер һөнәре юк... Әлбәттә, үзешчән сәнгатьнең булуы бик яхшы. Сәнгатькә бетмәс-төкәнмәс мәхәббәте бар... Әмма ләкин болар барысы да ныклы түгел, җитди түгел. Тормыш сине, якоре өзелгән кораб кебек, бер яктан икенче якка ташлый. Егетебез төптән, бик тирәннән уйлый һәм, ниһаять, хәл итә — укырга кирәк!.. Аның хәтеренә Бондюгка йөзүче пароходта булып узган һәм җуелмас тәэсир калдырган очраклы гына очрашу килеп төшә. Укуның кирәклеге турында шулкадәр күп сүз барган — Н.К.Крупская һәм Мария Ильинична Ульянова белән очрашу...

Шулай итеп, ул «укырга кирәк!» дигән карарга килә. 1920 елларда Татарстан башкаласында инде театр техникумы эшли башлый. Яшь егет шунда укырга керергә хыяллана. Ләкин, аһ, хыяллар тормышка ашмый. Беренче курска кабул итүләр булмый, ә икенче курска аны алмыйлар. Фуадның кәефе төшенке. Әмма ләкин яшәргә дә кирәк, кул кушырып утырып булмый. Менә шул вакытта инде ул мехкомбинатның 6 айлык мехчылар курсына укырга кереп, соңыннан шунда ук эшли дә башлый. Әгәр дә без бер генә минутка аның сәнгатькә хәтере калуын һәм аны ташлавын күз алдына китереп карасак, бик нык ялгышыр идек. Фуад комбинатта эшкә керешү белән үк, монда эшләүче мехчылар Эшче театрында катнашучы булып китә. Бу театрда ул коллективның әдәби эшләрен алып баручы Галиәсгар Камал белән якыннан таныша. Г.Камал бу труппа өчен махсус өч пәрдәлек «Күрәзәлек итү» исемле пьесасын иҗат итә, мехкомбинат тормышыннан скетчлар, сәхнә күренешләре яза.

Бу театр ярым һөнәри театр була. Анда, үзешчәннәр белән янәшә торып, инде һөнәри осталыгы булган актерлар да эшли. Театр техникумын тәмамлаганнан соң, анда М.Миңлебаева һәм Г.Газизовны эшкә билгелиләр. Очрашып, бер-берсен яратып, ике яшь кешенең — Ф.Халитов белән М.Миңлебаеваның өйләнешүләренә дә нәкъ менә шул театр сәбәпче була. Бәлки, яшьләрнең бер-берсенә тартылуына аларның икесенең дә бик яшьли әнисез — ятим калулары да, иркәләү, назлау, яратудан мәхрүм булулары да сәбәпче булгандыр. Аларның гаиләсе сирәк очрый торган тату һәм нык, дус гаилә иде. 1942 елның 18 маенда аларның бердәнбер уллары Рөстәм тугач, бу гаилә тагын да ныгый, балалары өчен алар җаннарын бирергә әзер торалар...

Әлбәттә, барлык актерлар кебек үк, бу гаилә дә матди кысынкылыкта яши. Алар күпмедер вакыт Тегәрҗеп урамында яшәүләрен дәвам итәләр, аннан соң кешеләр почмагында яшәп, чегәннәр кебек бер өйдән икенче өйгә күченеп йөриләр, һәм, ниһаять, аларга Островский урамының 6 нчы йортындагы актерлар тулай торагында бер кечкенә бүлмә бирәләр... Һәм күп еллар узгач кына, 1955 елда, Халитовка Мәктәп тыкрыгы (Школьный переулок) урамында зур, яхшы фатир бирделәр. Ул анда үзенең соңгы көннәренә кадәр яшәде...

Көн кадагына сугып язылган кечкенә пьесаларда катнашу Халитовта соңыннан аның иҗатында үзеннән уйлап чыгарып эш итүгә китереп җиткерүче аерым шәхес таланты сыйфатын тәрбияли. Нәкъ менә бүгенге көн өчен, ягъни бүгенге заман өчен кирәкле булган нәрсәне эләктереп алу осталыгын тәрбияли. Мөгаен, нәкъ менә шушы — бүгенге тормышка булган мәхәббәте, аны аңлавы — Халитовны эстрадага алып килгәндер. Иҗади рухы белән якын булган актер Мамай (М.Зәйнуллин) белән бергәләп 1930 еллар башында алар бик яратылган һәм танылган дуэт оештыралар. Татар язучысы Фатих Хөсни болай дип яза: «Халитов белән Мамай, ике яшь егет, ике дус, кайчандыр бөтен республика сәхнәләре буйлап гастрольләр оештырып йөргәннәр иде. Бу ике егетне эшче клубларында, кызыл почмакларда, кыр станнарында, ашханәләрендә, кыскасы, җырларга, биергә, такмак әйтергә мөмкин булган һәр урында очратып була иде» (Хөсни Ф. Безнең яшь артистлар. Кызыл Татарстан, 9 февраль, 1941).

Менә бу — сәхнәдә бөтен нәрсәне эшли алу, җырлау, бию, уку, акробатик номерлар ясау, тамашачының игътибарын яулап алу, рампа аркылы аның белән элемтә урнаштыру, син үзең эшләгән эшкә аны да ышандыра алу — Фуадның алга таба булган иҗади тормышы өчен бик яхшы алшарт-

лар тудыралар. Мөгаен, нәкъ менә шушы елларда аның талантының бик күп төрле кырларына нигез салынгандыр. Берсүзсез, эстрадада эшләү Халитовка соңыннан үзенең гәүдәсен, хәрәкәтләрен, мимикасын бик төгәл һәм ачык итеп эшләтә алырга өйрәтте. Совет театры тарихыннан без И.Ильинский, В.Марецкая, С.Бирман, М.Бабанова кебек эксцентрика һәм гротеск мәктәбен үткән шактый күп мәшһүр актерларны беләбез.

...Фуадның М.Вахитов исемендәге заводта үзешчән сәнгать түгәрәге әгъзасы, мехкомбинат театрының актив әгъзасы булуы, аларның Мамай белән шундый зур уңыш казанулары бик яхшы. Боларның барысы да бик әйбәт... Әмма ләкин шул ук вакытта егеттә барыбер ниндидер үз-үзе белән канәгатьсезлек хисе яшәп килә. Әлеге канәгатьсезлек хисе аны бер яктан икенче якка ташлый. Һәм аңарда яңадан уку турында уй калкып чыга. Шуңа күрә армиядән соң, — ә ул анда озак булмый, — Эшче һөнәри театры җитәкчесе Ә.Мәҗитнең үтенече буенча Халитовны Казанга чакыртып алалар. Ләкин монда, ниһаять, чын һөнәри театрда эшли башлыйсы урынга тагын юлга җыена. Ул Ленинградка китә һәм... политехника институтына укырга керә. Укый башлый. Әмма ләкин бер тапкыр сәхнә арты һавасын сулаган, сәхнәгә гашыйк булган кеше икенче эш белән шөгыльләнә аламы соң? Юк, әлбәттә. Һәм Халитов институтны ташлый да, Ленинградтан табан ялтыратып, яңадан Казанга кайта. Ләкин ул тагын бер урында гына утырып тора алмый. 1933 елның көзендә Фуад Мәскәүгә, ГИТИСның актерлык факультетына укырга керә. Ниһаять, яшь егетнең хыялы тормышка ашкан кебек. Ул укый. Һәм театр югары уку йортында укый. Ләкин тагын, бусында бөтенләй акылга сыймаслык итеп, Халитов Казанга кайтып китә. Әлеге кайтуының сәбәбе гаилә хәлләре була. Аның каравы шуның белән Фуадның бәргәләнүләре, сәяхәтләре тәмамлана. Ул Эшче театрына әйләнеп кайта, Ә.Мәҗит җитәкләгән ике еллык театр студиясен тәмамлый. Шул вакыттан алып Фуад Халитов ныгытып Эшче театрының актеры булып китә, шул вакыттан башлап һәм бөтен гомере буена ул театр белән арасын бер минутка да өзми һәм аңа башта «ТАССРның атказанган артисты», аннан соң «ТАССРның халык артисты» дигән исем бирелә. Һәм, ниһаять, РСФСРның, СССРның халык артисты булган, бөтен республика һәм бөтен илебез яхшы белгән һәм яраткан Фуад Халитов булып үсә...

1934 елда Фуад Халитов театр белән бергәләп Мәскәүгә алты айлык практикага китә. Режиссеры данлыклы А.Д.Попов булган Революция театрына беркетелә. Драматургиядә Н.Погодинның күренүе, совет театрында хәзерге заман тематикасының барлыкка килүе әлеге режиссерның исеме белән бәйле. «Чынбарлыкның яңа тукымаларына игътибар белән карый торган рәссамның текәлеп караучы күзе, — дип яза А.Попов, — дөрес иҗади карашның нигезе» (Н.Зорканың «Творчество А.Д.Попова» исемле китабыннан алынган өзек. М., «Искусство» нәшр., 1954, 127 б.). Бу сүзләр режиссерның үз иҗатына хас. Халитовның әлеге остазга килеп эләгүе аның иҗатында яңа күтәрелеш була. Чөнки әле Мәскәүгә килгәнче бик үк ачык та булып бетмәгән замандаш образын тудыру, заманча уйнау алымы турында хыялланучы яшь актерның омтылышлары А.Д.Попов янында репетицияләрдә үткәргән вакыт эчендә ахырына кадәр формалашып бетә. Һәм шуңа күрә, татар театрының әйдәп баручы актерыннан аның укытучылары турында сорагач, ул татар сәхнәсе корифейлары белән беррәттән иң беренчеләрдән әлеге атаклы режиссерның исемен атый.

Революция театрында булганда, яшь актерларга Н.Погодинның «Кичәдән соң» пьесасы буенча куелган спектакль репетициясенең һәм сәхнәгә чыгарылуының шаһитлары булырга туры килә. Алар гади совет кешеләренең яңа тормышта чын каһарман образларын тудырырга өйрәнәләр.

Яшь татар актерлары репетицияләрдә тын алырга куркып утыралар, мөмкин кадәр күбрәк нәрсәгә өйрәнергә, А.Д.Попов үзе белән алып килгән чын заманча, яңа нәрсәнең эченә кереп аңларга тырышалар.

Фуад ул вакыттагы Революция театры актеры булган гадәттән тыш талантлы В.Белокуровның уенына гашыйк була. Аның ничек репетиция ясаганын һәм уйнаганын күреп, ул кайсыбер вакытларда өметсезлеккә бирелеп китә. Үзенә, үз көченә һәм мөмкинлегенә ышанмау хисләре калкып чыга. Үзенең башкалада булган чакларын ничектер бер искә алып утырганда, Халитов бигрәк тә МХАТның беренче класслы спектакльләрен караганнан соң бик нык курку хисе төшкәнен сөйләгән иде. Ул вакытта В.Качалов, И.Москвин, Н.Хмелев, А.Тарасова, М.Степанова, О.Книппер-Чехова, Н.Баталов (барысын да санап бетерү дә мөмкин түгел) кебек гаҗәеп артистларның, данлыклы йолдызлар төркеменең үсешләрендә иң югары ноктага җиткән чаклары була. Татар актерларының үсешенә башка данлыклы театрларның спектакльләре дә зур йогынты ясый. А.Попов, танылган режиссер-теоретик В.Сахновский, Е.Вахтангов исемендәге театр актеры, режиссеры Р.Симонов, сәхнә теле буенча профессор Пряничников дәресләрендә шөгыльләнүләр «актерлык осталыгы» дип аталган бинаның диварларын тагын да биегрәк итеп күтәрү өчен ныклы нигез булалар.

Ә Мясницкаядагы тулай торакта торганда, яшь татар артистлары арасында күпме бәхәсләр, сөйләшүләр булып узган? Спектакльләрдән соң төн уртасы узганчы сөйләшеп утырулар вакытында мавыктыргыч әңгәмәләр белән инде үзәккә үткән ачлыкны да сизмиләр, дөресрәге, аны онытып торалар. Ләкин берәү дә шыңшып зарланмый да, көйсезләнми дә...

Алар театрның, эстрададан яңгыраган тере, дәртләндергеч сүзнең әһәмиятен аңлыйлар. Мәскәүдә стажировка узучы Эшче театры уку белән генә шөгыльләнми, ә үзе дә татар аудиториясе алдында чыгышлар ясый. Труппа репертуарында В.Билль-Белоцерковскийның «Кояш цехы», Ә.Мәҗитнең «Хупҗамал», М.Фәйзинең «Галиябану», Ф.Вольфның «Катарродан матрослар», Г.Кутуйның «Шатлык җыры» кебек төрле-төрле әсәрләр була.

Бу спектакльләрдән тыш, татар артистлары эшчеләр алдында агитплакат, скетчлар кебек көн кадагына сугып язылган кечкенә формадагы әсәрләр белән чыгышлар ясыйлар. Алар Мытищида, Подольскида, Автозаводта һәм Мәскәүнең үзәгендә, Чайковский исемендәге залда уйныйлар. Татар тамашачысы булган бөтен җирдә булалар.

1930 елларда татар артистларын кырыс тайгалы Уралда, эссе Төркестанда, атаклы Магнитка төзелешендә, Каспий диңгезе балыкчылары янында, Россия үзәгендә, Себердә, Казакъстанда, Әстерханда, Мәскәүдә, Ленинградта, СССРның зур һәм кечкенә шәһәр һәм авылларында күрергә мөмкин була.

Фуад Халитов та әлеге артистларның алгы сафында. Ул кемне генә уйнаса да — Ф.Вольфның «Катарродан матрослар» пьесасындагы боцман Франц Рашмы, А.Островскийның «Гаепсездән гаепleләр» драмасыннан Незнамовмы, кечкенә формадагы әсәрләрне укучы-декламатормы — актер бөтен җирдә бүгенге тамашачыга кирәкле нәрсәне таба иде.

Әйтик, Мамай белән берлектә әзерләнгән һәм Чайковский залында чыгыш ясаган «Мәдәниятсез мәдәниятчеләр» программасында актерлар төрле мәдәният идарәләренә кереп оялаган бюрократлардан ачы, усал һәм үткен итеп көләләр, мәдәният мәсьәләләрендәге җитешсезлекләрне, кайбер хезмәткәрләренең наданлыкларын, көлкегә калдырып, бөтен халыкка күрсәтәләр. Көчле алкышлар, тамашачыларның бик җылы кабул итүләре һәр очракта сайлап алынган материалның урынлы булуын һәм бик яхшы башкарылганлыгын сөйли.

Мәскәүдән әйләнеп кайткач, Эшче театры Дәүләт Эшче театры дип үзгәртелә. Берничә елдан соң бу коллективның ничек барлыкка килүе турында газетада болай язып чыгалар: «1931 елда туптуры производстводан килгән алты сәнгать сөюче Мәҗитов җитәкчелегендә эшче клубларда, төзелеш мәйданнарында тере газета, скетчлар һәм башка эстрада номерлары белән чыгышлар ясыйлар. Әлеге гади генә труппаның бар байлыгы гармун була.

Менә шулай итеп, Татар дәүләт Эшче театры барлыкка килә. Алты ел эчендә театр 2 миллион тамашачыга хезмәт күрсәтә. 1800 спектакль куя.

Узган җәйдә театр беренче тапкыр Мольерның, Островскийның, Горькийның классик пьесаларын куя башлады» (Сиротинская Н. От скетчей до классических пьес. Красная Татария, 28 февраля 1937).

Фуад Халитов республика тамашачыларына классиканы уйный башлап хезмәт күрсәтүчеләр арасында әлеге алты егетнең берсе була.

Актер ул вакытларда авылларда чыгыш ясаулары ничек авыр булуын искә ала иде. Ничек кирәк алай үзгәртеп җиһазланган зур өй, кечкенә генә сәхнә. Актерлар, алар ук администраторлар да, өйдән өйгә бөтен авыл буенча йөреп, авыл халкын спектакльгә килергә үгетләп, агитацияләп чыгалар. Инде сөйләшеп, килешеп кенә беткән кебек булалар, шул вакытта ниндидер карт гаилә башлыгы килеп чыга да театр сөючеләрне, чәчләреннән сөйрәгән кебек иттереп, өенә алып кереп китә һәм актерның борын төбендә шапылдатып ишеген ябып куя. Шәригать һәм бабайлар законы әле бу көчкә ия булган авылларда эшләве бик авыр була. Шуңа күрә, кагыйдә буларак, кечкенә генә тамаша залы беренче ике-өч рәттә генә тулы була. Ләкин шушы эш тә алга китеш санала.

Халитов актерларның ничек итеп елның теләсә кайсы вакытында, саз ерып, салкында туңып, яңгырда юешләнеп, эсседә пешеп, бөтен кирәк-яракларын үз җилкәләренә күтәреп, кайвакытта арбада, ә кайвакытта җәяүләп бер авылдан икенчесенә күчеп йөрүләрен дә искә ала иде. Бу артистлар, әлбәттә, үз эшләренә чиксез бирелгән фидакярләр була. Бу вакыйгаларга инде дистәләрчә еллар үткәч, дәрәҗәле исемнәр алган, күп хезмәт күрсәтеп хөрмәтләнгән актерлар, артистларның автобус бик яхшы җылытылмый дип канәгатьсезлек белдерүләрен ишетсә, ул һәрвакыт югарыда телгә алынган күчеп йөрүләрне искә ала иде.

Шәһәрләрдә, бигрәк тә Казанда уйнарга чагыштыргысыз җиңелрәк була, әлбәттә. Биредә Эшче театрының үз бинасы бар. Башта ул Пассаж бинасында урнашкан иде. Аннары аларга элеккеге мәчет бинасын бүлеп бирәләр. Ул мәчет — элеккеге Печән базары мәчете, хәзерге Мәскәү урамы белән Париж Коммунасы урамнары чатында урнашкан Нурулла мәчете булып чыга. Анда 500 — 600 кешелек тамаша залы, ул чорлар өчен яхшы гына сәхнә дә ясап куялар.

Эшче театры, аның режиссерлары Ә.Мәҗит, С.Вәлиев-Сульва репертуарны төрлеләндерергә тырышалар. Ф.Вольф, А.Островскийның афишада аталган пьесаларыннан башка К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», Ш.Камалның «Ут» әсәрләре дә куела.

Ф.Халитовның бу театрдагы иң беренче зур роле «Гаепсездән гаепләләр» драмасыннан Гриша Незнамов образы була. Табигый ки, Халитовның бу рольне уйнавын күккә чөеп мактап булмый.

Яшь актерның иҗатына пафос белән сөйләү хас була, бигрәк тә монологларда кирәгеннән артык мелодраматизм күренешләре чагыла. Мөгаен, бу мантыйклы да булгандыр, чөнки Незнамов роле гади генә түгел, ә Халитов мондый эш белән беренче тапкыр очраша. Жанрның асылыннан чыгучы, таләпләре бераз башкачарак булган милли әсәрләрдә, агит пьесаларда уйнарга өйрәнгән актерга авырлык шунда килеп чыга, аңа үзенең шәхси үзенчәлегендә яңа чикләр табарга кирәк. Ләкин барыбер кайчан да булса классика белән очрашу булырга тиеш иде. Шуңа күрә, Незнамов турында сөйләгәндә, әле яшь актердан тәмамланган, тулы образ таләп итәргә дә ярамый иде.

Ф.Халитов үзенең беренче эшләрендә эзләнә, сынап карый... Нәрсәдер килеп чыга, нәрсәдер юк... Тәҗрибә аз, бигрәк тә аның тәҗрибәсе, аннан соң, сер түгел бит, совет театрында 1920 еллар сәхнә сәнгатендә яңа тәэсирле чаралар эзләү билгесе астында үтә. Сәнгать театрында да, Мейерхольд, вахтанговчылар һәм Таһиров театрларында да эзләнүләр, милли театрларда да эзләнүләр. Бу эзләнү юлларында, табигый ки, тоташ җиңүләр генә булмый. Актерлык осталыгы турында бәхәсләр бара. Кайбер режиссерлар, театрда өстенлек итү роле фәкать режиссер кулында гына булырга тиеш, ә актерлар шәхси үзлекләрен югалткан һәм курчак-марионеткаларга әйләнеп калырга тиешләр, диләр. Ә актерлар мондый фикерләр белән килешмиләр.

...Дәүләт Эшче театры актерлары үз тамашачылары күңелендә бик күп яхшылык орлыклары чәчәләр. Әмма 1937 елда бу театрны ябу турында карар кабул ителә. Актерлар башка театрларга күчереләләр. Ф.Халитов, М.Миңлебаева, М.Гафуров Академия театрына алыналар.

Шушы дәвердә Фуад Халитов тормышының һәм иҗатының беренче чоры төгәлләнә кебек.

Иҗатының беренче ун елы аның өчен нәрсә булган соң?.. Беренче карашка, аның ниндидер бер ныклы үзәге дә юк кебек... Егет бер яктан икенче якка ташлана, бер һөнәрдән икенчесенә — әле химкомбинат, әле мехкомбинат, әле Норлат йә булмаса политехник институт. Ләкин шуңа да карамастан, әлеге еллар тышкы яктан үзгәрүчән тормышта иң төп эчтәлек булган. Ул үзеңнең бөтен барлыгың белән театрны яратудан тора. Ул кайда гына, кем генә булып эшләсә дә, завод, армия, колхоз үзешчән театр коллективлары сәхнәсендәме, эстрада сәхнәсендәме, ахыр чиктә һөнәри театр сәхнәсендәме, нәкъ менә шул ярату аны һәрвакытта шунда алып килә. Һәм һәрбер җирдә Халитов актерлык фәне серләренә төшенә, акыл һәм тәҗрибә туплый.

Тырышып-тырмашып, ул сабыр гына белем ала, чөнки аларның киләчәктә кирәк булачагын белә, аңлый.

Шуңа күрә танылган актер иҗатының башлангыч чорын эзләнү һәм тормышта, сәнгатьтә үз урынын, үз йөзен табу вакыты дип атарга мөмкин булыр иде. Мөгаен, ул елларда бусы иң мөһиме булгандыр. Әмма ләкин әлеге факт моннан соңгы елларда, үзенең кыйбласын билгеләгәч, Халитов тынычланып калган, бернәрсә дә эзләмәгән, ә иҗатының җимешләрен җыеп яткан дигән сүз түгел. Юк, һич юк. Мөгаен, әгәр дә иҗади тынычланса, эзләнүдән, уйланудан, тормыштан өйрәнүдән тукталса, ул Халитов булмас иде. Ул 50—60—70 яшьләрдә дә тынгысыз, һәрвакытта эзләнүчән кеше булды. Аны һәрвакыт бер үк фикер — заманнан артта калмаска иде, иске карашлы кешегә әйләнмәскә иде дигән фикер борчый иде. Һәм, мөгаен, нәкъ менә шуңа күрә дә ул иң заманча актерларның берсе булып калгандыр да.

Ф.Халитов Татарстанның халык артисткасы булган Мәрзия Миңлебаевага өйләнүе белән дә бәхетле булды. Ул талантлы актриса буларак танылган, бик күп төрле рольләрдә — җырлы Галиябану, эчкерсез Рәйсә, яшь, трагик Джульетта, дәртле, шаян Варвара, Фаншетта кебек рольләрдән алып характерлы, тормышчан, гади Саимә, Аграфена Кондратьевна кебек рольләргә кадәр зур уңыш белән уйный. Ул үзенең иренең фикердәше иде. Алар сәхнәдә дә еш кына партнерлар булып уйнадылар. Ул шулай ук җаны-тәне белән театрын яратты, туган коллективының шатлыклары һәм кайгылары белән яшәде. Ул һәрвакыт иренә, рольләре өстендә эшләгәндә, киңәшләрен бирде. Ә Халитов үз гомерендә бик күп рольләр уйнады.

## Г.КАМАЛ ТЕАТРЫНДА

1937 елда Халитов инде ул вакытта ук танылган Татар академия театрының бусагасын атлап керә. Нәкъ менә шунда киң иҗат диапазонлы остаз булып үсеп җитә. Аның турында ул — ялкынлы дәрткә ия булган кеше дип кенә әйтеп булмый... Аның тарафыннан тудырылган образлар шулкадәр төрлеләр һәм бер-беренә бөтенләй капма-каршылар. Ул каһарман рольләрен дә, характерлыларын да, баш рольләрне дә, эпизодикларын да, уңай рольләрне дә, тискәреләрен дә беркайчан да баш тартмыйча иҗат итә. Нәтиҗәдә менә шундый күп планлы актер булып өлгерә.

Халитовның артистлык язмышы өчен тагын бер нәрсә бик мөһим, аның өчен «күчү яше», ягъни баштан яшьләрне уйнаган актер соңыннан өлкән яшьтәгеләрне һәм картларны уйнарга күчә торган театраль төшенчә булмый. Халитов бит яшьтән картларны да, яшьләрне дә уйнаган. Шуңа күрә дә

инде күп артистларга хас булган «каһарманнар» рольләреннән картлар һәм «характерлы» дип аталучы рольләргә күчә торган, яманаты чыккан авыртулы «күчү яше» аңа кагылмый.

Рольләр, рольләр, рольләр... Алар берничә йөзгә тула. Менә алар, калейдоскоптагы кебек, күз алдында күренеп-күренеп китәләр. Бик күп төрлеләр — картлар һәм яшьләр, яхшылар һәм усаллар, нык холыклылар һәм йомшаклар...

Әгәр дә берәр кайчан могҗиза булып, артист тарафыннан театрда тудырылган дистәләрчә образлар терелсә, алар җыелган тамашачылар залы матур, шау-шулы, төрле төстәге халык төркеме белән тулыр иде. Биредә төрле илләрнең, төрле заманнарның, төрле яшьтәге төрле һөнәр ияләре, төрле белемле һәм төрле холыклы кешеләр булыр иде. Утыргычларның беренче рәтләрен халык бәхете өчен көрәшүчеләр, гаделлек өчен курку белмәс көрәшчеләр алыр иде... Алар артында патша Россиясе шартларында яшәп, авырлыклар алдында үзләренең башларын имәгән, үзләренең җаннарында горурлыкларын һәм кешелек дәрәҗәләрен саклап калган кешеләр утырыр иде... шунда ук йомшак холыклы һәм юлдан язган карак та утырыр иде... Бу төркемдә татарлар да, руслар да, итальяннар һәм инглизләр дә, америкалылар һәм гарәпләр дә, башкортлар һәм чуашлар да, төрле кешеләр — салкыннары һәм дәртлеләре, тынычлары һәм гайрәтлеләре — барысы да актерның фантазиясе һәм таланты белән тудырылган. Биредә бәхетсез Незнамов та булыр иде, ә бераз читтәрәк атаклы татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри уйга чумган һәм аның янында Хаҗибәковның «Аршын мал алан»ыннан Вәли биеп йөрер. Калейдоскопның тоткасы борыла һәм күз алдында Советлар иле каһарманнарының берсе, батыр ватанпәрвәр Муса Җәлил һәм хәйләкәр, мәкерле Николай Скроботов, янәшәдә шаян елмаеп торучы Хуҗа Насретдин, кырыс Мәгънәви, кызганыч, җайлаша белә торган, үзенә үзе ышанган Прибытков, каушап калган Шадрин, шат күңелле Сәгъдетдин...

Рольләр, рольләр, рольләр... Алар күпме бәхет, шатлык һәм күпме күңелсезлекләр алып киләләр. Образ эзләүләр, холык эзләүләр. Син тар сукмаклардан, олы юллардан баручы күзәтчегә әйләнәсең, әле биек тауларга күтәреләсең, әле тирән базга барып төшәсең һәм аннан бер дә чыга алмассың кебек. Менә синең ролең каядыр качкан да сине үчекләп тора — әле сиңа телен күрсәтә, әле борынын, аны тотарга телисең — ул синнән сикереп качып китә... Менә шулай итеп газапланасың инде, аны иярләгәнче...

Академия театрында эшләвенең беренче елларында ук аның турында бик җылы итеп Фатих Хөсни язып чыга: «Фуад Халитов артист буларак гаҗәеп бер зур энергия белән үсеп килә. Яшьлек энтузиазмы, эчтән давыллана белү, шигъри җиңеллек һәм тормыш дөреслегенә таба омтылу — менә бу сыйфатлар яшь артист Халитовны башкалардан аерып торалар. Соңгы елларда татар театрында Халитовтан башка, аның таланты һәм «итәге» кысылмаган спектакльне бик сирәк очратасың. Бу яшь егет барлык спектакльләргә дә дип әйтерлек тартыла һәм ул барысында да үзен аклап чыга» (Хөсни Ф. Безнең яшь актерлар. Кызыл Татарстан, 9 февраль, 1941).

Артистның театрда үткән юлына әйләнеп карасаң, аның иҗади язмышы тулаем алганда бәхетле булган дигән фикергә киләсең. Ул театрга килү белән, аңа шунда ук ышаналар. Рольләр — зурысы да, кечкенәсе дә — берсе артыннан икенчесе килеп кенә тора. Ләкин бу ышанычның нигезендә яшь актерның гадәттән тыш хезмәткә яравы, эш сөюе һәм эшкә сусавы ята.

Үзенчәлекле бер очрак искә төшә. Театр сугышка кадәр үк М.Әблиевнең «Шәмсекамәр» драмасын сәхнәгә куярга әзерли. Анда танылган актер Зәйни Солтанов староста Сәйфулланың ролен кабатлый икән. Ә Халитов спектакльдә мәшгуль булмаса да, һәр көнне репетицияләрдә утыра. Спектакльне тапшыру әзерләнә. Көтмәгәндә З.Солтанов авырып китә. Эшнең өзелү куркынычы килеп туа. Ул вакытта Ф.Халитов, үзен танылган остазга алмаш итеп, староста роленә үзен тәкъдим итә. Әлеге роль аңа бик ошый, һәм ул, аның турында ничектер үз-үзенә хисап биреп бетермичәрәк уйлап, үзенчә хәл итеп куя. Әмма ләкин ул бу хакта әйткәч, театр җитәкчеләре кулларын гына селтиләр. Янәсе, кая инде сиңа З.Солтановның үзе белән ярышырга. Аның тәкъдимен кире кагалар. Күпмедер вакыттан соң Халитов үзенең үтенечен кабатлый һәм аңа репетиция ясарга рөхсәт итүләренә ирешә. Алга таба, З.Солтанов терелеп чыккач, яшь актерның ничек кызык итеп эшләвен күрә дә аның файдасына үзенең роленнән баш тарта.

Менә шулай итеп эштәге тынгысызлыгы, үҗәтлеге коллективта артистның мөмкинлекләренә ышаныч тудыра, һәм, әйтергә кирәк, Сәйфулланың роле кызыклы гына килеп чыккан. Тамашачы алдына бер кабахәт, икейөзле кеше килеп баса. Бу кешенең киң кара кашлары, сыек кына сакалы, йөзендәге чирканыч елмаюы һәркемдә җирәнгеч тойгы уята.

Ф.Халитов иҗатына бер бик мөһим сыйфат хас иде. Без аның кичерешләр мәктәбенең чын актеры икәнлеген беләбез. Халитов актер эшендә иң төп нәрсә — рольне психологик анализлау икәнлеген яхшы аңлый иде. Ләкин ул, шулай ук тирән, психологик эшкәртү артында калып, образның тышкы ягы, аның формасы һич кенә дә онытылырга тиеш түгеллеген дә истә тотты. Шигъри дулкынланган, тәмамланган сәхнә образы фәкать бер «кичереш» нигезендә генә тудырыла алмый. Актерның техникасыннан башка, күзгә бәрелеп торган тышкы формасыннан башка, артистлыктан башка чын сәнгать әсәре була алмый. Шуңа күрә иң танылган совет режиссерларының берсе булган

Е.Вахтангов «кичерешләр мәктәбе» белән «күз алдына китерү мәктәбенең» бергә кушылуы турында (ләкин «күз алдына китерү» гыйбарәсен һич тә «һөнәр», «кәсеп» төшенчәсенә тиңләштермичә) сөйли торган булган. Актер, сөйли белү, тавыш, сүзләрне ачык итеп әйтә белү (дикция), гәүдә белән ритмик хәрәкәтләр ясау сәләте, сыгылмалылык (пластика) кебек тышкы тәэсир итү чараларының барысын да тирән һәм бик яхшы итеп үзләштереп, барысын да үзендә булдырырга тиеш. Ул үзенең гәүдәсенә дә, хисләренә дә ия булырга тиеш. Актерның бөтен тәэсир итү чаралары — образның эчтәлеген ачарга ярдәм итү, һәм шуның өчен кызыклы, нәкъ менә шуны — бирелгән сәхнә характерына кирәк булган формаларны эзләргә кирәк.

Халитов үз иҗатының башыннан ук, баштан эчке сиземләү белән, аннан соң тулаем аңлап, осталыкның серләренә төшенеп, әлеге кагыйдәгә буйсынып яшәде. Шуңа күрә, әгәр без ул тудырган рольләрне исебезгә төшереп, күз алдына китерсәк, шуны күрербез: алар эчке аермалар белән генә түгел, ә һәрбер аерым очракта кулланылган тышкы алымнар белән дә аерылып торалар.

Халитов тарафыннан 1940 елда, дөресрәге, Академия театрында эшли башлавының беренче елларында ук уйналган шактый зур рольләренең берсе Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» трагедиясендәге Ромео роле була. Бу — актерның дөнья драматургиясе гиганты белән беренче очрашуы. Ул актерны тагын да тирәнгәрәк кереп, тагын да җитдирәк итеп эшләргә мәҗбүр итә, чөнки аның алдында кеше холкының бик «зурысы» торган була.

Рольнең үтәли чыккан төп сызыгы — мәхәббәт, ул хиснең көче була. Трагедияне сәхнәләштерүче Е.Амантов җентекләп адым артыннан адым ясый — актердан образның идеясен, мәгънәсен «тартып чыгара». Режиссер образның тәэсирле асылын ачыкларга тырыша һәм бик тырышып, сабыр гына итеп яшь Халитовны тиешле юнәлешкә сала. Мондый роль белән Халитов беренче тапкыр очраша. Шуңа күрә, әлбәттә, татар артисты тудырган образ тулы, камил дип тә әйтеп булмый. Аңа масштаблык, чын мәгънәсендәге трагедияле күтәрелеш җитенкерәми. Ләкин, шулай булуга карамастан, Халитов өчен шул вакыттагы Ромео роле шактый зур вакыйга һәм яшь актерның иҗат тормышында бер истәлекле чор булып кала. Шул хакта күренекле татар язучысы Гадел Кутуй үзенең бәяләмәсендә болай дип яза: «Театрның яшь буыны вәкилләре Халитов һәм Миңлебаеваның Ромео һәм Джульетта рольләрендә чыгыш ясауларын уңай вакыйга дип бәяләргә кирәк. Әлегә бу фәкать башкаларга охшатып уйнау гына булса да. Шунысы ышандыра: инде хәзер үк Халитов һәм Миңлебаеваның уйнауларында үзләренә хас, образны сәхнәдә чишүгә үзләренчә якын килү сизелеп тора» (Кутуй А. Шекспир на татарской сцене. Красная Татария, 18 ноября 1939).

Ф.Хөсни дә, аны кабатлап, болай дип яза: «Ромео һәм Джульетта» әсәрендәге роле ул кайчандыр башкарган җиңел эстрада рольләренә тулысынча капма-каршы килеп тора. Ул җиңел сөякле такмакчы егеттән һөнәри артистка әйләнде, һәм бу әйләнү үкенечкә булмады, бу әйләнү безнең барыбызны да сөендерә торган әйләнү булды» (Хөсни Ф. Безнең яшь артистлар. Кызыл Татарстан, 9 февраль, 1941).

Бу эшләрнең җәмәгатьчелек һәм тәнкыйтьчеләр тарафыннан уңай бәяләнүе турында шул вакыйга сөйли: ике актер да әлеге рольләре белән 1940 елның көзендә Мәскәүдә узган Театр яшьләренең I Бөтенроссия конференциясендә катнашу дәрәҗәсенә ия булалар. Россиянең бөтен почмакларыннан җыелган яшь актерларның эшләрен караганнан соң, матбугатта татар артисты тудырган образ аеруча зурлап бәяләнә: «Халитов башкаруындагы кызу канлы, ярсулы Ромео тамашачының игътибарын җәлеп итте. Бу образ актерны киләчәктә зур иҗат уңышлары көтә дип ышанырга нигез бирә» (I Всероссийская конференция театральной молодежи. Советское искусство, 13 октября 1940).

Халитов соңыннан конференциянең аларга яхшы дәрт-дәрман бирүе, алга таба үз өстендә эшләү өчен яңа көчләр өстәве, иҗади эзләнүләргә һәм актерлык осталыгын күтәрүгә юл күрсәтүе турында сөйли иде.

Актерның иҗади үсүендә Татар дәүләт академия театрының классик әсәрләр репертуары да гаять зур роль уйный. Иң яхшы классик әсәрләрнең ачык күренеп торган реалистик юнәлеше, аларның гуманистик байлыклары театр үсешенә ярдәм итә. Классика — театрлар үзләренең осталык, сәхнә мәдәнияте дәрәҗәсе үсүен тикшерә торган алым ул. Гәрчә милли театр иҗат эшчәнлегенең төп эчтәлеге булып, әлбәттә, халыкның заманча тормышын чагылдыручы үзенә бертөрле драматургиясе яшәде һәм яши.

Әгәр Камал III не һәм Ф.Ильскаяны классикада ялкынлы, дәртле, тугрылыклы, намуслы каһарманнар мавыктырсалар, М.Мутинны кайчандыр хыялга бирелүчән көрәшчеләр образлары, Халитовны тегеләре дә, болары да һәм еш кына бер-берсенә чиктән тыш капма-каршы образлар да кызыксындыра. Шуңа күрә тамашачылар аны Ромео образында да, Николай Скроботов, Прибытков, Хуҗа Насретдин образында да күрә алалар иде. Һәм һәрвакыт актер тамашачыны образының чынлыгы, дөреслеге белән таңга калдыра, гаҗәпләндерә иде. Бер генә җирдә дә кечкенә генә дә ясалмалык булмады.

Сугыш алды елларында яшьләр катнашканга күрә генә дә отышлы булган спектакльләр күренә башлады. «Күзләр» спектакленә бәяләмә язганда, Г.Кутуй болай дип күрсәткән: «Куелган әсәрдә

нечкә юмор, яхшы диалоглар булуга карамастан, сәхнә хәрәкәте юк. Ләкин тулаем алганда Миңлебаева, Халитов, Сәгыйтов кебек яшь артистлар уйнавы белән спектакль лирик, җылы һәм шагыйранә килеп чыккан» (Кутуй А. Очи. Красная Татария, 28 ноября 1939).

Шулай итеп, Татар дәүләт академия театрында үткән сугыш алдының дүрт елы Халитов өчен киеренке уку, көч һәм осталык туплау еллары була.

...Казанда Мәскәүдә узачак татар сәнгате һәм әдәбияты Ункөнлегенә актив әзерлек бара. Иҗат берлекләрендә яңа әсәрләр укыла, карала, тыңлана. Һәм менә болар барысы да кинәт, көтмәгәндә, кискен тукталып кала... Гитлер Германиясе Советлар Союзына һөҗүм итә. Безнең бөтен тормышыбыз хәрби тормышка ярашып үзгәртеп корылырга мәҗбүр була. Сугышның беренче көннәрендә күп нәрсә ачык аңлашылып җитми. Тормыш әле сугышка кадәрге иске эзеннән ага кебек. Ләкин вакыйгалар бик тиз бара, һәм тормышның барлык өлкәләрендә дә ашыгыч чаралар күрү таләп ителә.

Бу шартларда театр әйтеп бетергесез зур әһәмияткә ия була. Ул кырыс елларда тамашачы сәнгатьтән үзе өчен җан тынычлыгы һәм күңел күтәренкелеге ала иде.

...Һәм театр халык арасына чыга — заводларга, мәйданнарга, вокзалларга һәм пристаньнарга, армиягә чакыру пунктларына бара.

1941 елның җәе, көзе һәм кышы бик куркыныч һәм фаҗигале була. Караңгыландырылган шәһәр. Татар дәүләт академия театры бинасы эвакуация пункты итеп алына, һәм өч театр — Опера, Татар академия һәм Рус театры — Зур драма театры бинасында кысылып урнаша. Иртә килгән салкын кыш башлана. Ягарга утын юк. Театрны хәзер тыныч тормыштагы бәйрәмчә киенгән күңелле тамашачылар төркеме тутырмый, ә хәрби туннар кигән фронтовиклар, майланып беткән телогрейкалар кигән эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар. Ләкин шәһәр яши. Ул киеренке, кырыс тормыш белән яши. Ә аның белән бергә театр да яши. Ул яңа спектакльләр чыгара. Ул планнан тыш та спектакльләр куя һәм оборона фондына уннарча мең сум акча җыеп тапшыра.

Театрның күп кенә хезмәткәрләре — М.Надрюков, Г.Газизов, Ф.Камал, Г.Йосыпов, Х.Сабиров, К.Гыйльманов, Һ.Солтанов, студиячеләр — фронтка китәләр. Калганнар җилкәсенә икеләтә йөк төшә. Ф.Халитов сугыш елларында театрда нинди генә эшләр башкармый. Ул сәхнә эшчесе дә, йөкче дә була, декорацияләр ясау цехында булыша, образлар тудыра, кайвакытта бер үк кичтә берничә роль башкара. Бер үк вакытта ул донор да була. Актер, үзенең көченнән килгәнчә, фронтка китүчеләрне алмаштырырга тырыша. Ул үзе фронтка эләкми. Дөресрәге, аны, И.Гафуровны, Г.Зыятдиновны сугышка киткән юлларыннан, хәрби эшелоннан кире борып кайтаралар. Кире кайтарганнар да бронь биргәннәр. Мондый чамасыз авыр елларда театрны ябарга ярамый иде, ирләр төркеменнән башка театрны калдырырга ярамый иде. Шуңа күрә бронь белән сугыштан калдырылганнарга икеләтә, өчләтә йөк төшә.

Безнең алдыбызда Ф.Халитовның сугыш елларында уйнаган рольләрдәге дистәләрчә фоторәсемнәре. Менә К.Симоновның «Рус кешеләре» исемле пьесасыннан тәртипкә өйрәтелгән, тәкәббер һәм шәфкатьсез нацист Розенберг. Ә янәшәдә Островскийның «Яшен» драмасыннан Кудряшның бик күңелле, бик җилле шаян йөзе...

Шунда ук М.Әмирнең атаклы «Миңлекамал» пьесасы — беренче карашка аңлашылмый торган күршелек. Ә менә Халитов нигәдер ике кыяфәттә. Акыллы, арыган, киң күңелле, ягымлы йөзле райком секретаре Гыйльманов. Һәм шунда ук янәшәдә җирәнгеч, чирканыч, сөйкемсез чырайлы кылый Хәлим. Профессор Л.Җәләй ул вакытта: «Ф.Халитовның талантлы артист икәнлеге кылый күзле Хәлимне уйнаганда күренде», — дип язды.

Король Лирның иң якын, ышанычлы дусты, намуслы Кентның йөзендә без күпме чын, ясалма булмаган хәлгә керүчәнлек күрәбез.

Ә янәшәдә — «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектаклендәге маклер Хөснетдиннең гадәти татар алыпсатары, спекулянты, хәйләкәр, үтә алдакчы адәм актыгы чырае. Г.Кашшаф та бу хакта: «Хөснетдин маклерның реаль сурәтен, җанлы табигатен артист Ф.Халитов искиткеч осталык белән күз алдына бастыра», — дип очраклы гына язмаган (Кашшаф Г. Сезон башы. Совет әдәбияты, № 11 — 12, 1941).

Испан гранды Федерикның тук, үз-үзеннән канәгать һәм үзенә ышанган, тәкәббер чырае безгә Лопе де Веганың «Печән өстендәге эт» комедиясе спектакленнән алынган фотодан карап тора.

Шунда ук Арбузовның «Таня» пьесасыннан совет инженеры Германның тыныч йөзе, Б.Горбатовның «Аталар яшьлеге» спектакленнән Антон...

Сәүдәгәр Бикинең чыраенда ук аның саран, ялагай, куркак һәм адәм актыгы икәнлеге язылып куелган. Шуңа күрә аны акыл иясе Хуҗа Насретдин дә яратмый.

Дистәләрчә фоторәсемнәр һәм аларның берсе дә уйлап чыгарылмаган. Безнең алдан бер-берсенә охшамаган, укымышлы кешеләрнең тулы бер галереясе үтеп китә. Бу фоторәсемнәрнең һәрберсе актерның нинди бай мимикага ия булганлыгын дәлилли. Ә артист кешегә аның йөзенең мәгънәле булуы нинди зур әһәмияткә ия булуын кем генә белми икән?.. Бер генә рәсемдә дә сез бер-берсен кабатлаган ике йөз күрмәссез. Менә шушы бер караганда гади генә күренгән мәгънәле йөзне булдыру

артында никадәр күп хезмәт тора. Актерның һәр сәхнә образы — инде башка персонажларга күчә алмый торган, нәкъ менә бу кешенең табылган образы. Рольләрнең җентекләп һәм нечкәләп эшләнгән рәсемнәре фәкать бу персонажларга гына хас.

Халитов өчен һәр холык — табигатькә кабатланмас кыяфәт бирә торган — рольнең пластик күчермәсе дә әйтеп бетергесез зур роль уйный. Актер ритмлы, сәхнәдә бик яхшы хәрәкәт итә. Ә менә болар, барысы бергә алганда, эшкәртелгән, җентекләп уйланылган, әзер роль бирә.

Тамашачы Халитов тарафыннан тудырылган рольләрнең никадәр төрлелеген һәм кайвакытта аның холкына, социаль хәләтенә бөтенләй капма-каршы килгәнлеген күрә. Әмма ләкин актерның барлык рольләре аша, уңайлары һәм тискәреләре аша кызыл җеп булып бер фикер, бер тема уза. Бу — тормышта уңай башлангычның ныгу, урнашу темасы, чынбарлыкка гуманистик мөнәсәбәт темасы. Бу фикерне ул һәр роленә сала. Артист үзе тудырган образларда кешелек дәрәҗәсен табарга тели һәм хәтта кайвакытта, тискәре персонажларны уйнаганда, аларда кешелекле лек сыйфатлары эзләгән кебек була. Моңа мисал итеп аның башкаруында К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» әсәрендә бер үк вакытта хәйләкәр дә, акыллы да ат карагын һәм Н.Исәнбәтнең «Һиҗрәт» әсәрендәге көлке дә, кызганыч та хәзрәтен китереп була.

Ф.Халитов үз өлешенә тигән рольгә, аның нинди булуына карамыйча, игътибарсыз карамый, беркайчан да салкын булып калмый. Ул шунда ук каһарманына карата үзенең мөнәсәбәтен төгәл итеп билгели. Алга таба, инде үзенең эшен тамашачыга күрсәтеп, ул бу юлы уйнаган теге кешесен яратырга һәм күрә алмаска өйрәтә.

Әгәр сугыш алды елларында Ф.Халитов әле яңа гына көч җыя башласа, ә сугыш елларында инде тәҗрибә һәм белем тупласа, сугыштан соңгы вакытта ул инде үз эшенең остасына әйләнә.

Кырыс сынау еллары аның әхлакый күреп белүен тагын да үткерли. Соңгы 35 ел эчендә ул, үзенә яшь вакытта баглаган өметләрне аклап, тулысынча бурычларын кайтара. Бу вакыт эчендә Ф.Халитов совет театрының иң яхшы осталары тудырган образлары белән бертигез торырлык бик яхшы образлар тезмәсе тудыра.

Бу галереягә нигез салучы образларның берсе булган 1947 елда уйнаган Н.Погодинның «Мылтыклы кеше» пьесасындагы атаклы Шадрин роле. Актер алдында, рольнең үзе бик авыр булганга гына түгел, ә совет театрында инде Шадринның бик яхшы образлары тудырылганга күрә, гадәттән тыш катлаулы бурыч тора.

Башта актер рольгә керә алмыйча изалана. Әйтерсең ул сабый хәлендә. Күңелдә дистәләгән сорау: Герман фронты окопларыннан Питерга әйләнеп кайткан солдат нинди булырга тиеш? Үзен ничек хис итә ул? Ә менә Смольныйда Ленин белән очрашу мизгелен, чәй турында сөйләшүләрне ни рәвешлерәк уйнарга? Икесе дә мөһим сәхнә күренеше.

Тирән уйларга бирелеп, күңеленнән генә әле бу, әле теге эпизодларда уйнап, актер урам буйлап атлый. Аның яныннан гына эре адымнар белән бер абзый үтеп китә. Дары һәм төтен исе сеңгән, ышкылып беткән шинель кигән, күрәсең, бөтен сугышны айкап узгандыр. Бер кулына чиләк тоткан, җилкәсенә мылтыкка охшаган буяу пумаласы да менеп кунаклаган.

Артист аңа эндәшә:

— Ваня дәдәй!

Солдат борылып карый.

— Нинди Ваня булыйм мин сиңа? Вася мин, Василий Кузьмич.

— Гафу итегез, Василий Кузьмич, ялгыштым. Сез Иван Шадринга шулхәтле охшагансыз.

— Бернинди Шадринны да белмим мин. Әйе, ялгыштың син, егет, ялгыштың, — ди солдат һәм юлын дәвам итмәкче булып кузгала, ләкин актер аны туктатып өлгерә.

— Василий Кузьмич, әйдәгез, буфетка кереп чыгабыз, берәр чәркә сыра эчәрбез. Монда сыра һәрвакыт әйбәт була. Ялгызым гына нигәдер күңел тартмый.

— Соң, әйдә, алай сыйлыйсың килә икән, мин каршы түгел. Эштән соң берәрне тотып кую гөнаһ булмастыр.

Сыраханәгә кергәч, сөйләшеп китәләр. Дөнья күргән тәҗрибәле солдаттан актерның бик күп нәрсәләр хакында сорашасы килә. Аны барысы да кызыксындыра: сөйләм теленең интонациясе дә, үз-үзен тотышы да, бит мускулларының хәрәкәте дә, ым-ишарәләр дә...

— Мин, улым, сугышны буеннан-буена гизгән кеше. Мәскәү астыннан алып Кенигсбергка хәтле күпме окоп салкыны татылган! Дүрт ел, күз алдыңа китерәсеңме? Кырык бердә Мәскәү тирәсендә окоплар казыдым. Кабер дә казыдым. Аннан Курск дугасы, Полесье, Польша һәм, ниһаять, Германия. Иң гаҗәбе шул — дүрт елга бер генә мәртәбә дә яраланмадым. — Карт солдат шинель төймәләрен ычкындыра, маңгай тирен сөртә. — Үзем мин Псков ягыннан, сугышка хәтле Покров дигән авылда яшәдем. Бүген ул авылның эзе дә юк. Фашистлар, яндырып, көлен күккә очырган. Казанга күчтем. Карчыгымны биргә эвакуацияләгәннәр иде. Хәзер якшәмбе көннәрендә аның каберенә барам. Мине көтеп алмаган, мәрхүмә, үлгән. Балаларыбыз булмады. Авылда мичче идем мин. Әле дә шул һөнәрем ярап куя...

Алар урамга бергә чыгалар. Солдат көрәк кебек киң кулын, шинель чабуына сөртеп, актерга суза һәм: «Сыең өчен рәхмәт, улым», — ди. Ул очраклы танышының исемен дә сорамый, «Син кем?» — дип тә төпченми. Моңа нигә гаҗәпләнергә: үз гомерендә ул меңнәрчә шәфкатьле җаннарны очраткандыр һәм сугыш кырында йөзәрләгән үлемнең шаһиты да булгандыр.

Актер, вакыт турында бөтенләй исеннән чыгарып, солдат артыннан бик озак карап тора. Бераздан гына, репетициягә соңаруын аңлап, театрга йөгерә, атылып диярлек тамаша залына килеп керә.

Спектакльне сәхнәләштерүче режиссер Шириездан Сарымсаков аның аклануын тыңларга да теләми:

— Репетициядән соң тикшерербез, марш сәхнәгә! — дип боера ул. — Рәхим итегез. Ленин белән очрашу мизгеле.

Фуад Халитов белән Габдулла Шамуков сәхнәгә күтәреләләр. Кинәт солдат Иван Шадринга җан иңә... Актерның алдан әзерләнмичә генә уйный алу сәләте искитәрлек могҗиза иде.

Бу күренешне әллә ничә мәртәбә кабатлыйлар. Кабатлаган саен ул камилләшә генә бара. Режиссер да канәгать, Халитовның соңга калуын онытып, артистларга рәхмәтен белдерә.

СССРның халык артисты Фуад Халитов тарафыннан иҗат ителгән образлар галереясында иң уңышлысы дип саналган Иван Шадрин образына ачкыч әнә шулай табыла.

Шадринның холкы бик катлаулы булып чыга — сугыш чукмары, үзсүзле, астыртын, хәйләкәр таза гына ир. Шуңа күрә дә инде аны башта фәкать сыер белән ат кына кызыксындыра да. Башкарган рольдә ике төп сәхнә күренеше була — эшче Чибисов белән (Камал III) Ленин (Г.Шамуков).

Шадрин большевиклар сәясәте турында сөйләүче Чибисовка маңгай астыннан гына авыр караш белән карый. Дәшми, тупас итеп җавап бирә, ә уенда бер генә нәрсә — «Син лыгырдаган нәрсәгә ышанмыйм, кит янымнан! Ул — тезген кидерә торган «бирешмим!» дигән ат кебек иде. Менә Чибисов Шадринның мылтыгына кулын суза. «Бирмим!» Мылтыкны үзенең гәүдәсенә кысып тота, күзләре бик сак кына карыйлар. Ә Чибисов тыныч кына ышандырып вазгыятьне аңлата. Шул вакыттан алып крестьянның аңында кискен борылыш башлана. Солдат кинәт уйга чумып кала. Аның күзләре инде усал түгел, ә игътибарлылар.

Ул Ленин белән очрашкач, аның аңында бик күп нәрсәләр үзгәрә. Очраклы гына очрашу, әңгәмә башланып китә. Шадрин кайгысы белән уртаклаша, сыеры үлгән. Әңгәмәдәшенең кызыксынуын күргәч, җанланып китә, кызып-кызып сугыш турында, үзенең солдат уйлары турында сөйли башлый.

«Халитов Шадринның рухи яктан яңадан тууын күрсәтә. Ул үз каһарманын һәркемгә якын образ итеп уйный. Тамашачы каршына акыллы, тәвәккәл һәм бай рухлы рус крестьяны килеп баса. Әлеге образны иҗат итү Ф.Халитовның сәнгатен тагын да югарырак баскычка күтәрә», — дип яза Гази Кашшаф (Кашшаф Г. Татар сәхнәсендә юлбашчылар үрнәкләре. Кызыл Татарстан, 7 май, 1947).

Вакытлар узгач, эшкә барганда, эштән кайтканда, теге карт солдатны күреп, аңа бу хәлне сөйләп бирергә күпме хыяллана актер, әмма күрешүләр насыйп булмый.

Татар театрлары актерлары арасында да 1940 еллар ахырында — 1950 еллар башында Ф.Халитовныкы кебек бик яхшы иҗат ителгән образлар бик аз була.

Совет театрының сугыштан соңгы беренче еллардагы хәле бик катлаулы була. Иҗади эзләнүләр белән беррәттән — хаталар, дөрес булмаган карашлар, болары инде сугыш алды елларында килеп чыга башлаган була, һәм алар турында 1939 елда Режиссерларның I Бөтенсоюз конференциясендә сүз булган. Сүз сәнгатьтәге тигезләү, ике арадагы аерманың бетүе, аның законлашуы, актерлык һәм режиссерлык иҗатында штамп күренүе турында бара. Берничә ел үтәр, һәм матбугат килеп туган бу хәлне тәнкыйтьләп чыгар.

«Сәнгатьтә бердәнбер дөрес карарлар юк, — дип язды «Правда» газетасы. — Сәнгатьтә иң куркыныч бәлаләрнең берсе — тигезләү, ике арадагы аерманың бетүе, иң яхшы булса да бер үк үрнәккә тигезләп китерү. Әсәр өстендә эшләүгә мондый караш аерым бер үзенчәлекләрне бетерә, шаблон, ияртүчәнлек тудыра, иҗади фикер үсешен тоткарлый, сәнгатьне эзләнүләр шатлыгыннан мәхрүм итә» (Правда, 27 ноября 1953).

Мондый хәлдән татар театры да читтә калмый. Берничә спектакль генә бераз отышлы булып чыга: М.Әмирнең «Тормыш җыры», Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», Н.Исәнбәтнең «Мулланур Вахитов», Б.Горбатовның «Аталарыбыз яшьлеге», Б.Лавреневның «Диңгездәгеләр өчен» әсәрләре шундыйларга карыйлар. Ләкин шул ук 1950 елларда якты вакыйгага итеп билгеләп үтелгән бер чор булып ала. Шуңа мисал булып 1957 елда Мәскәүдә татар сәнгате һәм мәдәнияте Ункөнлегендә үткән еллардагы иң яхшы спектакльләрне күрсәтү тора. Бу Ункөнлек нәтиҗәсендә театрның күп кенә хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр бирелә. Алар арасында Ф.Халитов та «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем ала.

Инде Ункөнлектән соң Ф.Халитов үзенең иң яхшы рольләренең берсе булган Муса Җәлил образын тудыра. 1958 елда Н.Исәнбәтнең шул исемдәге трагедиясендә уйный. Каһарман татар шагыйре

образын бик яхшы итеп башкаруы артистның яшерен, әмма ләкин туктамый торган иҗади үсүе турында сөйли.

Яшь режиссер П.Исәнбәт тарафыннан куелган бу спектакль 1958 елда Мәскәүгә гастрольгә алып барыла. Гастрольләр «Муса Җәлил» белән ачыла һәм ябыла. Баш рольне башкаручы, әлбәттә, мәскәүлеләрнең югары билгесен ала.

«Халитовның һөнәри мәдәнияте, кешенең рухи дөньясын тирән аңлавы, совет актерының каһарманлыгы тамашачыга татар милли каһарманы булган Муса Җәлилнең иң яхшы сыйфатларын җиткерергә булыштылар» (Кормушина Г. По пути исканий. Литература и жизнь, 6 июля 1958).

«Халитов бөтен спектакль аша гадилекне һәм кешелеклелекне алып бара» (Соколов А. Поэт — гражданин. Московская правда, 3 июля 1958).

Әмма ләкин әлеге хөрмәт күрсәтүләр белән беррәттән ул елларда әле яшәп килүче тәнкыйть театраль эстетика ягыннан образның гадәтилеген дә билгеләп үтте. «...актерның Җәлил-шагыйрьне, илһамлы романтикны һәм ялкынлы агитаторны күрсәтүе йомшаграк чыккан. Аның тавышында кайдадыр ясалма гадәти көнкүреш интонацияләре күренеп китә...» — дип яза «Советская Россия» (Морозова Н. Новая встреча. Советская Россия, 26 июня 1958).

Роль өстендә эшләгәндә, Халитовның Муса турындагы шәхси истәлекләре, аның белән якыннан таныш булуы күп нәрсәләр бирә. Сугыш алды елларында, бергә эшләгән елларда шагыйрь — лирик, тормыш сөючән, киң күңелле, шат елмаюлы кеше — каһарман көрәшче, бөтен дөньяга танылган шагыйрь. Бу каһарман Ленин премиясе лауреаты булыр дип, ә кайчан да булса аның образын уйнау турында уйлавы да кыен булган. Муса Җәлилнең бөтен тышкы кыяфәте ул башкарган каһарманлык белән берничек тә бәйләнми. Шуңа күрә роль икегә аерылган кебек килеп чыккан — Муса өйдә һәм Муса әсирлектә, Германиядә.

Беренче күренештә вакыйга Казанда бара. Өй, соңгы кич. Фатирда тынлык. Фәкать өстәл лампасы гына яна. Эңгер-меңгер. Җылы, җыйнаклык. Муса бүлмәдә, ә ширма артында кечкенә авыру кызчык. Ул гимнастеркадан, итексез, өйдә кия торган бәйләгән ак оекбаштан. Дәшмичә генә, бары тик кызчыгы белән ара-тирә генә сөйләшеп, бүлмә буйлап йөри, кәгазьләрен тәртипкә китерә. Эчтән генә барлык күнегелгән, йөрәккә якын әйберләр белән аерылыша. Артист бернәрсә дә эшләмәгән кебек, тыштан тыныч күренә, ләкин бик тирән уйлар белән бер ноктага төбәлгән. Ул әле өйдә иде, ләкин шул ук вакытта ул монда юк та кебек, ул инде алгы сызыкта. Бу күренештә берниндичамасыз хискә бирелү дә юк, бернинди мелодрама да юк, ләкин дулкынланудан тын кысыла.

Җәлилнең уй белән фронтта булуы беренче күренештә актерга кирәк, бу — үзенә күрә бер күпер, бәйләүче, тоташтыручы буын. Чөнки алдагы күренеш безне шунда ук Муса әсирлеккә төшкән вакытка, баракка илтеп ташлый.

Һәм биредә, концлагерьда, аннан соң уйдырма азатлыкта шагыйрь тыштан элеккеге кебек калган төсле. Бары тик күзләре генә җылылыгын югалткан, алар кырыс, нык булып калганнар. Йомшак, ягымлы, зыялы һәм какшамас, тимер холыклы сәяси җитәкче, Халитов Мусасы «куркусыз һәм тел тидергесез рыцарь» түгел. Ул — киң күңелле, иркәләүче, җылы күзле йомшак кеше. Ләкин холкының бу сыйфатлары аны куркакка әйләндермиләр. Киресенчә, нәкъ менә җирдә иң югары яхшылык һәм гаделлек өчен сугышырга бара бу сөйкемле кеше. Ул ачык йөзле, өйдә хатынына һәм кызына карата бик нык игътибарлы. Муса кызы белән гаҗәеп назлы һәм шаярып уйный. Мусага карап, бу күренешләрдә беренче карашка йомшак бу кешенең тимердәй нык түземлеккә һәм нык ихтыяр көченә ия булуына ышануы да кыен.

Германиядә татар мөһаҗире өендә барган күренешләрдә дә Муса тыштан шундый ук йомшак. Ләкин аның күзләре ничек аңлатып караучан. Муса шат күңелле, борчусыз, ләкин тамашачы болар артында чит кеше киемендә булган кешенең сагышын сизә.

Халитов Җәлилнең образын хәрәкәттә, үсештә күрсәтә. Акттан актка Мусаның тышкы кыяфәте генә түгел, эчке ягы да үзгәрә. Тамашачы аның төгәл эшләүче уй-фикерен сизә.

Төрмә һәм сорау алу күренешләрендә безнең алда кырыс, какшамас кеше, алда торган җәзалау турында белсә дә, үзенең кыюлыгын һәм ихтыяр көчен югалтмаган каһарман тора.

Каһарманлык, ныклык һәм какшамаслык сыйфатлары белән беррәттән Халитов зыялы шагыйрь, мәгърифәтче кешене күрсәтә. Мондый эретмә тулы бер кеше холкы образын ачып бирә. Бу образда, үзенең башка иң яхшы рольләрендәге кебек, актерның уйлый белү сәләте, сүзләрне тамашачыга җиткергәндә төгәл булуы күренә, һәм шул сыйфатлар аны якын һәм заманча итәләр.

Мусадан соң тагын да рольләр була. Күп рольләр. Баш һәм иярчен рольләр, һәм тагын, һәрвакыттагыча, актер бернинди эштән дә баш тартмый. Бик күпләрнең хәтерендә нечкәләп эшкәртелгән эпизодик рольләр сакланып калган. «Тукай» спектаклендә Халитов Печән базары сәүдәгәренең сүзсез дип әйтерлек ролен уйный, һәм ул шундый иттереп уйный, аны баш рольләр белән янәшә куярга мөмкин. Яки бөтен тамашачыларның күңелләрендә бик озак сакланып калган «Чаткылар»дагы тиле-миле исерек Мочтак роле...

Шул ук елларда М.Әмирнең «Хөррият» әсәрендәге авыл Советы рәисе, Э.Раннетның «Юлдан язган угыл» әсәрендәге Марк Туйск, Н.Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ындагы Хафиз рольләре кебек рольләр дә уйналган.

Тагын, һәрвакыттагыча, Халитов турында җылы сүзләр генә сөйлиләр. «Якты темпераментлы һәм зур эчке көчкә ия булучы артист Халитов Хафизның тирән психологик образын тудыра. Халитовның Хафизы спектакльдә бик зур идея йөге алып бара. Автор нәкъ менә аның авызыннан театрның халык тормышындагы бөек роле турындагы фикерне әйттерә, һәм, Хафиз-Халитовның хәрәкәтләрен күзәтеп, тамашачының үзенең халкын яктылыкка, азатлыкка чакырган кешеләргә карата хөрмәте арта», — дип язылды «Гөлҗамал» спектакле өстендә эшләү турында (Кумысников Х. Правда искусства. Советская Татария, 21 сентября 1963).

Татар дәүләт академия театрында яңа чор анда Марсель Сәлимҗановның баш режиссер булып килүе белән башланды.

Халитов баштан ук Сәлимҗановны йөрәгенә якын кабул итә һәм аңа ышана. Алай гына да түгел, ул Сәлимҗановны бу вазифага билгеләнүен актив яклаучы кеше булып та чыга. Зур дәрәҗәле кеше һәм танылган актер буларак, Халитов, яшь белгечне баш режиссер итеп билгеләүләрен үтенеп, югары партия оешмаларына күп тапкырлар бара.

Соңыннан, яшь аермасы шактый булуга карамастан, алар якын дуслар булып китәләр, өйләренә кунакка йөрешәләр, бергәләп балык тотарга йөриләр. Халитов Шәүкәт Биктимеров белән беррәттән Марсель Сәлимҗановның иң яраткан актерларының берсе булды. Ул бик еш кына Халитовның татар театрының легендар актеры Шакир Шамильский белән ниндидер бер эчке иҗади туганлыклары барлыгын, аның юлын дәвам итүче икәнлеген кабатлый торган иде. Режиссер хәтта шундый өзелмәс җепне дә төзеп куйды: Шамильский, Халитов, Таҗетдинов.

Аларның өчесен дә сиземләүнең искиткеч булуы, тормышчанлык, кайнар дәртле, бай эчке кичерешле, темпераментлы каһарманнар берләштерә.

Сәлимҗанов актерны репертуарда бик актив файдалана. Халитов иҗатының соңгы чоры бик уңышлы булды. Шуңа күрә, соңгы унбиш ел эчендә вазгыятьнең уңай якка үзгәрүе сәбәпле, Халитовның бик күп һәм кызыклы образлар тудыруы бөтенләй очраклы хәл түгел. Өстәп әйтергә кирәк, бер-берсенә охшаш булмаган образлар бит әле алар. Әйтик, «Шамил Усманов»тагы Сәгъдетдинне һәм «Соңгы корбан»дагы Прибытковны, «Миләүшәнең туган көне»ндәге Әһлиулланы һәм «Фатыйма Сабри»дагы Габделхәмитне, «Американ»дагы Шәехмирзаны һәм «Хуҗа Насретдин»дагы Хуҗаны, «Агай-эне ак мыек»тагы Рисположенскийны һәм «Канлы күләгәләр»дәге Карлос Бланконы; «Синең урыныңа кайттым»дагы Мәгънәвине һәм «Ир-егетләр»дәге Әхтәмне бер-берсе белән чагыштырып буламы соң?

Сүз дә юк, соңгы бик зур, күләмле, осталарча тудырылган рольләрдә алдагы елларның тәҗрибәсе дә үзен нык сиздерә. Мөгаен, Шадриннан башка шундый гаҗәеп Сәгъдетдин дә, Розенбергтан башка Габделхәмит тә булмас иде.

Ф.Халитов, уңай каһарманнарны уйнап, үз персонажларының намуслылыгын, омтылышларының чисталыгын күрсәтергә омтылды. Тискәре рольләрне уйнап, бу кешеләрнең бөтен әшәке, түбән эчке сыйфатларын ачып бирә, аларны нәфрәтләнеп фаш итеп, җәза карары чыгаручы судья, прокурор кебек чыгыш ясый.

Сәхиб Җамалның «Фатыйма Сабри» әсәрендәге Габделхәмит тә шундый.

Тыштан купшы, «энәдән чыккан» шәп киемнәр киюче, бик яхшы нечкә-нәзакәтле гадәтләргә ия булучы тикшерүче. Аның күзләре кечкенә тычканныкы кебек кенә, ирен өстендә тар гына мыегы, кыек юл калдырып таралган ялаган кебек кара чәче. Баштан караганда ул шулкадәр сөйкемле, ачык йөзле, ачык күңелле кеше булып күренә. Габделхәмит бөтенесе белән ягымлы, киң күңелле, елмаючан. Аның тавышы, әле әкрен генә аккан инеш кебек челтерәп, әле әкрен генә көйләп, мер-мер килеп чыга.

Зиһенгә ирексездән чагыштыру килә. Котырынган, фанатик фашистлар меңнәрчә, ун меңнәрчә кешеләрне үтерәләр һәм шул ук вакытта, җан-тәннәре белән бирелеп, үзләренең балаларын да яраталар. Араларында бик яхшы музыкантлар, Моцартны, Бетховенны башкаручылар да була. Аларның кайберләре шул чиккә барып җитәләр ки: үлем лагерьларында чәчәкләр үрчетү белән шөгыльләнәләр һәм мәетләр яндыру бинасы белән янәшәдә матурлыклары белән шаккатыргыч, искиткеч гүзәл чәчәкләр үстерәләр. Коточкыч вәхшилек. Әмма ләкин булган хәл...

Шуңа күрә соңыннан без күреп алган Габделхәмитнең тышкы кыяфәте белән беренче карашка туры килмәгән мәрхәмәтсез эчке дөньясы чынбарлыкка тулысынча туры килгәнлегә күренә, һәм актер моның белән бик яхшы файдалана.

Менә ул өенә әйләнеп кайта. Сөйкемле, бик нык яраткан кебек, хатынын кочаклый. Аның белән тыныч кына һәм яхшы гына сөйләшә. Фәкать күзләре генә аның эчкерсез түгеллеген белдерәләр. Габделхәмит алдында ничек кенә булса да революционер Фәрхәдне эзләп табу бурычы тора. Шул максат белән ул сиздермичә генә Фәрхәднең фоторәсемен чәчәкләр вазасына сөяп куя, һәм үзе, кә-

нәфигә утырып, әһәмиятсез генә ниндидер өйдәге әңгәмәне алып бара һәм һәрвакыт хатыны артыннан күзәтә. Аның әлеге фоторәсемнең барлыкка килүенә ничек игътибар итүен беләсе килә. Габделхәмитнең күзләре, аны тотарга тырышып, Зәйнәпнең йөзе буйлап шашынып йөгерәләр. Ләкин тыштан караганда ул бик игътибарлы, кече күңелле, аның белән ягымлы булып кала.

Ул Фәрхәднең әнисе Фатыйма Сабри белән дә шулай ук ягымлы. Әмма ләкин... барысы да вакыт җиткәнче генә. Фәрхәд тозакка эләккәч, Габделхәмитне танып булмый.

Тикшерүче бүлмәсе. Коммунисттан сорау алу бара. Сабридан бернәрсә дә әйттерә алмагач, сорау алучы Габделхәмитнең йөзендә дежур елмаю урынына коточкыч ерткычларча ырҗайган авыз күренә, һәм хәзер безнең алда фашистланучы һәм, мөгаен, үзенең элгәреләреннән берни белән дә ким булмаган гестапо офицеры образы тора...

Нибары берничә ай гына вакыт үткән, ә Ф.Халитов инде алдагысы белән бернинди уртаклыгы булмаган роль иҗат итә. Бернинди охшашлык билгеләре дә юк, ни тыштан, ни эчтән...

Совет властеның 50 еллыгына Академия театры А.Гыйләҗев һәм А.Яхинның «Шамил Усманов» драмасын сәхнәләштерде. Ф.Халитов анда Сәгъдетдин картны уйнады. Бөтен спектакль аша, бөтен массалы күренешләр аша, барлык персонажларның холыклары аша кызыл җеп булып массаларның революцион аңы барлыкка килү фикере уза.

Бу спектакльдә күпсанлы халык күренешләре булган урыннар белән беррәттән аерым кешеләрнең язмышлары ачылу вакытлары да булды. Шуңа күрә «халык язмышы, кеше язмышы» төшенчәләре аерылгысыз бердәмлектә булдылар.

Тавышлы, шау-шулы халык төркеме арасында тыныч кына, аерылып тормый торган гаҗәеп чиста, хәйләсез һәм саф караучы күзле бер карт йөри. Ул кечкенә генә буйлы, бөкрәеп тора, кара төстәге татар казакиен кигән. Аркасында кечкенә генә киндер капчык. Үзең дә сизмичә, аның артыннан күзәтә башлыйсың. Нәрсә белән икәнлеге аңлашылмаса да, ул нәрсә беләндер аерылып тора һәм үзенә карата кызыксыну уята. Карт әлеге шау-шудан бераз югалып кала. Аны кемдер төртеп җибәрсә, ул бер сүз дә әйтә алмый, төртүдән чайкалып куя да, гаҗәпләнеп, тирә-ягына карый. Ниһаять, этелә-төртелә өстәл янына килеп җиткәч, ул карлыккан, әкрен генә тавыш белән аны Кызыл гвардия батальонына язуларын сорый. Менә бу — Сәгъдетдин үзе инде. Әйтерсең лә Ф.Халитов бу спектакльдә иң яхшыга әйләнгән образны тудыруга бер көч тә куймый. Театрда иң югары бәя биргәндә әйтелгәнчә, бу — беренче номерлы актерлык эше.

Бу Сәгъдетдин аз сөйли, нигәдер һаман халык төркеме эчендә йөри, күзәтә, тыңлый, дөньяда нәрсә булганын аңларга тели. Шуңа күрә, аның яхшылык сирпеп торган күзләре шундый игътибарлы, сынаулы. Бөтен азсүзлелеге артында без әлеге хәйләсез карт яшәгән тулы бер тормышны күрәбез. Актер, бер сүз дә әйтмичә, әлеге кешенең бөтен тәрҗемәи хәлен ачып бирә. Һәм монда актерлык осталыгының иң югары уңышы чагыла. Чөнки моны эзлекле итеп алып бару һәм тамашачыга җиткерү — һәр артист үти алырлык эш түгел.

Халитовның Сәгъдетдине — бик милли образ. Татардан башка бер генә халыкта да андый кешеләрне күреп булмый. Анда дөньяга карашы саф, яхшы карашлы, бераз гына беркатлы, бөтен гомере өметсез нужада яшәргә өйрәнгән революциягә кадәрге ярлы, хокуксыз татар крестьянының кыерсытылганлыгы, юашлыгы, басынкылыгы эретмәсе салынган. Бернәрсә дә — изелү дә, Россия чынбарлыгының әшәкелекләре дә — анда тормышның ахыргы, соңгы яхшылыгына, аның электән килә торган гаделлегенә ышанычны юкка чыгара алмыйлар. Шуңа күрә Сәгъдетдиннең холкы нигезендә усаллык түгел, ә кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәт яши. Һәм ул һәрвакытта, теләсә кайсы минутта аларга ярдәмгә килергә әзер тора. Сәгъдетдиннең тормышның якты башлангычына ышанычы аның җиңел уйлаучанлыгыннан, җүләр сыманлыгыннан һәм шул сәбәпле катлаулылыкларны аңламавыннан түгел. Юк, киресенчә. Бу карт акыллы, һәм, акыллы булу сәбәпле, ул тормышка ышана.

Сәгъдетдин үз тормышының соңгы чорында бик күп нәрсәне хәл итә һәм үзе өчен бик күп нәрсәне ача. Яңалыкка чиксез ышанычы белән бу ягымлы карт кеше үз артыннан яшьләрне дә ияртә. Без бераз гына буш сәгатьләрендә һәм минутларында үзе генә калганда Сәгъдетдиннең тирән уйларга чумуын, аның комиссарны сынап күзәтүен һәм аның сөйләвенә колак салуын күрәбез.

Сәгъдетдин һәлак булганда, сине сыкрап сызлый торган авыру биләп ала, әйтерсең лә син бик якын туганыңны, бик якын, гадәттән тыш кадерле җан иясен югалтасың.

Карт татар крестьяны күп уйлана, фикер йөртә. Гомумән, әлеге образда бөтен роль буйлап кызыл җеп булып фикер, уй бара. Ул ялгыз калса да уйлый, кешеләр белән булса да уйлый, сөйләшкәндә дә үзенекен, күңел түрендәгесен уйлый. Бу очракта, бәлки, сәер дә яңгырар, әмма ләкин Сәгъдетдин-Халитов — бай эчтәлекле зыялы кеше.

Әйтергә кирәк, сәхнәдә фикерле белү — гомумән, Халитов каһарманнарына хас күренеш. Бу — аның талантының бик яхшы, аерылып торучы сыйфаты. Бу — үзенең иңендә дистәләрчә еллар тәҗрибәсе булган актерны татар театрының иң заманча актеры иткән сыйфат.

«1960 — 1970 елларда театр сәнгатендә хәзерге заман актеры кем ул, хәзерге заман уен стиле нәрсә ул?» дигән темага сөйләшүләр, дискуссияләр булып узды. Бу бәхәсләр мантыйклы һәм закон-

чалыклы, чөнки реалистик сәнгать ул эченә яңа эчтәлек агызып тутырыла торган катып калган формалар түгел, ул — үзе чагылдырган чынбарлыкның тәэсире астында үзе үзгәрә торган гадәттән тыш сыгылмалы организм, ул — бөтен нәрсәне сизә торган, җир астындагы теләсә нинди үзгәрешләрне теркәүче сизгер сейсмограф.

Актерның сәнгате һәрвакытта массакүләм һәм кешеләрне берләштерүче тамашага исәпләнгән. Артист аерым бер шәхескә түгел, ә җәмгыятькә мөрәҗәгать итә, бу аның иң төп һәм иң мөһим сыйфаты. Тамашачы белән берлектә залга бүгенгә «көнүзәк мәсьәлә» керә, ул театрга үзенең таләпләрен куя, анда бүгенге көн сорауларына җавап эзли. Шуңа күрә аның бөтен тарихында бәяләнмәгән, замандашлары аңламаган, ә аннан соң киләчәк буыннар даһи дип санамаган артист юк та, булмады да. Бу бүген «терек белән тереләрчә» дип килгән тамашачы белән күзгә-күз карап сөйләшә торган, «күптән үткән еллар эше» белән түгел, ә бүгенге көн белән кызыксынучан тамашачы белән, театрның үзенчәлеге белән бәйле. Актер үзен бөеккә күтәргән буын алдында гомере буена үзен күрсәтеп яшәргә тиеш. Аның киләчәге ул — аның бүгенгесе. Нәкъ менә театр сәнгате, башка барлык сәнгатьләрдән аермалы буларак, фәкать үзенең замандашлары өчен генә иҗат иткәнгә күрә, аның конкрет бүгенге тормыш белән бәйләнеше гадәттән тыш киеренке булып күренә.

Ф.Халитов һич бәхәссез зыялы, укымышлы актерлар рәтенә керә. Әлбәттә, аны табигый сәләте генә шундый итми. Бу юлларның авторы белән сөйләшкәндә, Фуад абый үзенең бөтен гомере буе заман белән бертигез булырга, гасырдан артта калмаска, аның койрыгында сөйрәлеп бармаска тырышуы турында сөйли иде. Ул һәрвакыт уяу. Заман таләпләре киеренке тормышта яшәргә мәҗбүр итә, һәрвакыт эштә, энергияле ритмда булуны сорый. Ә бу үз чиратында даими укуны, үзеңнең осталыгыңны камилләштерү хакына бертуктаусыз армый-талмый эшләүне таләп итә. Менә шуннан чыгып, заман таләпләрен төгәл үтәргә өйрәнә, шуннан чыгып, уенның стилен, ысулын үзгәртүгә китерүче даими заманчалык. Халитов, спектакльдәге бүгенге диалог кыска, ачык, төгәл, озак аңлатуларсыз һәм чәйнәп каптыруларсыз булырга тиеш, дип әйтә иде. Чөнки бүгенге тормышның темпы, тавыш тизлегеннән дә югары тизлек белән эшләүче двигательләр заманы темпы гадәттән тыш зур тизлек белән бара. Чынбарлыкның шартларын аңлау образларны заманча төгәл чишүгә китерә. Шуның белән бергә хәзер генә язылган пьесаларның персонажлары гына түгел, ә классик әсәрләрнең каһарманнары да бүгенгечә аңлатып бирелә.

Классикларның пьесаларында холыклар, күптөрле традицияләр һәм штамплар ябышып «үсә», ә Халитов һәр чакта алардан кача. Шуның ачык мисалы булып Островскийның танылган «Соңгы корбан» драмасындагы Прибытков роле тора.

«Мин бу актерда гаҗәеп сизгерлек, бай рухи дөнья тойдым, — дип яза пьесаны сәхнәләштерүче Мәскәү режиссеры М.Новохижин. — Аның Прибытковы — катлаулы холыклы кеше, аның эчке дөньясы гүя кискен итеп икегә аерылган һәм хисләре дә капма-каршы яши. Ул бер үк вакытта яхшы күңелле дә һәм каты күңелле дә» (Новохижин М. Нас спаял Островский. Театральная жизнь, № 2, 1969).

«Мөгаен, Фуад Халитов башкаруында Прибытков образы — спектакльнең иң кызыклы чишелгән образларының берсе» (Гыймранова Д. Соңгы корбан. Социалистик Татарстан, 17 октябрь, 1968), — дип, республика матбугатының иң югары бәя бирүе дә очраклы түгелдер.

Прибытков сүзгә бик саран. Каһарман тыштан караганда тотнаклы гына, хәтта тәкәббер дип тә әйтеп була. Һәрвакытта, сирәк кенә очракларны искә алмаганда, бик тыныч. Аның күз карашы гына холкының капма-каршылыгын, аның эчке дөньясының катлаулылыгын ачып бирә.

Халитов башкаруындагы Флор Федулычның Мәскәү елгасы аръягындагы «караңгылык патшалыгы» вәкилләре Хлыновлар һәм Дикойлар белән бернинди уртаклыгы юк. Ул укымышлы һәм хәтта зыялы дип әйтергә мөмкин. Аны һич кенә дә Курослеповның һәм Тит Титычның исерек, акыручы өерендә йөрүче кеше итеп күз алдына китереп булмый. Прибытков — яңа чор сәүдәгәре, укымышлы, сәнгать белән кызыксынучан, чит илләрдә булган. Һәрхәлдә, аны әйләндереп алган мохит белән чагыштырганда, ул бик күпкә отышлы хәлдә. Прибытков бай, ул һәркемне үзенең алдында тезләндереп тота ала. Менә шуңа күрә дә инде ул шундый киребеткән, тәкәббер, үзенең әйләнә-тирәсенә кимсенеп карый. Бу — чын күңелдән Тугинаны яратучы сәүдәгәр һәм чыннан да аның язмышы өчен борчылучы кеше. Шуңа күрә ул аның белән йомшак, ягымлы. Ләкин шуның белән бергә актер бик нечкә итеп, сизелер-сизелмәс кенә Прибытковның шул ук ерткыч, ләкин элеккеге сәүдәгәрләргә караганда нечкәрәк, үткенрәк эш алып баручы кеше икәнлеген аңлата. Юлия Тугинаның тере җанын һәлак итүчеләр арасында ул да бар. Бу нисбәттә икенче күренештәге Юлия сәхнәсе үзенчәлекле.

Бай, алтынланган куе чия төсендәге штоф тукымасы белән тышланган Прибытков кабинеты. Бик зур ишекләр, массив канделябрлар, барокко стилендәге җиһаз, барысы да үтә зиннәтле, үтә тантаналы, тәэсир итә торган. Менә акча сорарга Тугина килә. Ике актер — Ш.Әсфәндиярова һәм Ф.Халитов — менә дигән шәп дуэт оештыралар.

Прибытков кырыс, тотнаклы, ләкин яшь хатын-кыз килүенә эчтән гаҗәпләнә дә, шат та. Визитның сәбәбен белгәч, хәтта ул, Юлияне яратып йөрсә дә, аның өстеннән оятсызланып көлеп алудан

канәгатьләнү алырга тели. Астыртын мыскыллы көлеп, чыбыркы белән суккан кебек кискен итеп «Юк!» дип кырт кисә. Йөзе караңгылана, кәнәфигә утыра. Яраткан хатын-кызының түбәнсенүен күргән кешенең кайгысын ачык итеп тоеп булган авыр караш. Аннан соң Юлия, өметсезләнеп, шактый ямьсез адым ясарга теләсә дә (ул аның тезләренә утырып бераз чытлыкланып алырга тели), Флор Федулыч аны кискен рәвештә усал итеп этеп җибәрә, дулкынлануыннан хырылдап чыккан тавышы белән кычкыра. Кәнәфидән сикереп тора. Хәрәкәтсез катып кала. Һәм фәкать Юлия аның алдында тезләренә егылгач кына, ул «ах!» дип бирешә. Нindидер алты мең сум акча өчен аның үзен шулай түбәнсетүенә гаҗәпләнә. Әкрен генә сейфы янына бара. Акчаларын бирә. Бөтен барлыгы белән аңа тартыла, һәм аның үбүеннән соң ул берничә тапкыр, интонация һәм әһәмият арасында үзгәрүләр кертеп, үзе генә калганда, «бу үбү бик кыйммәт тора!» дигән сүзләрне кабатлый.

Актерлар тарафыннан сәхнә күренеше бик тыйнак алып барыла. Хисләрне бернинди ялган драматик уйнату юк, беркем дә үзенең «дәртләрен» өзми. Ләкин шуның белән бергә бу күренеш дулкынландыргыч, тирән драматик хисләр белән сугарылган. Ул бөтенләе белән хәзер тураер да авырттырып сугып җибәрер төсле торган кысылган пружина кебек.

Тугинаның аның белән өйләнешергә ризалык бирүенә ирешкәч, чынлыкта аны сатып алып, Прибытков-Халитов, акыллы кеше буларак, бәхетне сатып ала алмаганлыгын яхшы аңлый. Тормышта аның шатлыгы булмаячак. Менә ни өчен, хәтта тормышының иң бәхетле кебек күренгән чагында да, аның йөзендә, күзләрендә хәсрәт катып калган, һәм аны берни белән дә куып чыгарып булмый. Бу — Прибытковның трагедиясе, һәм ул үзе дә моны бик яхшы аңлый.

Татар артисты тарафыннан менә шундый тирән, киң кырлы холык иҗат ителә. Прибытковның фикере төгәл, ачык итеп җиткерелә. Дөресрәге, ул бер генә минутка да каһарманның исеннән чыкмый. Секунд өлешенә дә актер пьесадагы хәрәкәттән чыгып тормый. Бөтен спектакль дәвамында тамашачы театраль телдә «икенче план» дип әйтелгән, чит кешеләр күзенә күренмәгән эчке тормышны сизеп утыра.

М.Сәлимҗанов сәхнәләштергән А.Островскийның «Агай-эне ак мыек» спектаклендәге адвокат Рисположенский образын да актерлык шедеврлы дип атап була. Бөкре, гомергә исерек, майланып каткан киемле, үзеннән-үзе биздергеч тышкы кыяфәте артында актер түбәнсетелгән һәм мәсхәрәләнгән кешеләрнең драматизм тулы тормышын күрергә ярдәм итә. Дөрес, кайвакытта аңарда ачык авызлы сәүдәгәрләрнең авызларын яптырырга тырышучы дәртле адвокат образы да кабынып китә, ләкин тулаем алганда мәҗбүри ярарга тырышучы Рисположенский фигурасы артында үз заманында Достоевскийның җанын көйдергән юаш, мескен, ярлы халыкның гомумиләштерелгән образы күренеп тора.

Бу образда тормыштагы хаклык, күзгә ташланып торган яктылык белән каһарманның төгәл мантыйкый тәртибе кушылып китә. Шуннан чыгып, холкының тышкы күренешен кабартып бирү — Рисположенскийның аракыга булган дәртен ассызыклап күрсәтү килеп чыга. Аракыны күргән саен, аның күзләре очкынлана. Ул үзенең күз карашын графиннан ала алмый, бөтен барлыгы белән аңа тартыла, ә аннан соң түземсезлектән калтыраган куллары белән стаканга аракы сала. Ләкин, әгәр дә эчке тулылык булмаса, рухи драманы бу дөньяның көчле кешеләренә бәйле булган «кечкенә» кешенең җиткерүе булмаса, тышкы үзенчәлек кенә үз максатына ирешә алмас иде.

Бервакыт Фуад абый белән аның ничек эшләве, ничек рольләр иҗат итүе турында сүз чыккан иде. Ул аның өчен, актер өчен образның эчке тормышы бик зур роль уйнаганлыгы турында сөйләде (үзе дә шуны бик яхшы практикада куллана иде). Шуңа күрә, үзе өчен персонажының тәрҗемәи хәлен ачыклап, аның төп үзәген табып, ул әлеге кеше өчен тышкы ачып бирү сыйфатлары эзли. Ләкин бу очракта Халитов өчен образның иң мөһим өлеше булып һәрвакыт бөтен спектакль дәвамында алып барыла торган эчке монолог кала бирә. Шуңа күрә дә инде, кагыйдә буларак, Халитовның рольләре шундый тирән, күләмле булалар. Чөнки ул холыкның тышкы ягы белән генә чикләнми. Халитов бер генә секундка да пьесадагы хәрәкәттән читкә чыкмый. Ул — даими рәвештә, бу очракта персонаж әңгәмәдә катнашамы, юкмы, тирә-яктагылар белән барыбер тыгыз элемтәдә, аралашуда. Каһарманның сәхнәдәге гомере буена игътибар шунда булган вакыйгаларга төбәлгән була.

Рольнең эчке, тәэсир иткеч сызыгына мизансцена рәсеме дә бәйле. Чөнки актер мизансценаны үзмаксат түгел, ә рольнең холкына, аның эчке тормышына бәйле дип саный.

Халитов ничектер бер диаграмма ясаган иде. Ул бөтенләй кәкрәеп беткән, әле кинәт кенә өскә күтәрелә, әле кинәт кенә аска төшеп китә, әле кайдадыр күтәрелүләр һәм төшеп китүләр арасында озын гына, тигез генә җеп булып сузылып бара. *«Бу,* — дип аңлатты Халитов, — *актерның роль өстендә эшләве. Озак барасың, газапланып... Әле генә бер холык тапкан кебек буласың. Карасаң, ул сине буш калдырып очып киткән. Актер, авыру тәндә җәрәхәтле җир эзләүче хирург кебек, кешене күзәтә. Ә андый күзәтү алып бару өчен тулы хәрби амуниция кирәк, ә актерның җиһазлары — талант плюс белем».*

Ничек шулай килеп чыккан соң, махсус мәктәбе булмаган, махсус белеме булмаган кеше бик яхшы актер була алган.

Мөгаен, бу сорауга җавап бирергә авыр булмас. Иҗат кешесе өчен, ул язучымы, рәссаммы, композитормы, актермы, барыннан да элек кешенең үзенә салынган талант кирәк. Әмма ләкин бер талант кына, әлбәттә, җитеп бетми. Аны үстерә белергә кирәк. Ә бу бик күп көндәлек, һәр сәгатьләп бик нык киеренке эшләүне таләп итә. Үз ихтыярыңны, гәүдәңне, тавышыңны, сөйләвеңне күнектерү кирәк. Театр гаҗәеп талантлы кешеләрнең, үзләренең ялкаулыклары сәбәпле, үз хезмәтенә намус белән карамаган өчен, ахыр чиктә бернигә дә ирешә алмаулары турындагы фактларны күп белә. Һәм дистәләрчә артистларның данлы исемнәрен китереп була, алар, махсус югары уку йортлары бетермичә, үзләренең табигый талантына һәм тырышлыгына күрә мәшһүр сәхнә осталарына әйләнделәр. Болар — революциягә кадәрге рус актерлары, болар — татар артистларының беренче буыны — Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Ш.Шамильский, Н.Таҗдарова, М.Мутин, З.Солтанов, К.Шамил һәм башка бик күпләр.

Хезмәт төшенчәсенә аның аерылмас өлеше — үзлегеннән белем күтәрү дә, театр әдәбияты, театр осталарында уку, фикер йөртү, бәхәсләр, сөйләшүләр, спектакльләр тикшерү дә керә. Боларның барысыннан да актер үзе өчен, акылы өчен, җаны өчен, үзенең үсүе һәм алга китүе өчен ризык ала.

Ф.Халитов бу укуларның, тәҗрибәләрнең бөтенесеннән актив файдаланды. Ул бөтен гомеренә үзенең турыдан-туры укытучылары дип исәпләгән Ә.Мәҗиткә, Ш.Шамильскийга, Х.Сәлимҗановка тирән рәхмәт хисләре саклады.

Татар актерлык осталыгы мәктәбе ул нигездә — кичерешләрнең чынбарлыктагы мәктәбе. Нәкъ менә шул юнәлеш беренче татар актерларына салынган иде, ә бу милли сәнгать пионерлары үзләренең дәвамчыларына калдырдылар. Әлбәттә, бу беренче татар артистлары 100 ел элек уйнаучылар кебек уйныйлар дигән сүз түгел. Юк. Ләкин нигезе шул ук.

Мөгаен, К.Тинчуринның «Американ» әсәрен беренче тапкыр сәхнәгә куйганда, ул башкачарак яңгырагандыр. Шәехмирзаны уйнаучы Ф.Халитов башкачарак күренгәндер һәм башкачарак уйнагандыр.

1969 елда М.Сәлимҗанов куйган «Американ» спектакле жанры буенча — фарс, гротеск. Бу спектакльне караганда, зиһенгә К.Марксның «тарих үзенең үткәне белән көлеп саубуллаша» дигән сүзләре искә төшә. Комедиянең бөтен персонажлары җир йөзеннән югалган җан ияләренең балавыз сыннарын хәтерләтәләр. Алар арасында беренче урын, әлбәттә, Шәехмирзаныкы.

Гаҗәеп, уен алымы белән әлегә кадәр уйналган образларның берсенә дә охшамаган. Сәхнә буенча кыска тар пиджак, аксыл төстәге бик кыска чалбар кигән хәлсез кеше йөри. Аның пеләш, бик яман зур кебек башының кырыйларында бөтен якка сирәк кенә чәчләр тырпайган. Аның бөтен гәүдәсе чиктән тыш көлкеле. «Йөри әлеге галим ир», — дип, үзен олылый Шәехмирза, әллә сикереп йөреп, әллә аксап йөреп, яхшылап кына аңламассың да. Гаҗәеп кыяфәткә — оратор позасына басып, карлыккан, өзелә торган фальцет белән дөрес, хак сүзләр сөйли.

«Американ» спектаклендә Халитов эше шунысы белән кызык иде: актер монда бөтенләй башка манерада уйнады. Аңарда, әйтик, Прибытковның, Мусаның, Сәгъдетдиннең роль стиле белән бернинди дә уртаклык юк иде. Монда ачыктан-ачык тамаша иде. Әмма ләкин бу бөтенләй актерның реалистик алымнардан читкә китүе булмады. Монда да хаклык бар иде. Ләкин фарс хаклыгы, сатирик гротеск хаклыгы иде. Сәхнә сәнгате реформаторы К.С.Станиславский: «Драматик сәнгатьнең һәр жанрының үзенең сәхнә хаклыгы бар», — дип, күп тапкырлар әйткән. Трагедия хаклыгының водевиль хаклыгы белән бернинди уртаклыгы юк, ә водевиль хаклыгының фарс хаклыгы белән, драма яки мелодрама турында әйтеп тә тормастан, бернинди уртаклыгы юк.

Шуңа күрә «Американ» — бөтен спектакльнең үзе дә һәм бөтен актерларның эшләре дә, шул исәптән Ф.Халитовның эше дә, бу үз палитрасының бик күп төрле төсләрен булдыруда зур әһәмияткә ия булды.

Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр» пьесасындагы Әхтәм образы бөтенләй башка манерада, кичерешләр манерасында, тирән психологик дөреслек манерасында уйналды. Бу образ озак елларга актерның бик танылган роле булып калды. Урамда Халитовны күргән кешеләр: «Әнә Әхтәм килә» яки: «Исәнмесез, Әхтәм!» — дип узып китәләр иде.

...Заманча кафеның киң тәрәзәләре артында күп катлы йортларның гаять зур корылмалары күккә ашкан. Кафеда буфетчы Сәлимә (М.Миңлебаева) һәм ямьсез кыяфәтле, искереп беткән кара свитердан, башына берет кигән, сүнгән күз карашы белән биек өстәл янында баскан килеш аракы эчеп торучы билгесез бер кеше. Монда бер стакан минераль су эчәргә дип гадәти генә, башкалардан аерылып тормый торган соры төстәге костюм кигән, яхшы һәм йомшак күз карашлы 50 яшьләр тирәсендәге бер ярыйсы гына юан ир кеше килеп керә. Баскан килеш кенә үзенең минераль суын эчә. Нәрсәдер турында уйлана, беркемне дә күрми. Аңа нәрсә өчендер мөрәҗәгать иткән икенче ир кешене дә күрми, нәрсәдер дип машиналь рәвештә генә җавап бирә. Җавап бирә һәм кинәт эчтән талпынып куя. Каршында торган ир кешегә күтәрелеп карый, игътибар беләнрәк, текәлебрәк карый башлый. Таный! Аның янына ташлана. Кочаклый. Дымлы күзләре белән бер мизгелгә катып кала. Бу — чи-

рек гасырдан соң ике фронт дусты, ике разведчик, сугышчан орденнар кавалерларының очрашуы. Аларның берсе — соры костюмдагысы — Мәрвән, ә икенчесе — беретлысы — Әхтәм.

Спектакль менә шулай башланып китә, аның нигезендә элеккеге дуслар арасындагы бик кискен тормышчан көрәш ята. Менә бу ике рольне Татар дәүләт академия театрының бик зур осталары уйнау очрагы спектакльне бик дәртле-темпераментлы, тормышчан китереп чыгардылар, бәрелешләр көчле, кискен булдылар, монда битарафлыкка һәм салкын мөнәсәбәткә урын булмады.

Спектакльдә Мәрвән белән тормышының кайсыдыр вакытында әшәке кешеләр белән туры килеп һәм алардан җиңелгән һәм шуңа күрә хәзер бөтен нәрсәгә, тормышка кара күзлек аркылы гына карый торган талантлы архитектор Әхтәмнең бертуктаусыз көрәше бара. Ул хәзер рәнҗетелгән кеше позасына баскан һәм бөтен җирдә гаделсезлек турында хакыйкать тарата. Актер бу сүзләрне карлыккан тавышы белән усал итеп, хәтта ниндидер каршылык белән әйтә иде.

Әхтәм-Халитов үзенең бик күп җәфа чиккән авыр язмыш кичерүче кеше икәнлеген ясалма күрсәтергә тырыша. Ул беркайчан да елмаймас, аның күзләре беркайчан да җылынмас. Йөзендә җәфа чигүченең даими тамгасы. Әмма ләкин үзенә кигән әлеге битлек, маска артында бик зур, кан саркый торган яра яшеренгән. Ләкин бу яраны дәвалау урынына Әхтәм һәрвакыт аны телгәләп тора.

Мәрвән үзенең эшсез калган дустын туган колхозына алып кайтып киткәч тә, Әхтәм-Халитов үзен бик күп җәфа чиккән авыр язмыш кичерүче кеше икәнлеген тәкәббер рәвештә күрсәтүен дәвам итә. Чынбарлык аның тормышка карата булган нигилистик карашларын әйләндереп ташлый.

1970 елларда Халитов тормышка тагын да ныграк текәлеп карый. Үзенең күзәтүчәнлеген актер һәр образ өстендә эшләгәндә уңышлы файдалана. Аның тудырган образлары шул хакта сөйли.

Тулаем алганда Халитовның рольләрен башкару манерасын, мәсьәләне чишүгә караш ягыннан ике төркемгә бүлеп була.

Бер төркем — психологик яктан бик нечкәләп тикшерелгән, өйрәнелгән, тышкы кыяфәтләре бик тотнаклы, елмаймый торган, чын тормыш хакыйкате белән тутырылган тирән һәм күпкырлы фәкать драматик образлар.

Персонажларның икенче төркеменә ачык, күзгә ташланып торган театральлек, кайвакытта карикатуралык, шаржны эченә алган комедия образлары керә. Әйтерсең актер фантазиясенең чиге юк. Әмма ләкин аның үзен иркен тотуы һәрвакыт холкының хакыйкатен, аның төп эчтәлеген ачуга буйсындырылган.

Халитов нәрсә генә уйнаса да, һәрвакыт тулысынча башка кыяфәткә керә ала иде.

Актерның киң иҗат диапазоны аңа бөтенләй капма-каршы рольләр уйнарга мөмкинлек бирде. Халитов, үзе тудырган образларга карап, тамашачыда персонажның холкына бәйле рәвештә әле кайнар мәхәббәт һәм рәхмәт, әле күрә алмау һәм нәфрәт хисләре тудыра иде.

Фуад Халитовның бөтен тормышы — ул театрдагы тормыш, театрга бирелгән тормыш. Чөнки театрдан башка бернәрсә дә бу кешене шулкадәр үзенә йота алмый. 50 ел дәвамында сәнгатькә хезмәт итү вакытында барысы да була: шатлыклар да, ачышлар бәхете дә, авырлыклар һәм кырпак кар да. Югары күтәрелешләр һәм тигезлек саклау... Ләкин һәрвакыт үзенең бөтен гомере буена бу кеше театрга булган изге мәхәббәтен, фидакярләрчә һәм җан-тән белән бирелгән һәм үзе дә күп тапкырлар сөйләгән мәхәббәтен алып бара. Халитовны халыкның тануына, СССРның халык артисты булуга ирештергән Халитов ясаучы мәхәббәтен алып бара.

Халык артисты. Бу исем җылы, акыллы, күпкырлы, уңышлы сәнгатьнең эчтәлеге турында уйлаучы кеше булган Фуад Халитов тормышының мәгънәсен барыннан да яхшы итеп билгеләүче исем булды. Һәм хәтта үләренә күп тә калмаган вакытта да ул барысын да аңлый иде, зарланмады, ыңгырашмады, ә авырлыкларны ирләрчә кичерде. Аның янына актерлар килгәндә, ул фәкать театр турында гына сораша, үзенең үгет-нәсихәтләрен бирә иде...

Театрдан башка аның кечкенә генә, ләкин бик тату, бер-берсенә мәхәббәт белән сугарылган дус гаиләсе бар иде. Халитов үзенең килене Фәнияне үз кызы итеп гаиләсенә кабул итте. Ә оныгы Элланы бик ярата иде. Фуад абый һәм аның улы Рөстәм бер-берсен гадәттән тыш яраталар һәм хөрмәт итәләр иде. Улы атасын тәмам илаһилаштырды. Ул вафат булгач, Рөстәм көн саен диярлек әтисенең каберенә барды. Рөстәм, атасының үлеменнән соң 9 гына ел яшәп, 48 яшендә вафат булды.

...Ә Фуад абый бу дөньядан мәңгелек йортка 1981 елның 15 мартында, аңа 72 яшь булгач күчте.

## ФУАД АБЫЙНЫҢ КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ ДӘФТӘРГӘ ТАТАРЧА ҺӘМ РУСЧА ЯЗЫП КАЛДЫРГАН ФИКЕРЛӘРЕ

Яшьлегеңдә гомер очсыз-кырыйсыз, озын булып тоела. Бернәрсәгә карамастан көннәрең, елларың тыныч үтүен сизеп алга, һаман ераккарак чабасың. Көннәр... еллар... Ничек үткәннәр алар? Үкенечле түгелме? Нинди гөнаһларың булды? Ә картлыкта, соңгы станциягә килеп җитсәк, юл бик кыс-

ка күренә, күз ачып йомганчы барып җитәрлек. Барысы анда, артта кала, кешегә яши алырлык гомер бирелә, һәм шул гомерең яхшымы, начармы, озынмы, кыскамы, — яшисең. Ягъни кабатланмый торган бер гомер ул — кеше гомере. Һәм шуның кебек гомер юлында нәрсәләр эшләвеңне үзеңә үзең бәя биреп карыйсың. Изге эшләрең шатландыра, бик борчулы кимчелекләреңне күз алдыннан үткәрәсең...

Зур ихтирамга лаек буын кешеләре бар, балалар һәм картлар... Ә мин үземнең картлыгым белән масаям, горурланам. Хезмәт җимешләрем халкым өчен булды, шуңа шатланам.

Гаиләм, туганнарым саф булдылар, — алар белән горурланам, бигрәк тә тормыш юлдашым, иң якыным, Марзушым белән горурланам. Аңа мең-мең рәхмәт һәм дан. Улым Рөстәмгә, аның киләчәктә җәмгыятебез өчен зур файдалы эшләр эшләвенә ышанам һәм аның белән горурланам. Фәнияне, оныгым — йөрәк бәгырем Элланы — йөрәгемне яратам. Барчасына изге теләкләр; әдәпле, җәмгыять өчен файдалы кешеләр булсыннар, бу минем изге теләгем, мин аларга ышанам.

Улым! Беркайчан иҗатта арыма, хезмәттән кеше үлми, зур әсәрләр яз, тынгысыз бул иҗатыңда, ярыймы, улым! Эллачкам... йөрәгем... әбиеңне һичбер кайчан онытма, бәгырем, тырыш, әтиеңне, әниеңне ихтирам ит, әдәпле, олы җанлы, ярдәмчел бул, зур кеше бул, бәхетле бул, озак яшә! *Бабакаең.*

* * *

Миңа 70 яшь, тагын шулкадәр яшәсәм дә сихри сәхнәмнән бизмәс идем.

Һәрбер яңа роль — ул яңа кеше белән очрашу, шул кешенең уйлары, тормышы, хисләре белән яшәү. Сәнгать кешесенең язмышы ике нигезгә бәйләнгән: талант һәм осталык. Бу сыйфатларның берсе генә дә зәгыйфь булса, иҗатчы нигезгә корылган булмый, талант базисы, нигез ташы өстә булыр өчен шул базиска корылган иҗади бинаны төзи белергә кирәк.

Вакытны бушка уздырмасам да, шулай да үткән гомерне кире борасы иде, туктатасы иде. Юк, картлык куркытмый, мәсьәлә анда түгел, эшләнеп бетмәгән эшләр чиксез күп. Нишләргә? Тиле йөрәк тә шаяра. Нишләргә? Эшлисе эшләр күп. Нәрсәләр эшләдем әле менә бу узган еллар эчендә? Сәнгать, гомумән иҗат — очсыз-кырыйсыз мохит бит ул. Аның очына чыктым дип, бер иҗат кешесе дә әйтә алмый, юк, әйтә алмый. Әйтергә хакыбыз юк. Бинигая авыр, тирән кеше хисләренә чума, ай авыр, шулай булмаганда театр белән бәхилләш, сәнгать чигенешләрне яратмый, ярга ата. Артист хезмәте — бик авыр хезмәт, ләкин иҗат җимеше белән тамашачыны канәгатьләндергән артист ул көнне ак биләүгә биләгән бала кебек ләззәтле һәм тыныч йоклар, бу бәхеттән дә зур бәхет юк. Театрдагы көндәлек хезмәт — туктаусыз эзләнү, эзләнү...

Иң әһәмиятлесе — башыңдагы бөтен дөнья мәшәкатен онуту, дикъкатьне фәкать иҗатка буйсындыру, тормышны аңлау, яшәүнең максатын белү, кешеләрнең йөрәкләренә керү. Менә шул.

Чөнки бүгенге тамашачы кичәге тамашачы түгел. Тамаша залында һәр яклап аңлы, белем белән корылган тамашачы утыра, һәм без алардан артта калырга тиеш түгел.

Үзеңдә иҗади канәгатьсезләнү, борчылу, нәрсәдер җитми кебек. Нәрсә? Нәрсә? Комсызланып белергә, төбенә төшәргә, бөтенесен ачыкларга кирәк. Артист гражданин һәм художник булырга тиеш.

НТР дәверендә иҗат итү тагын да тормышны тирәнрәк белүне таләп итә. Артист өчен 8 сәгатьлек яки 5 сәгатьлек эш сәгате юк. Ул урамда барганда да иҗат итә, йокларга яткач да иҗат газабы кичерә, башын мендәр астына тыга.

Һәм гомер буена газаплы эзләнү, табу шатлыклары, йокысыз төннәр, — җәүһәр һәм шул ук вакытта коточкыч профессия. Чөнки артистның шәхси тормышы икенче планда, чын художник өчен беренче планда сәнгать. Чын художник үзенең җәмгыять каршындагы бурычын фанатикларча яратып үти, сәгать белән исәпләшми.

Эх, дуслар! Мин нинди бәхетле! Чөнки мин иҗат кешесе! Артист!

Сәнгать камиллегенә якынайган саен, үз-үзеңә булган таләпчәнлек тә арткannan-арта бара. Артист профессиясе — сокландыргыч профессия.

Татар совет театрын үстерү теләге белән яшим. Ватан теләген, тамашачы зәвыгын, аның теләген канәгатьләндереп, ветеран буларак талантлы яшьләребезнең һәр яктан үсүенә шатланам һәм кулымнан килгән кадәр ярдәм итәргә тырышам.

Мин яшьтән үк тынгысыз сихри иҗат дөньясын, театр сәхнәсен үз иттем. Шул дөньяга гашыйк булдым, нәкъ шул дөнья миңа бәхет китерде, тормыш мәктәбе булды.

Менә 46 ел инде рольнең борын төртүе агач бөреләнгән кебек. Эшче клубы миңа канат куйды, очарга өйрәтте. Сәхнәдә эшләү дәверендә дистәләгән рольләргә җан бирдем...

* * *

Ум — это прекрасно налаженная мозговая машина, постоянно требующая топлива — знаний, впечатлений, переживаний. Именно ум вовлекает в творческую стихию.

Часто размышлял я о красоте человека, вообще считал людей, занимающихся искусством, счастливыми, серьезными людьми.

Сейчас, вспоминая и анализируя начало своей творческой биографии, я прихожу к выводу, что уже тогда у меня была еще не до конца осознанная, но властная и настойчивая потребность реализовать себя в искусстве. Любовь к сцене привела меня через рабочие клубы в Казанский государственный Рабочий театр. Сбылась моя мечта: я стал актером. Однако путь, ведущий к мастерству, был еще очень долог. Я хорошо понимал: чтобы стать настоящим актером, надо учиться, трудиться. К моему счастью, Рабочий театр превратился в рабочий театр-студию (руководитель Асгат Мазитов).

В 1933/34 году 8—9 месяцев молодой рабочий коллектив находился на стажировке в Москве. Нас прикрепили к МХАТу, Вахтанговскому, театру Революции. В.Сахновский, Р.Симонов, А.Попов были нашими наставниками. Надо ли говорить, какую роль в моей актерской судьбе сыграла работа в этом Рабочем театре. Помню как сегодня — нам, молодым актерам, помогали выдающиеся мастера сценического искусства.

Без сосредоточенности, без максимального напряжения сил не произойдет прорыва – открытия. Если не совершится это, человек может потерять веру в себя.

Самый строгий судья — ты сам. И беспощадно ответствен ты, прежде всего перед самим собой. Это и есть в конечном счете самая высокая ответственность перед обществом. Основная форма существования актера — это служение искусству.

Для меня самое главное — сохранить и здоровье, и творческие силы. Это значит работать и работать! Знать и постоянно ощущать, что ты нужен.

## АКТЕР

### Размышления о профессии

Комсомолец Татарии
*23 февр., 1969*

*Медленно гаснет свет в зале, и мы видим на сцене актера…видим лицедея, кудесника, мага, и в нем, маге, человека, раздираемого нашими собственными противоречиями, размышляющего о том, о чем мы размышляем, творящего на сцене жизнь, какую мы творим за порогом театра… Но что стоит за тем кратким мигом, когда актер выходит на сцену? Мы, зрители, видим обычно лишь результат, с которым является к нам актер, но мы не видим того пути сомнений, отчаяния, мучительных поисков, который проходит он, работая над ролью…*

*Статья эта есть результат диалога вашего корреспондента Д. Валеева с народным артистом РСФСР и ТАССР Фуадом Халитовым, чей 60-летний юбилей, кстати, отмечает в эти дни театральная общественность республики. Более 150 ролей сыграно им за сорок с лишним лет жизни на сцене. 150 ролей — 150 жизней…*

*Итак, что стоит за каждой исполненной ролью?*

На сцене мы ищем сценическую правду. Но эту правду мы должны прежде всего увидеть в жизни.

А роль дается не сразу. Читаешь, например, приказ. Ага, будешь играть такую-то роль. Потом помреж вручает тебе саму роль — несколько листов бумаги. Думаете, сразу начинаешь вчитываться? Нет, прячешь роль, в карман пиджака осторожно засовываешь, к сердцу ближе, пусть погреется там. Боишься читать. Ведь начинается мучительный период работы.

Иной раз пройдешь, не поздороваешься с человеком. А он, может, подумает: «У, зазнался!». Да нисколько. Задумался просто. Ведь когда мы, актеры, идем на репетицию, мы должны быть внутренне готовыми. Как лошади, которых готовят к скачкам на сабантуе, уже заранее, с весны, чуют и ждут их, так и мы, актеры, сколь, может быть, несообразно это сравнение, ждем своего часа. Бывает, сидишь гримируешься перед зеркалом, а рядом в коридоре кто-нибудь говорит: «Почем сегодня баранина на базаре?», ну кто-нибудь из технического персонала… И вот выходишь, извиняешься, спрашиваешь: «Кто это там, мол, насчет баранины?» А сам думаешь, какая к черту баранина, когда пятнадцать, десять, пять минут осталось до выхода на сцену?!

Да, актер должен верить свято в то, что делает. Помню, играл секретаря райкома. Война. В тылу одни подростки, женщины. Разоренная деревня. Сам знаю, в каком положении была тогда Родина.

Уметь войти в душу людей, дать им надежду, свет — вот что я должен был делать в роли секретаря. Мне нужно было пережить все снова так, чтобы каждое дыхание, каждый жест был оправдан, точен. Мне на свои плечи надо было взвалить всю ответственность, которая лежала на этом человеке.

Или роль Ивана Шадрина в «Человеке с ружьем». Я должен был создать внутренний рисунок роли до самой мелкой подробности. Я должен был показать, как средний крестьянин пришел в революцию. Ведь он внутренне приходит к ней. Он переделывается, сам не зная как.

Иногда теоретически все понимаешь и представляешь, можешь дать и внешний рисунок, а образ говорит тебе: «Нет, не возьмешь!» Да, его дыхание должно стать твоим дыханием, его противоречия – твоими. Встреча с Лениным Ивана Шадрина или эпизод, когда Шадрин собирает солдат, у меня не получались. А это было основное в образе. И вот в эти дни я увидел одного демобилизованного солдата. Пьеса эта ставилась после войны. Перенял у него походку, выражение глаз, как он сплевывает… Но это все было внешнее, внешнее!

А потом шел по Кольцу, на репетицию торопился и вдруг на трамвайной линии остановился. Меня осенило. Водитель трамвая выскочила, кричит: «Ты что, меня под суд хочешь!» А я радостный! Нашел вроде что-то, понял. А каким образом нашел, черт его знает. Схвати мгновение и запечатли!

Когда народному артисту СССР Тарханову задали вопрос: «Как вы работаете над ролью?» — он пожал плечами и ответил: «Всякий раз по-разному».

В самом деле, иногда роль дается тебе быстро, а иногда долго. Очень долго. Но надо ежедневно работать, ежедневно заниматься. Без такого ежедневного тренажа актеру расти невозможно. И не только актеру, но и врачу, инженеру. Диплом, например, это лишь аванс на будущее, но не само будущее. Его можно и потерять, если относиться к призванию своему небрежно. Поэтому — работа, постоянный тренаж. Для нас, актеров, особенно. Труд тяжелый, адский.

— Окупается?

— Радостью. Да, радостью! Взять хотя бы самый тяжелый застойный период — период поисков. Где там золото это зарыто? Где там зерно образа? И когда находишь, приятно. Приятно, когда видишь это по глазам режиссера, по глазам своих коллег-собратьев. А когда видишь, что твои раздумья, твоя боль доходят до зрителя, то здесь вот уже праздник актера, его торжество.

— А минуты, часы, дни отчаяния?

— А как же! Я — Халитов. Я должен играть муллу, бродягу, конокрада, профессора… А ведь я только Халитов. Ведь многого я просто и не знаю еще. Мало знать текст, вызубрить его, усвоить мизансцену, — это еще не образ. Надо найти внутреннее движение образа, показать душу его, показать, как меняется человек. Надо найти и внешне убедительное решение образа.

В тот период, когда я работал над ролью врача-глазника Салима, то не раз присутствовал на операциях у профессора Адамюка. Мне надо было знать мельчайшие тонкости. А здесь свои трудности… Тебе поручается роль. А зачем эта роль в пьесе? Что хотел сказать автор этой ролью? Что я, актер, хочу сказать ею? Я все должен знать. Авторский текст для меня, актера, это результат. Между авторскими строчками лежат еще и мои собственные строчки, мои внутренние монологи. Их не слышит зритель. Но он должен их почувствовать, коль я актер! Я, например, говорю простую фразу: «Пить хочу!» Но если я говорю это, то я и на самом деле должен испытывать жажду, должен показать, что я хочу пить. А не только сказать. Вот я сижу. Что заставило меня встать и шагнуть? Не самоцель! Внутренний монолог мой, внутренний ритм чувства. Актер, повторяю, должен быть убедительным, ибо его нервами, его душой живет его герой. Ведь каждая пьеса, каждая роль — это часто выражение целой эпохи, ее слепок. Поэтому ответственность, которая лежит на актере, как гражданине своего времени, своей эпохи, как мастере, наконец, своего трудного ремесла, огромна. Бывают ли дни отчаяния, сомнения в своих собственных силах? Конечно бывают. Это дни поисков…

Чем именно дышит жизнь сегодня, сейчас? Это главное, конечно! Ведь еще ставятся, ставятся зелененькие, недоделанные пьесы, несмотря на слабость их драматургического материала. Не плакатные борцы, не схематичные характеры нужны нам, актерам, и зрителям на сцене, а полнокровные, из жизни выхваченные типы. Живые люди со всеми их страстями, противоречиями, поисками своего единственного пути! Поэтому драматургия еще в долгу перед театром, перед зрителем. Хотя драматурги сейчас работают много. Но и задачи перед ними тоже труднейшие. Ведь чего не хватает современным пьесам порой? Философии в них мало, философии! В треугольниках решаются в большинстве случаев все проблемы. Две женщины, один мужчина. Двое мужчин, одна женщина и т. д. Или вот, например, злободневная пьеса. Можно ее ставить в этом сезоне, а на будущий год? В следующем сезоне ее уже не поставишь. Та правда, которой жила эта пьеса, уже изменилась! Поэтому очень коротка порой жизнь у пьес. А автор, когда пишет пьесу, должен писать ее, как говорится, на века. Так, чтобы мы, ставя ее в 1969 году, могли поставить ее и в 1979 году, и в 2009 году даже!

Вот возьмите «Шестое июля». Вот пьеса какого масштаба! В ней судьба государства решается. А разве в наше время нет сложных проблем? Ведь жизнь продолжается! Нет, поверхностный конъ-

юнктурный взгляд на действительность с подлинным искусством несовместим. Несовместим он и с нашим партийным отношением к явлениям жизни. Мы должны воспитывать подрастающее поколение не на мелкотемье, а на больших полотнах, где решается судьба моего завода, моего колхоза, моего института… Моего, моего! Мы должны воспитывать молодежь на образах людей страстных, обаятельных, сомневающихся, убежденных — всяких! Но всюду, играем ли мы героя положительного или отрицательного, маяком для нас должна являться гражданственность. Надо понять, что без масштабных, острых, подлинно партийных произведений нельзя воспитывать молодежь. Телевизор, гитара, развлекательная комедия — отлично! Надо веселить, но нельзя только веселить! И нельзя проходить мимо больших социальных проблем времени.

Становишься старше, и все труднее работать. Все больше ответственности. Растет зритель. Должен расти и драматург, и актер. И должен быть на голову выше зрителя. Зритель не любит повторений. Значит, надо искать какие-то другие формы, другие средства. Я уже несколько десятков лет на сцене. И тогда, и сейчас знаменем нашего искусства был и есть реализм. Но все течет, все меняется. Мы не можем уже сейчас подряд говорить по две-три страницы текста. Жизнь требует более энергичного, живого диалога, мы не можем, и не строим теперь на сцене дворцы, чтобы зритель пришел посмотреть лишь декорации… Новаторство должно быть. Обязательно. Необходимо. И в ритмическом отношении, и в оформлении спектаклей, и в мизансценических решениях. Тридцать лет назад, например, театр ставил пьесу Тази Гиззата «Кыю кызлар». В этом году мы ее поставили снова. И — совершенно другое решение. Современное. Режиссер по-новому прочел пьесу. И что самое главное, пьеса лучше доходит до зрителя, зритель больше ее понимает. Меняется жизнь, меняются и приемы, и внутренняя техника актера. Актер становится гибче, изобретательней. И вот здесь проблема для актера — быть всегда современным, не отстать, не остаться сзади. Не догонишь!

В театре у нас сейчас талантливая молодежь. На редкость талантливая. Молодые актеры уже доказали это своими работами. Поглядите спектакли, где играют Ренат Тазетдинов, Гульсум Исангулова, другие. Я верю им. И верю в них, в их будущее. А значит, и в будущее театра. Сцена не любит ячества. Каждая роль — это кровь сердца, души твоей, это нервы. Каждая настоящая роль — это и большая школа жизни. Сцена учит актера любить людей, учит его видеть красоту жизни, а через нее, любовь эту, учит находить и свои собственные ошибки…

Журналистам приходится интервьюировать самых разных людей. По разным поводам, по разным проблемам. Но, право же, такое наслаждение интервьюировать Актера… Я был не только слушателем, но и зрителем. Актер есть актер. Вот он говорит и тут же, неудержимый в своем темпераменте, вскакивает, и я уже не узнаю его. Два-три неуловимых штриха, и меняются черты лица, интонация, выражение глаз… Это уже герой пьесы, о котором он только что рассказывал.

…Театр. Медленно погаснет в зале свет, и мы увидим Актера. Увидим лицедея, мага, человека интереснейшей профессии, творящего жизнь на сцене. И в нем, маге, увидим самих себя, наши собственные боли и радости, наши собственные размышления о мире и о том, что есть мы в нем, нашу собственную жизнь… А увидев, поймем, что Актер есть всегда сын своего времени, наш современник…

*** * ***

***<u>Шәүкәт Биктимеров</u>***

*СССРның халык артисты, Татарстанның*
*Г.Тукай һәм РСФСРның К.Станиславский исемендәге*
*Дәүләт премияләре лауреаты*

## ЗАМАНЫНДА ТЕАТРНЫ ТОТКАН КЕШЕ

Фуад абый әйбәт, матур кеше иде. Акыллы, фикерле, фәлсәфә кора белә. Кеше буларак бик «доступный», гади, шаян, юмор яратучан, искиткеч эмоциональ. Заманында ул театрны тоткан кеше. Ләкин анда мин-минлек хисе юк, актер актерыч түгел. Ул беркайчан да пычрак, әшәке анекдот сөйләмәс. Яшьләргә ярдәм итә иде. Марзушына тугрылыклы, гаиләсендә бик намуслы, әдәпле. Улы Рөстәмне, киленен, оныгын үлеп ярата иде.

Фуад абый беркем белән дә конфликтка кермәде, беркемне дә яманламады, роль өчен талашып йөрмәде. Бервакыт, Н.Исәнбәтнең «Зифа»сын куя башлаганда, Чураев ролен Халитов белән Хәким Сәлимҗановка бирделәр. Шул рольдән Фуад абый баш тартты — «Сәлимҗанов үзе генә уйнасын» дип. Ә алар — Сәлимҗанов, Гафуров, Колбарисов, Халитов дуслар иде. Ул көнче дә түгел иде.

Олыларны, аеруча Хәлил Әбҗәлиловны бик ярата, хөрмәт итә, аңа «Хәлил абый» дип endәшә, ә яшьләрне «улым», «кызым» дип йөртә иде.

Фуад абый заман, чын совет кешесе, идейный коммунист булды. Аның бер яраткан сүзе бар иде — «попутчиклардан саклан». Кайсы вакытларда ул күз яшьләре белән: «Мин бит заводта тире кыручыдан СССР халык артисты булдым», — дия иде. Аны Марсель Сәлимҗанов бик яратты. Ул хәтта бер иҗади сызык сызды — актер осталыгы дәвамы — Шакир Шамильский, Фуад Халитов, Ринат Таҗетдинов.

Актер буларак тиз кабынып китә иде, биргән рольгә, уйный торган образга балаларча ышанучан. Аның бөтен геройлары сәхнәдә уйлый белә, фикер йөртә. Үзе бик табигый, тормышчан актер булганга, башка артистларның уенында фальшьны тиз тотып ала иде.

Фуад абый бик күп уйный иде — төп рольләрне дә, эпизодикларны да. Ул үзен кызганмый, һәр рольгә бирелеп, аның эчтәлегенә төшенеп уйный. Минем исемдә аның бик күп иҗат иткән образлары. Алар эчендә театрда вакыйгага булып яңгыраган искиткеч шәп, тормышчан, тирән фикерле Шадрин — «Мылтыклы кеше», Сәгъдетдин — «Шамил Усманов», Прибытков — «Соңгы корбан», Муса — «Муса Җәлил», Рисположенский — «Агай-эне ак мыек», Ат карагы — «Зәңгәр шәл». Фуад абыйның рольләренә тамашачы яратып кул чаба, ихлас күңелдән кабул итә. Алар турында бик әйбәт пресса бар, безнең Татарстанда гына түгел, ә Мәскәүдә, Ленинградта, Урта Азиядә, Казакъстанда, Башкортстанда.

Халитов киң диапазонлы артист иде, шул ук вакытта беренче чиратта «социаль герой» иде. Соңгы елда ул Талановны (Л.Леонов «Ябырылу») уйнарга хыялланды, «шуны уйнап калыйм инде» диде, ләкин насыйп булмады...

Мин театрга килгән елларны Фуад абыйга мөкиббән киткән кеше идем, аның актерлык сыйфаты миңа бик зур тәэсир итте. Шуңа күрә аңа охшатып уйный да башладым, аның карлыккан тавышы белән сөйләшергә дә тырыштым. Ләкин шуның белән үземә зарар китердем. Чөнки һәр актер үз юлын табарга тиешлеген аңладым.

Фуад абый олы җанлы шәхес булып калды!

***<u>Нәҗибә Ихсанова</u>***

*Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе*
*лауреаты*

**ФУАД АБЫЙ**

Миңа калса, Фуад абыйда адәм баласына хас бөтен сыйфатлар да бар иде. Чыгышы, нәселе муллалар нәселе белән тоташа, әтисе бик билгеле Ибраһим мулла. Халкыбызның беренче пьеса язучысы — Фатих Халиди шул ук яктан, һәм нәселе Фуад абыйларга барып тоташа. Димәк, талантлы, укымышлы нәсел. Бәлки, шуңадыр театрыбызда аеруча яхшы артист булуы белән аерылып торды. Ул тормышта да һәрвакыт үзенә игътибарны җәлеп итте. Һәрвакыт пөхтә, чиста, зәвык белән киенеп йөрер, дөрес, монда гомер иткән хатыны — Татарстанның халык артисткасы, яшьлегендә бар музыкаль героиняларны уйнаган бик тә үзенчәлекле артистка Мәрзия апа Миңлебаеваның өлеше дә бардыр. Аларның икесенең Горький урамы буйлап парлап театрга килүләре хәзер дә күз алдында тора. Без аларга сокланып карый идек. Киемнәренең төсләре аңа гына хас, кара-көрән төсләр аңа туры килмәс тә иде кебек. Болар барысы да аның иҗатында да чагыла: төгәл, фикерле, мәгънәле, җыйнак. Минем иң беренче күргән, игътибар иткән, хәтерләп калган рольләре — «Зәңгәр шәл»дә — Ат карагы, «Хуҗа Насретдин»да — Бики. Бу — Мәскәүдә декада вакытында. Әлеге ике спектакль театрда гел куелып торды, ләкин Фуад абый үзенчә: аның Бикие нигәдер миңа терекөмеш кебек тоела, хәзер дә шулай күзаллыйм. Ә инде Ат карагы бөтен спектакльнең ритмын бирә, шул чорны тулысы белән чагылдыра. Без театрга кайткач, «Хуҗа Насретдин» кабат куелды. Фуад абый бу юлы Хуҗаны уйнады. Мавыкты ул бу роль белән, бик тә тәмен табып уйный, безне үз артыннан ияртә иде. «Соңгы корбан»да Флор Федулычны уйнады. Спектакльне әзерләү вакытында мин һәрвакыт театрда булдым, катнаштым, чөнки миңа Юлия Павловна роле бирелгән иде. Хәзер дә бөтен спектакль исемдә, Фуад абыйның эшләү процессы хәтердә: бөтенләй бирелеп бетә, чын мәгънәсендә Юлия Павловнаны ярата, акчага сатып алса да, гашыйк булып, егетләрчә яратып өйләнергә тели.

Ныклап Фуад абый белән сәхнәдә «Миләүшәнең туган көне»ндә очраштым: сугыш инвалиды, бер аягы агач, беркемгә кирәксез, ләкин ул пөхтә, тәртипле, эчтән нуры бөрки. Бөтен сугышны ерып чыккан ташландык кеше. Бик мескен, кызганыч, ләкин эчке горурлыгы бәреп тора. Ә инде «Ирегетләр»дә мин аның хатынын уйнадым. Ул зур белгеч, дипломлы архитектор, ләкин аны аңламыйлар, аракыга якыная, аннан сердәш эзли, бәргәләнә. Хәтеремдә, ВТО* линиясе буенча Куйбышевка шушы спектакль белән барган идек, безнең театр игътибар үзәгендә булды. Бигрәк тә Фуад абый өлешенә бик күп мактау сүзләре яуды. Гомумән, бу әсәр-спектакль театр тормышында, драматурги-

ядә борылыш чоры кебек булды. Үзара сөйләшә идек: ничек безне йөртәләр, Туфанны ничек алып китмиләр — әсәрдә ачыктан-ачык сөйләшү бара, бигрәк тә Фуад абый тарафыннан акцент дөрес, образ тулы канлы.

Фуад абыйның әзерләнеп бетеп уйналмаган спектакле — Л.Леоновның «Нашествие»се. Мин аның хатыны Анна Николаевна. Берни белми, берни сизми эшләдек, Фуад абый эшкә төгәл килә, әзерлек белән, тема җитди, бар да тырышып эшли. Спектакль инде тулысы белән күз алдына килә, артистны җылыта, куанып эшлибез. Репетициягә иртәрәк киләбез, кабатлап алабыз, шунда Фуад абыем әйтә куйды: «Кызым, авырып торам бит әле, нигәдер температурам төшми». Ул миңа «кызым» дип дәшә иде. Ул бөтен көченә эшли, авырый дип башыбызга да килми. Тиздән аны больницага салдылар... Ул инде кабат театрга килә алмады. Әзер спектакльне уйный алмады. Күп уйнадык бу спектакльне, күп җирләрдә булдык, ә Фуад абый беркайчан да күз алдыннан китмәде. Һәр әсәрдә төп фикерне, төп мәгънәне Фуад абый алып бара иде. Иң арткы рәтләрдә утырып караганым бар — сүзләр ачык, фикер төгәл, ә күзләр, кап-кара күзләр — алар каян да сине — тамашачыны эзләп таба.

***<u>Наил Дунаев</u>***

*Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты,*
*Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе*
*лауреаты*

## ФУАД АБЫЙГА ХӨРМӘТЕМ БИК ЗУР

Без — бер төркем яшьләр — Мәскәүнең Щепкин исемендәге училищесын тәмамлап кайтканда, Фуад абый танылган сәхнә остасы иде инде. Ул безне якты йөз белән каршы алды һәм бөтен егетләргә «улым» дип эндәшә иде.

Минем әле дә күз алдында аның 1960–1970 елларда уйнаган онытылмаслык рольләре. Әйтик, Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ында шаккатыргыч хәйләкәр Бикие һәм А.Островскийның «Соңгы корбан»ында Прибытков. Икесе ике төрле, бер-берсенә охшамаган образлар. Беренчесе көлкеле, кызыклы бәндә булса, икенчесе драматик югарылыктагы, акыллы, тыйнак, күптөрле буяулар белән сурәтләнгән көчле шәхес.

Фуад абыйның бик күп рольләрен — Әхтәм (Т.Миңнуллин «Ир-егетләр»), Ат карагы (К.Тинчурин «Зәңгәр шәл»), Мәрвән (Р.Халид «Синең урыныңа кайттым»), Арсланов (Д.Вәлиев «Намус хөкеме»), Карлос Бланка (Г.Боровик «Канлы күләгәләр») һ.б. — мин мәшһүр француз артисты Жан Габен иҗат иткән образлар белән чагыштырыр идем.

Фуад абый һәр ролендә катлаулы характер бирә белә иде. Әйтик, шул ук бик уңышлы уйналган, тамашачыны шаккатырган Әхтәм. Ул кешенең амплитудасы бай. Бер яктан Әхтәм кимсетелгән, изелгән, мораль яктан тәмам таркалган булса, шул ук вакытта ул йомшак кеше. Ул — заманында танылган архитектор. Шуңа күрә архитектура турында сүз чыкса, Әхтәм җанлана, күзләрендә утлар уйный башлый иде.

Фуад абый борынгы тормышны, ул вакыттагы кешеләрне, аларның гореф-гадәтләрен, көлүләрен, шаяруларын яхшы белә иде. Шуңа күрә Г.Камал әсәрләрендә уйнаганда, аның геройлары бик гади, табигый, тормышчан чыга иде. Гомумән, Фуад абый бик киң диапазонлы актер булды. Ул яшь егетләрне дә, ак сакаллы картларны да, мөлаем кешеләрне, усал, ямьсез бәндәләрне дә бертигез дәрәҗәдә яхшы итеп уйный иде.

1973 елда Г.Камал театры А.Островскийның «Агай-эне ак мыек» спектаклен Костромада, рус драматургына багышланган фестивальдә күрсәтте. Шул спектакльдә Халитов — Рисположенский, мин — Подхалюзин. Костромада Мәскәү тәнкыйтьчеләре, атаклы Рус кече театры, — ул театрны Островский йорты дип йөртәләр, — бик күп башка өлкәләрдән, республикалардан спектакльләр белән килгән артистлар, режиссерлар бар иде. Ләкин 1 нче премияне, дипломны без алдык — режиссер М.Сәлимҗанов, Ф.Халитов һәм мин. Фуад абыйның Рисположенские бөтенесен шаккатырды. Ул, русча әйтмешли, «мастер класс» уздырды.

Шул ук Костромада бик кызыклы бер хәл булды. Театрны туку фабрикасы кунакка чакырды. Бездән банкет вакытында берәр номер кирәк иде. Шунда Фуад абый берүзе Т.Гыйззәтнең «Чаткылар» әсәреннән иң көлкеле сәхнәне, андагы рус тикшерүчесенең татар әбиеннән староста ярдәме белән сорау алу күренешен уйнады. Рус тукучылары да, без үзебез дә эчебез катып көлдек.

Фуад абый спектакль уйнаганда беркайчан да үзен беренче рәткә чыгармый, режиссер кушкан сурәтне бозмый. Атаклы артист булуына карамастан, Фуад абыйда мин-минлек хисе һич юк иде. Ул, искиткеч импровизатор буларак, репетиция вакытларында режиссерларны канатландыра, аларга дәрт бирә. Аны Марсель Сәлимҗанов бик ярата иде. Фуад абый авырып театрга килми башлагач, ул көн саен диярлек өенә хәлен белергә барды.

Фуад абый сөйкемле, актив кеше, конфликтларга керә торган артист түгел иде. Балалар яратучан, алар белән шаяра, шуннан ләззәт таба. Яшьләрнең эшен күрә белә, аларны канатландыра, кирәк вакытта ярдәм итә. Ул беркайчан да, яңа спектакльне карагач яки яңа пьеса укыгач, үз сүзен әйтмичә калмый иде. Аның бер яраткан сүзе бар иде — «форточка җитми», ягъни әсәрдә яктылык җитми.

Фуад абыйның соңгы көннәрендә без — артистлар — аның янына бара идек. Безне күреп шулкадәр шатлана, яшәреп киткәндәй була иде. Һәм бөтен сораулары фәкать театр турында — нинди яңа пьесалар, спектакльләр, театр ни хәлдә, гомумән, театр ничек яшәргә тиеш — үгет-нәсихәт. Соңгы сәгатькә хәтле театр, театрның халәте...

Минем Фуад абыйга хөрмәтем бик зур.

***Әнвәр Гобәйдуллин***

*Татарстанның халык артисты*

Мин Фуад абыйның сәләтенә гашыйк кеше идем. Ул искиткеч эмоциональ артист. Геройлары эчтән янып торалар, һәм аның диапазоны бик киң иде. Әйтик, бер үк чорда ул капма-каршы образлар иҗат итте. А.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр»ендә — яшь, көчле хисләр кичерүче провинциаль артист Незнамов һәм Н.Погодинның «Мылтыклы кеше»сендә — крестьян, беренче бөтендөнья сугышындагы олы яшьтәге окоп солдаты Шадрин. Ике образны бик шәп итеп уйный.

Фуад абый яшьтән үк картларны да, яшь кешеләрне дә уйнады, аларның бөтенесендә төрле-төрле характерлар. Андый артистларны мин бик яратам. Шунысын да искә төшерергә кирәк — ул олы, авторитетлы актер булуына карамастан, бернинди рольдән дә — зурысыннан да, кечесеннән дә баш тартмый иде.

1960 елларның ахырында мине Әһлиулла, Хәйрулла рольләренә (Т.Миңнуллин «Миләүшәнең туган көне», Н.Әсәнбаев «Канат җәйгәндә») Фуад абыйның дублеры итеп куйдылар. Һәм мин аның белән горурланам.

Кеше буларак Фуад абый бик гади, һәрбер кеше белән уртак тел таба иде. Без аның белән вә бер төркем артистлар, — 1960—1970 елларда «бригада» дип атала иде, — бик еш Татарстан районнарына, колхозларга гастрольгә чыга идек. Фуад абыйның оештыру сәләте булганы өчен, аны җитәкче итеп җибәрәләр. Районга чыккач ук инде райком секретарьлары, колхоз председательләре белән әйбәтләп сөйләшеп, тамашаны оештыра.

Гомумән, Фуад абый тынгысыз кеше иде, шаярырга бик ярата, аның белән күңелсез түгел...

Фуад абыйның гаиләсе матур. Ул үзенең Марзушын (Мәрзия апаны — хатынын — Марзуш ди иде), улы Рөстәмне, килене Фәнияне бик ярата иде. Берзаман Фәния авыргач, Фуад абый аны үз кызы шикелле итеп карады, дәвалады. Бик кешелекле дә иде Фуад абый.

Үзе авырый башлагач, ул ашый алмады. Ләкин зарланмады, чыраен сытмады, ачык йөзле булып калды. Авыруына карамастан, һаман театр эшләре белән кызыксынды, хәер-фатихасын биреп калдырды...

***Рауза Хәйретдинова***

*Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты*

## ОНЫТЫЛМАС ШӘХЕС, ЯКИ ЗУР ТАЛАНТ ИЯСЕ

Татар театр сәнгате үстерүгә зур өлеш керткән, тамашачыларның мәхәббәтен казанган, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының олы талантлы артистларының берсе дип Фуад Ибраһим улы Халитовны әйтер идем. Мин 1946 елдан башлап театр каршындагы студиядә укыганда, театрның сәхнә йолдызлары белән аралашып, ә инде 1948 елдан театрда артист булып эшли башлагач, алар белән партнерлар булып уйный башладым.

Фуад абый табигать биргән таланты, хезмәт сөючәнлеге һәм тырышлыгы белән гади эшчедән татар профессиональ театр сәхнәсенең зур остазына кадәр күтәрелә. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында иҗат итә. Һәм бу театр сәхнәсендә аның таланты, сәләте тулысынча чәчәк ата.

1947 елда Н.Погодинның «Мылтыклы кеше» спектаклендә аның авыл кешесе, җирле крестьян Шадрин образын иҗат иткәнен хәтерлим. Фуад абыйның сөйләве буенча аңа бу катлаулы образ бик авыр бирелгән. Бары тик бер олы яшьтәге солдат белән очрашып, аның үз-үзен тотулары, киемнәре, сөйләмнәре белән танышканнан соң гына Шадрин образын күз алдына китерә башлаган. Искиткеч уңышлы образ туган һәм Фуад абый аны бик яратып уйнаган.

Фуад абыйны искә алганда, аның турында язганда, минем аның белән партнерлар булып уйнаган спектакльләрнең кайберләренә тукталып китәсем килә.

1952 елны куелган «Галиябану» спектаклендә мин Галиябануны, ә Фуад абый Исмәгыйльне уйнады. Мондый олы талантлы артист белән уйнау бик җаваплы һәм куанычлы иде. Бу миңа зур тәҗрибә дә бирде.

Аннан соң Н.Исәнбәтнең «Рәйхан»ында ул — Моратны, мин — җырчы кыз Ләләне, Ш.Шахгалинең «Таң атканда» мин уйнаган Гөлбикәнең яратып йөргән егетен — Иршатны, Г.Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» спектаклендә мин — Гөлбануны, ә ул — Яучы картны, Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр»ендә — Әхтәмне, ә мин Гайшәне уйнадык.

«Ир-егетләр» спектаклендә Фуад абый катлаулы Әхтәм образын бик уңышлы башкарды һәм Мәскәү тәнкыйтьчеләре тарафыннан бик югары бәя алды.

Ул иҗат иткән уңышлы образларның берсе дип М.Әмирнең «Миңлекамал» спектаклендәге райком секретаре Гыйльманов образын әйтер идем. Сугыш вакытындагы авыр елларда кешеләрнең хәлләренә керә белүче, искиткеч оештыручы, җитәкче Гыйльманов образын ул үзенчәлекле иҗат итте. Мин бу спектакльдә, секретарь кыз Венера булып, Фуад абый белән уйнау бәхетенә ирештем һәм аның образның эчке кичерешләрен нинди осталык белән чын тормыш дөреслегендә бирү сәләтен күреп, сокланып күзәтә һәм өйрәнергә тырыша идем.

Бу спектакль 1957 елда Мәскәүдә үткән сәнгать декадасында бик зур уңыш белән барды. Шулай ук бу декадада Фуад абыйның В.Шекспирның «Король Лир» спектаклендә Кент образын уңышлы башкаруын әйтеп китмичә булмый. Аның бу башкарган ике образы да Мәскәү сәнгать белгечләре тарафыннан югары бәяләнде һәм газета-журналларда мактап язылды.

Шул ук 1957 елда Фуад Ибраһим улы Халитовка «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Фуад абыйның төп рольләрне уйнаган барлык спектакльләрендә партнер буларак катнашмасам да, мин өлкән талантлы артистларның уйнавын һәрвакыт читтән күзәтеп бара идем һәм, аларның уеннарын карап, артистның ничек катлаулы образлар иҗат итүләрен өйрәнергә тырыша идем. Фуад абый кебек ул чордагы олы талантлы артистларны театрның тарихы дип әйтергә була.

Фуад абыйның 1957 елны куелган «Муса Җәлил» (Н.Исәнбәт) спектаклендәге Муса образын башкаруын һич оныта алмыйм. Буш сүз сөйләшми, тавышка кормый. Ул сүз әйткәнче күзләре белән фикер йөртеп, аннан соң гына сүзләрне йөрәге аша үткәреп, Мусаның эчке кичерешләрен тамашачыга җиткерә иде.

Фуад абыйның иҗат тормышында рус һәм татар классикасы спектакльләрендә тудырган онытылмаслык уңышлы образларын сөйләп тә, язып та бетерерлек түгел. Бары тик М.Горькийның «Дошманнар» спектаклендә Скроботов, А.Островскийның «Соңгы корбан»ында Прибытков Флор Федулыч, К.Тинчуринның «Американ» комедиясендәге Шәехмирза образларын искә алу гына да бик уңышлы булыр.

Шул ук вакытта Фуад абыйның Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясендә Бики образын искиткеч уңышлы башкаруын әйтмәсәң, гафу ителмәс иде. Ә менә К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» мелодрамасында Фуад абый тудырган ат карагы Минһаҗ образы турында аеруча әйтеп китәсем килә. Кыска гына итеп әйтсәк — әсәрдә чын ат карагы үзе сәхнәгә килеп керсә дә, шулай Фуад абый шикелле оста уйный алмас иде.

Фуад абый тормышта бик шаян кеше иде. Бервакыт мин театрга килгәндә, аның каршыма чыгуын һич оныта алмыйм. Минем янга килеп җиткәндә аягы белән сөртенеп, чак кына егылмый калды. Ә мин шул вакыт, ул җиргә егылмасын дип тотып калыйм дигәндә, ул кинәт шаркылдап көлеп китеп барды. Чөнки аның шулай шаярта торган гадәте булган икән. Тик торганда элекке картлар шикелле сикерә-сикерә биеп китә иде.

Фуад абый кешеләргә карата мәрхәмәтле, кешелекле, ярдәмчел булды. Бу уңайдан тагын бер үзем белән булган вакыйганы искә төшереп китәсем килә. 1949 елны мине беренче мәртәбә гастрольгә алып чыгарга булдылар. Миңа кечкенә генә роль биреп, ярдәм йөзеннән аз гына булса да акчасы булыр дип кассада билет сатарга йөкләделәр. Фуад абый гастрольдәге коллективның җитәкчесе иде. Мин, гастрольгә чыгу белән, бизгәк авыруы белән авырый башладым, температурам 40° ка җитә, дер-дер киләм, бизгәк тота. Көндезен билет сатарга, кичен спектакльдә уйнарга кирәк. Кирәкле дару табу бик кыен. Менә шул вакытта Фуад абый миңа каяндыр, эзләп, бизгәктән эчә торган дару табып кайтарып бирде, һәм шуның аркасында мин берничә көннән авырудан, бизгәк тотудан туктадым.

Фуад абый Халитов татар театры сәхнәсе йолдызларының берсе иде. Театрыбызның 100 еллыгына кадәр яшәмәсә дә, 45 ел сәхнәдә иҗат итү дәверендә татар театры үсешенә бик күп өлеш керткән кеше.

Ул үзенчәлекле талантын, реалистик осталыгын, актер буларак гаҗәеп сизгерлеген, бай рухи дөньясын үзебезнең театрга багышлады.

Фуад абый яшь буын артистларын ярата һәм аларга ярдәм итә иде. Шул ук вакытта ул бервакытта да үзешчән сәнгать коллективлары белән элемтәсен өзмәде, күп еллар буе алар белән җитәкчелек иткән, аларга һәрвакыт булышкан кеше. Үзенең бер мәкаләсендә болай дип язган иде: «Үзешчән сәнгать — зур елгага коючы инеш ул. Аннан театр училищеларына, театр вузларына яшь көчләр килә. Уку йортлары аша профессиональ сәнгатькә юл яралар».

Фуад абый гадәттә бик күп сөйләшми, килешмәгән анекдотлар сөйләүгә катнашмый иде. Ул бары тик җаны-тәне белән театр сәнгатенә бирелеп яшәде.

Фуад Халитовның театр сәнгатенә биргән күпьеллык бай иҗади хезмәтләре хөкүмәтебез тарафыннан зур бәяләнде, һәм 1975 елны аңа «СССРның халык артисты» дигән югары исем бирелде.

Безнең театр коллективы, тамашачыларыбыз Фуад Халитов кебек олы талантлы артистларны онытмыйлар, һәрвакыт горурланып искә алалар.

***<u>Асия Галиева</u>***

*Татарстанның халык артисткасы*

## ХАЛЫК АРТИСТЫ

Һәрбер профессиянең үзенә генә хас нечкәлекләре, үзенә генә хас моментлары бар. Артист профессиясе бигрәк тә үзенчәлекле.

СССРның халык артисты Фуад Халитов — киң диапазонлы артист. Аны комик артист дип тә әйтеп була, трагик дип тә. Аның төрле-төрле характерда уйнаган рольләре татар, рус пьесаларында, чит ил драматургиясендә — Г.Камал, Н.Исәнбәт, К.Тинчурин, В.Шекспир, А.Островский, М.Горький һәм башка бик күп язучыларның әсәрләрендә. Шул ук вакытта ул бүгенге көн драматургиясендә дә җаваплы рольләр уйнаган артист.

Миңа аның белән бергә партнер булып шактый күп спектакльләрдә уйнарга туры килде. Н.Исәнбәтнең «Гөлҗамал»ында ул — Хафиз, мин — Гөлҗамал, Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр»ендә, С.Җамалның «Фатыйма Сабри»да, Х.Вахитның «Рәхим итегез»дә һәм башка спектакльләрдә. Үзе белән уйнаган артистларга ул бик игътибарлы булды, бигрәк тә яшь артистларга карата.

Фуад абый турында «ул — характерлы артист» дип тә әйтергә була, һәрбер образга карата тиешле грим, костюм, сөйләү, йөрү манерасын таба иде. Сатирик рольләрне гаҗәп оста уйный иде. К.Тинчуринның «Американ» спектаклендәге Шәехмирза ролендә уйнаганын һич оныта алмыйм. Бу спектакльдә аның роле кечкенә иде, ләкин ул аны зур осталык белән, оныта алмаслык итеп башкарды. Әйтергә кирәк, Фуад абый эпизодик образларны да яратып уйнады. Аның Шәехмирзасы карлыккан тавыш белән сөйли, кызык итеп йөри, чалбар балтырының бер ягы озын, икенчесе кыска, ярым пеләш чәче тузгыган. Бу образ чын сатирик образ иде.

Ә менә Т.Миңнуллинның «Ир-егетләр»ендә Фуад абый төп рольне — Әхтәмне уйнады. Бу бөтенләй башка характердагы роль. Ул тормышындагы ялгышлары турында, гаделлек турында уйлана. Бу драматик образ.

Мин Г.Камал театрына 1950 елны килдем. Фуад абый, әлбәттә, бу вакытта күп рольләр уйнаган артист, мин аларны күрмәдем, шулай да бер вакыйганы оныта алмыйм.

1950 елда атаклы артист Зәйни Солтановның иҗат кичәсе үткәрелде. Зәйни абый ул вакытта театрда эшләми иде инде. Без, яшьләр, машина белән Зәйни абый ята торган больницага аны алып кайтырга дип киттек. Ул кичә мәңге онытылмаслык булды. Анда Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская, Гөлсем Камская һәм Фуад Халитов катнаштылар. Татар театрының бөек артистлары. Алар бөтенесе күз алдында мәңге калдылар. Шул кичәдә Фуад абый «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектаклендәге бер өзектә Приказчик ролендә чыгыш ясады. Комик роль. Аның уены хәзер дә күз алдында. Бу өзектә ул Г.Камская белән уйнады, Фуад абый — Приказчик, акча саный: бер сум, ике... тугыз... Гөлсем апа сикереп куя — «ай, ай, ай» дип. Алар шулкадәр оста уйнадылар — бөтен зал шаркылдап көлде.

Комик рольләрдә гаҗәеп оста уйный иде ул. Шуңа күрә аны күбрәк комик артист дип йөртәләр иде.

Фуад абый һәм аның хатыны, сәхнә партнеры Мәрзия Миңлебаева да бүген юк. Мин аларга бик рәхмәтле. Яшьләргә карата, бигрәк тә миңа карата бик игътибарлы иделәр. Мине яраталар иде. Мин уйнаган образларга карата мактау сүзләре, фикерләрен әйтәләр иде. Актрисага, бигрәк тә яшь актрисага, андый сүзләр бик кирәк. Алар тагы да көч, илһам бирә.

Фуад Халитов — бөтен тормышын театрга багышлаган кеше. Һәм театр тарихында иң мактаулы урында тора.

***<u>Фирдәвес Хәйруллина</u>***

*Татарстанның халык,*
*Россиянең атказанган артисткасы*

## ФУАД АБЫЙНЫҢ МАРЗУШЫ

СССРның халык артисты Фуад Халитов үзенең яраткан хатынына «Марзуш» дип эндәшә иде. Мәрзия апа иркәләп-назлап эндәшүгә, хөрмәткә һәр яктан лаек ханым иде шул.

Аның исемен атауга ук күңелгә чисталык, уңганлык, пөхтәлек, пакьлек кебек хатын-кызны зурлый торган төшенчәләр килә. Моңа тагын бик тәмле камыр ризыклары пешерүче, гомумән, искиткеч аш-су остасы булуын да өстик.

...Кеше буларак та, актриса буларак та шундый гүзәл сыйфатларга ия иде ул. Хәер, ире — бөек артист Фуад Халитовны чын мәгънәсендә саклап, кадерләп, бала караган кебек хасиятләп яшәтүе белән генә дә бу дөньялыкта бөек миссиясен үтәгән булыр иде. Чөнки талант юкка чыкмасын, фаҗигале язмышка дучар булмасын өчен, аны саклый да белүче кирәк. Мәрзия апа да Фуад абыйны «яшел елан» агуыннан саклап кала алды.

Әйе, ул — чын татар хатыны. Ирне беренче планга куеп, зурлый белә торганы. Ярату һәм ятарылу бәхетенә ирешә алган ханым.

*Апрель, 2001*
(«Юксыну» китабыннан)

**<u>Матбугат битләреннән</u>**

Яшь көчләребез Халитов белән Миңлебаева иптәшләрнең Ромео һәм Джульетта рольләрендә чыгышларын уңышлы адым дип хисапларга кирәк. Суга кермичә йөзеп булмый, диләр. Ә Шекспир — диңгез. Миңлебаева да, Халитов да диңгезгә керделәр һәм аннан йөзеп чыктылар. Бу хәл — яшьләрнең үсүе дигән сүз.

(Гөлшат К. Ромео һәм Джульетта татар сәхнәсендә. Яшь сталинчы, 17 ноябрь, 1940.)

*** * ***

Хөснетдиннең реаль сурәтен, җанлы табигатен артист Ф.Халитов искиткеч осталык белән күз алдына бастыра. Хөснетдин обыватель булып гәүдәләнә, сай карашлы булуы ачыла, «миңа кагылма, мин үземә тигәнне кичерә алмыйм» дигән бик примитив фәлсәфәгә нигезләп көн күрүе беленә. Халитов — татар театрының талантлы артисты. Ул туктаусыз уен техникасын үстереп килә. «Аталар яшьлеге»ндә ул Антонның мөлаем образын бирсә, «Миңлекамал»да кылый Хәлимнең дошман табигатен ача. Бу образлар төрле характерда, төрле омтылышларда һәм төрле сыйныф кешеләре. Халитов шул төрлелек эчендә буталып калмый, ул образларның үзенә хас дөньясын җанлы һәм катлаулы итеп күрсәтә белә.

(Кашшаф Г. Хаҗи әфәнде өйләнә. Совет әдәбияты, 1944, № 11.)

*** * ***

Артист Фуад Халитов иптәшнең зур талант иясе икәнлеге кылый Хәлим образында тагын бер тапкыр күренде. Тискәре образны башкаручы артист ул типның явызлыгын барлык нечкәлекләре белән ача алса гына, бу образга тамашачының нәфрәте туа ала. Халитов иптәш менә шул максатка ирешә алган. Бу аның иҗат көче...

(Насрый Г. Миңлекамал. Кызыл Татарстан, 13 май, 1944.)

*** * ***

Кыюсызлык катыш мавыгудан башлап киткән Салихов-Халитов үзе дә рәтләп сизмәстән һәм ничектер тамашачыга да сиздермәгән кебек, әллә ничек бик табигый, бик тормышчан итеп разведчиклар арасында үз кеше булып китә һәм шулай оста гына итеп тамашачының күңеленә дә кереп утыра.

(Хөсни Ф. Серләр. Кызыл Татарстан, 27 ноябрь, 1948.)

*** * ***

Сәүдәгәр Бики образын Татарстанның атказанган артисты Фуад Халитов мактарлык осталык белән күрсәтте. Бики бай саран, комсыз, ялагай һәм куркак, тормышка карашы түбән һәм тар... ул тү-

бән җанлы, акылга ярлы бер кеше булып гәүдәләнә. Халитов иптәш бу рольне бик дөрес аңлап, игътибарны җәлеп итәрлек характерлы образ иҗат иткән.

(...Хуҗа Насретдин. Кызыл Башкортстан, 18 июль, 1950.)

* * *

Профессиональная культура Халитова, его глубокое понимание душевного мира человека, гражданское мужество советского актера помогли донести до зрителя лучшие черты татарского национального героя Мусы Джалиля.

(Кормушина Г. По пути исканий. Литература и жизнь, 6 июля 1958.)

* * *

Спектакльдә сурәтләнгән вакыйгалар дәвамында зур үсешкә ирешкән халык массасы вәкилләрен күрсәтү җәһәтеннән авыл карты Сәгъдетдин образы бик тә колоритлы. Башта батальонга «мөселман батальоны» дип аталган өчен генә килгән, үзе белән комганын да калдырмаган бу карт крестьян кыска вакыт эчендә чын көрәшче булып әверелә. Әсәрнең соңгы өлешендә, Оренбург байлары һәм Дутов солдатлары белән очрашканда, мәсәлән, ул үзен чын большевикларча тота. Бер яктан үтә гади һәм кешеләргә тиз ышанучан булып күренгән, ә кискен моментта нык ихтыярлы бу кешенең бөтен эчке күркәмлеген РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Фуад Халитов бөтен тулылыгында ача. Дутовчы офицерның, татар батальонын мыскыл итәргә теләп: «Менә шушы карт аларның гвардеецлары, ә комиссарлары бер малай гына», — дигән сүзләренә каршы без Сәгъдетдиннең үтә тыныч итеп, шул ук вакытта зур эчке ышаныч һәм сарказм белән әйткән: «Әнә шул малай алдында йөзләгән солдатларыгыз дер калтырап торалар», — дигән сүзен ишетәбез. Шулай ук аның ахыр сулышында: «Большевик иптәшләрен сатмый», — дигән репликасы да җиңүче-сугышчының анты булып яңгырый.

(Сафуанов С. Кызыл таң. Уфа, 1968.)

***<u>Хәким Сәлимҗанов</u>***

*Татарстанның халык артисты*

## ТЫНГЫСЫЗ ЙӨРӘК

*РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Фуад Халитовка 50 яшь тулу уңае белән*

Совет сәнгате алдына куелган бурыч бик ачык билгеле. Ул тормыш белән бергә нык бәйләнеп, үрелеп үсәргә, халыкка хезмәт итәргә тиеш. Хәзерге көндә һәрбер артист, режиссер, художник алдында торган изге эш шул бурычны тулырак гамәлгә ашырудан гыйбарәт. Менә шушы яктан караганда артист Фуад Халитовның иҗаты аеруча характерлы. Ул үзен тәрбияләп үстергән, күтәргән халыкны бер генә минутка да исеннән чыгармый, халык белән нык элемтәдә яши. Менә ничә еллар инде Фуад Халитов театрның агитаторлар коллективына җитәкчелек итеп килә. Ул бу эш өчен янып йөри, бер агитаторның эшендә кимчелек күрсә, аны бик тиз төзәтү чарасын күрә, эшне юлга сала һәм киң катлау масса белән төрле темаларга әңгәмәләр оештыра.

Язучылар кебек үк, артистлар да халыкның тормышын, теләкләрен яхшы белергә, һәрвакыт аны сиземләп торырга тиешләр. Шундый артистлар гына чын сәхнә образлары тудыра алалар. Артист Фуад Халитов тудырган образларда аның тормышны тирәнтен белүе күзгә аеруча бәрелеп тора. Мисал өчен ул тудырган Иван Шадрин (Н.Погодин «Мылтыклы кеше») образын алып карыйк. Артистның бу иҗатын заманында вакытлы матбугат: «Бу образны башкаруы белән Фуад Халитов сәхнә сәнгатенең яңа баскычына күтәрелүен, социалистик реализм методын үз иҗатында уңышлы куллануын күрсәтте», — дип билгеләп үтте.

Ул Казан Эшче театрында артист булып эшли башлый һәм онытылмас күп кенә образлар тудыра. Ш.Камалның «Ут» әсәрендә Рәүф Моратов, Г.Кутуйның «Шатлык җыры»нда парторг Иванов һәм А.Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр»ендә Незнамов образларын сокланырлык итеп башкара. Кыска гына вакыт эчендә театрның иң күренекле артистына әверелә.

1937 елда Фуад Халитов Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрына артист булып күчә һәм, анда күп еллар эшләп, театрның атаклы артистлары сафына баса.

Фуад Халитов сәхнәдә эшләгән 30 еллык иҗади хезмәте дәверендә онытылмаслык дистәләрчә образлар тудырды. Алар арасында Ромео («Ромео һәм Джульетта»), Кент («Король Лир»), маклер

Хөснетдин («Хаҗи әфәнде өйләнә»), Мочтак («Чаткылар»), Гыйният («Изге әманәт»), Морат («Рәйхан»), Бики бай («Хуҗа Насретдин»), Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр»), Гыйльманов һәм кылый Хәлим («Миңлекамал»), Иван Шадрин («Мылтыклы кеше») образлары бар. Болар үзләре генә дә артистның диапазоны никадәр киң икәнлеген күрсәтәләр.

Фуад Халитовның артист буларак иҗади үзенчәлеге нәрсәдә соң?

Беренчедән, ул, әйтеп киткәнебезчә, киң диапазонлы артист. Әгәр без ул башкарган Ромео, Иван Шадрин, Незнамов, Гыйният образларын гына алсак та, алар яшь ягыннан гына түгел, тормыш шартлары, характерлары, халәт рухияләре, ниһаять, омтылышлары, төрле сыйныф вәкилләре булу белән бер-берсеннән бик нык аерылалар. Фуад Халитов исә бу катлаулы образларны, аларга гына хас дөньясын тулысынча саклап, гаять оста гәүдәләндерә.

Икенчедән, аның таланты үзенчәлекле булуда. Бөек артист Станиславский әйтә: «Артист һәрбер рольдә үзенең мөлаемлыгын, үзенең индивидуальлеген табарга, шул ук вакытта һич тә кабатланмаска тиеш», — ди. Фуад Халитов кабатланмый — бер карасаң очкын очыра, икенче бер образда көлке тудыра, ә кайчакларда трагедиягә килеп җитә.

Ул рольне тирәнтен аңлап, өйрәнеп эшләргә ярата. Образның эчке кичерешләрен ачуга зур урын бирә, үзенең партнерын бик яхшы тыңлый белә. Кечкенә генә, хәтта сүзсез рольне дә соклангыч иҗади хыял белән башкара. Моның җанлы шаһиты итеп Ә.Фәйзинең «Тукай» пьесасында базарда «Каранҗа догасы» сатып йөрүче күзлекле кеше образын күрсәтергә була.

Фуад Халитовның тагын бер уңай ягы шунда ки, ул, кулына роль алгач, текст белән генә канәгатьләнми, эзләнә, шуның нәтиҗәсендә образның характерын тулырак ачуга ирешә.

Фуад Халитовның татар театрын үстерүдә күрсәткән хезмәтләрен искә алып, аңа 1945 елны «Татарстанның атказанган артисты», ә 1956 елны «Татарстанның халык артисты» дигән мактаулы исемнәр бирелде. 1957 елны Мәскәүдә булып үткән Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында Фуад Халитовка «РСФСРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

*Социалистик Татарстан*
*10 март, 1958*

***Ильтани Илялова***

**ЕСЛИ БЫ ОН РАССКАЗАЛ О СЕБЕ**

Когда человеку перевалило за шестьдесят, есть о чем вспомнить, особенно если жизнь была наполнена большими событиями, если вся жизнь — труд. Труд повседневный, упорный, сделавший человека тем, чем он является сегодня.

...Далекое детство. Пожар, уничтоживший половину татарской части Казани... Медресе, где временно поселились погорельцы... Там, в этом старом медресе мальчишки и девчонки пытались ставить спектакли. И не какие-нибудь безделки, а «Бедность не порок» самого Островского.

Спектакли, спектакли... Они проходят через всю жизнь Фуада Халитова. Сначала детские, потом в кружках художественной самодеятельности, с которой он связан и по сей день...

Когда немного подрос, начал работать. И кем только не приходилось быть! То рабочим на химическом заводе, то мездрельщиком на знаменитом меховом комбинате, то расклейщиком афиш, то посыльным в том самом театре, на сцене которого впоследствии стал играть. Служил он и в армии...

Двадцатые годы, начало тридцатых — бурное время первых пятилеток, создание колхозов. Комсомолец Фуад — в гуще событий, в гуще жизни. Он работает на заводе, затем в числе двадцатипятитысячников едет в деревню — участвует в организации колхозов.

И повсюду — на заводе, в деревне, в армии — были спектакли, которые Халитов ставил и сам играл в них.

Казалось бы, все ясно, жизненный курс определен: театр, и ничто другое. И все же Халитов с улыбкой вспоминает, как он был зачислен в Ленинградский политехнический институт и как удрал оттуда ради сцены.

Театр «Эшче», что в переводе на русский значит рабочий...

Москва, куда коллектив был откомандирован на полгода, чтобы набраться ума-разума, посмотреть спектакли ведущих театров. Знакомство с выдающимися московскими режиссерами и актерами. Алексей Дмитриевич Попов, под чьим руководством создавался спектакль «После бала», Василий Григорьевич Сахновский, Владимир Вячеславович Белокуров... И сами они, молодые татарские актеры, играющие перед рабочими Москвы — автозаводцами, или в Мытищах, Подольске. Общежитие на улице Кирова, неустроенная, но счастливейшая жизнь!..

А спектакли, которые они тогда ставили! «Без вины виноватые» Островского, «Матросы из Каттаро» Вольфа, «Галиябану» Файзи. И агитки, агитплакаты, в которых молодые актеры добивались большого успеха у зрителей.

Газета «Красная Татария» писала: «В 1931 году шесть любителей, пришедших прямо с производства, выступали... в рабочих клубах, на строительных площадках — с живой газетой, скетчами и другими эстрадными номерами. Все богатство этой несложной труппы составляла гармонь. Так зарождался Татарский государственный рабочий театр».

Это о нем, Фуаде Халитове, и его товарищах...

Рабочий театр!.. Много доброго посеял он в душах своих зрителей. А как было трудно порой! Особенно в деревнях. О настоящих клубах даже мечтать не приходилось. Кое-как приспособленный для представлений обычный дом. И актеры, они же администраторы, идут по деревне от дома к дому, агитируя крестьян посмотреть их спектакль. Уговаривать надо было долго, убедительно. И только удавалось уговорить, как вылезал какой-нибудь древний старик — патриарх рода и чуть ли не за волосы тащил своих домочадцев назад, захлопнув перед носом актеров дверь.. А как актеров сейчас в деревнях встречают! Большие клубы, Дома культуры переполнены, не пробьешься. А ведь и его, Халитова, заслуга в этом есть...

Он вырос, возмужал как актер в коллективе Татарского театра драмы.

Роли, роли, роли… Их наберется не одна сотня. Персонажи разные — старые и молодые, добрые и злые, волевые и слабые, люди разных стран, народов, эпох...

Вот трагичный Незнамов... Разбитной весельчак Кудряш... Знаменитый татарский просветитель Каюм Насыри... Умный, волевой и человечный секретарь райкома Гильманов и отвратительный косой Халим из одной и той же пьесы «Минникамал» Амирова... Муса Джалиль из одноименной пьесы Н. Исанбета, озорной Ходжа Насретдин и рядом коварный, хладнокровный Николай Скроботов...

Трудно давалась Халитову роль Шадрина, хотя и очень нравилась. И вот надо же! Идея образа понятна, характер тоже, — и тем не менее Шадрин никак не становился своим. Близилась премьера. Его уже начинал охватывать страх. И вот однажды утром, когда шел в театр на репетицию, вдруг повстречался с каким-то солдатом. Это был уже немолодой человек, в старой шинели, обмотках, с тощим рюкзаком за плечами.

Окликнул его: «Ваня!», назвав первым попавшимся именем. Солдата нужно было обязательно задержать, поговорить с ним. А тот: «Я не Ваня» — и пошел дальше. Побежал за ним, остановил, что-то спросил. Слово за слово — откуда, кто... Наговорились досыта. Конечно, опоздал на репетицию, получил выговор. Но все это уже не имело никакого значения. Душа солдата была понята, — Шадрин зажил, обрел плоть и кровь. Роль стала любимой.

Сложный этот человек Шадрин, уже немолодой солдат. Задиристый, ершистый. Не простачок деревенский, а крепкий мужичок себе на уме. Потому его и заботит вначале только свое хозяйство.

Главными в роли были две сцены — с Лениным и Чибисовым. Исподлобья, угрюмо смотрит на Чибисова солдат, молчит, слушает его, а на лице — недоверие. Впервые сталкивается он с большевистской правдой. Не постиг еще ее сердцем. Невдомек ему, крестьянину, привыкшему всю жизнь оберегать свое убогое хозяйство, что можно в корне изменить жизнь. Но под влиянием слов Чибисова именно в этот момент и произошел в его сознании перелом. Шадрин вдруг обмяк, призадумался. А глаза стали уже не задиристыми, не злыми, а внимательными, зоркими.

И когда Шадрин встречался с Владимиром Ильичом, это был уже наполовину «упропагандированный» человек. Владимир Ильич вызвал его на откровенность. Шадрин, задумчивый, печальный, поделился горем своим: пала корова. Потом, встретив понимание, оживился, искренне, горячо заговорил о войне, о своих солдатских думках. Доброжелательно, с огромным интересом и вниманием слушал солдата Ильич.

Понравился Шадрину этот человек. Кто он?

— Ленин!

Остолбенел Шадрин, и такая вдруг тоска в глазах и горе: что же мне никто раньше не сказал?.. Ведь я бы ему все поведал.

И становится Иван Шадрин агитатором за Советскую власть — непреклонным, горячим.

Муса Джалиль... Очень многое в работе над этой ролью дали личные воспоминания о Мусе, близкое знакомство с ним. Трудно было даже подумать в предвоенные годы, в годы совместной работы, что поэт-лирик, жизнерадостный, добрый, веселый, улыбчивый человек погибнет в фашистском застенке. Погибнет как герой и станет всемирно известен своим мужеством, своей поэзией.

Роль делилась как бы на две части — Муса дома, на Родине, и в плену, в Германии.

...Последний вечер перед уходом на фронт. Тишина в квартире. Горит настольная лампа. Полумрак. Тепло, уютно. В комнате — Муса да маленькая больная дочка за ширмой. Молча, лишь изредка переговариваясь с дочкой, ходит он по комнате, приводит в порядок вещи, бумаги, прощаясь со

всем привычным, милым сердцу. Внешне спокоен, а внутренне глубоко сосредоточен, напряжен. Всем своим существом он уже там, на передовой.

В концлагере поэт внешне как будто оставался прежним. Только взгляд его становился суровым, твердым. В этом мягком, душевном, обаятельном интеллигенте обнаруживались качества умелого политического руководителя, коммуниста с несгибаемой, железной волей...

Немало ролей сыграно и в русском классическом репертуаре.

Казалось бы, что нового можно создать в образе Прибыткова из «Последней жертвы» Островского? Или в ролях стариков из национальных пьес, обросших сценическими штампами? Но он искал и находил что-то новое, стремясь избежать повторений.

Зрителю кажется, будто актер не прилагает ни малейших усилий, чтобы сделать образ ярким, выпуклым, запоминающимся. И только он один да еще режиссер знают, сколько пота и крови актерской потрачено, чтобы достичь этой легкости.

Конечно, не все за долгую творческую жизнь в театре было одинаково удачным, не все и не всегда получалось хорошо. Но всегда, играя положительных персонажей, Халитов стремился как можно ярче показать все благородство, чистоту устремлений своих героев, а в ролях противоположного плана — обнажить природу и корни зла. Тогда он выступал как судья — беспощадный и гневный.

Вот следователь Абдулхамит из пьесы «Фатима Сабри» С.Джамала — внешне лощеный воспитанный человек с изысканными манерами, маленькими злобными глазками и прилизанными, набриолиненными волосами. Внешне он мил, обходителен, приветлив. Но какая же низкая, продажная это душонка! Словно звериный оскал вдруг сменяет дежурную улыбку следователя, когда при допросе коммуниста Сабри он убеждается, что ничего не сможет добиться.

...Сорок лет отданы театру. Какие грандиозные события произошли за это время в мире, в стране! А как отвечали на зов времени работники искусства! Как активно вторгались они в жизнь! И хочется, чтобы театр всегда был на передовой. На линии огня. Когда тебе стукнуло шестьдесят, становишься, оказывается, особенно жадным до работы. Потому-то и не думается об отдыхе, покое, хочется одного — работать, работать, работать...

Вот примерно так, как нам кажется, рассказал бы о себе народный артист РСФСР, один из крупнейших мастеров татарского театра Фуад Халитов.

Театральная жизнь, 1970

## ПЛЕЧО ТОВАРИЩА

За широкими окнами кафе высятся громады многоэтажных домов. В кафе двое: буфетчица Салима и Ахтям — человек явно полуопустившийся, пьяница. Вскоре здесь появляется еще один посетитель. Он садится за столик, завтракает и, погруженный в свои мысли, не замечает Ахтяма. И только когда тот обращается к нему с вопросом, он поворачивается и узнает его. Бросается к нему, обнимает...

Так встречаются два фронтовых товарища, бывшие разведчики, кавалеры боевых орденов, не видевшие друг друга четверть века, — герои спектакля Татарского театра имени Г.Камала «Мужчины» Т.Миннуллина. И начинается борьба председателя колхоза коммуниста Марвена за судьбу своего фронтового друга — талантливого архитектора Ахтяма, потерявшегося в жизненных перипетиях. И то, что Марвена и Ахтяма играют замечательные мастера татарского театра А. Шамуков и Ф. Халитов, придало спектаклю, поставленному М. Салимжановым, особый накал, страстность, темперамент.

Когда-то, столкнувшись с людьми нечестными и потерпев в этой схватке поражение, Ахтям встал в позу обиженного человека, и теперь зло, с вызовом кричит о всеобщей несправедливости. Ахтям — Ф. Халитов свыкся с маской мученика. И нет у него желания одуматься, преодолеть себя, он все больше и больше погружается в терзающие его переживания. Даже когда Марвен увозит бросившего работу Ахтяма в свой колхоз, он и там продолжает с той же настойчивостью нести свой «крест».

Поначалу кажется, что у Марвена — А. Шамукова, слишком деликатного и доброго, не хватает силы воли, характера, чтобы поставить Ахтяма на ноги. Но это не так. Все, что терпеливо сносил он с момента встречи с Ахтямом в кафе, теперь подвергается им гневному обличению: бегство Ахтяма от жизни, от трудностей, трусость. Когда же Ахтям с обычным своим пренебрежением спрашивает, какое ему до него дело, Марвен — А. Шамуков с гордостью отвечает, что он ответствен за всех людей и за все дела на земле. Именно эта ответственность и заставляет его бороться за Ахтяма до победного конца.

Театральная жизнь, 1971

**СССР Верховный Советы Президиумы Указы**

*Ф.И.Халитовка «СССРның халык артисты»*
*дигән мактаулы исем бирү турында*

Совет театр сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Фуад Ибраһим улы Халитовка «СССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирергә.

СССР Верховный Советы
Президиумы Председателе *Н.Подгорный*

СССР Верховный Советы
Президиумы секретаре *М.Георгадзе*

Мәскәү, Кремль
1975 ел, 26 ноябрь

* * *

**Котлыйбыз!**

Хөрмәтле Фуад ага!

Татарстан комсомолецлары һәм яшьләре исеменнән Сезне «СССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелү уңае белән кайнар котлыйбыз. Бу — театр сәнгатен һәм Сезнең иҗатыгызны яратучы меңләгән тамашачылар өчен зур шатлык.

Г.Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә Сез, танылган сәхнә осталарының матур традицияләрен дәвам итеп, замандашларыбызны дулкынландырган йөзләрчә образлар иҗат иттегез. Республикабыз яшьләре ул образлар аша үзләрендә матур сыйфатлар тәрбиялиләр. Сез катнашкан спектакльләр яшьләрдә һәрвакыт күңел күтәренкелеге һәм иҗади хезмәт активлыгы уята.

Сез хәзер дә армый-талмый иҗат итәсез һәм, яшь буын артистларының остазы буларак, алар белән үзегезнең бай тәҗрибәгезне уртаклашасыз.

*Татарстан яшьләре*
*27 ноябрь, 1975*

***Разил Вәлиев***

## БАЛАЧАКТАН КИЛГӘН ЧӘЧӘКЛӘР

Алар урман куенына килеп җиткәндә, кояш баш очына күтәрелгән иде инде. Еракта зәңгәрсу-яшел булып күренгән урман эчкәре кергәч гел бүтән икән. Нинди генә төсләр юк монда: соргылт наратлар, ак каеннар, яшькелт усаклар, кара шомыртлар! Чәчәкләргә килгәндә, аларның исәбе-хисабы юк. Табигать фәненнән укытучы абый һәр чәчәк, һәр куак янында туктала да шундый матур, аңлаешлы итеп сөйли башлый. Меңләгән чәчәкнең исемен каян белеп бетергән дә һәр кошны тавышыннан танырга каян өйрәнгән икән ул?! Сөйли-сөйли дә аннары кинәт тынып кала.

— Туктагыз әле, туктагыз, — ди балаларга укытучы. — Урман тавышын тыңлагыз. Ишетәсезме, үзе бер симфония бит бу, урман симфониясе.

Фуад башта аптырабрак, сәерсенебрәк тора. Ләкин бар малайлар тын калып, тирә-юнь кошлар авазы белән тулгач, укытучы сүзләренең дөреслеген аңлый башлый ул. Шәһәр бакчасында да, Кабан күле буенда да кош сайравын ишеткәне бар инде аның. Ләкин бу кошлар бөтенләй башкача сайрый. Әллә чәчәк исеннән башы әйләнгән, әллә дуслары гына түгел, хәтта бар агачлар да шым калып, бирелеп тыңлаганга шулай матур төсле бу авазлар.

Экскурсиядән Казанга кайтканда, укытучы бик озак сөйләшми барды. Аннары гына сүз башлады:

— Сезнең киләчәгегез зур, балалар, — диде ул. — Кайберләрегез инженер, галим булыр, сәнгать юлы белән китүчеләр дә табылыр. Ләкин берүк минем сүзләремне онытмагыз, күңел түрегездә һәрвакыт гүзәллеккә хөрмәт хисе йөртегез, матурлыкны аңларга өйрәнегез.

Әллә инде укытучы абый сүзләре тәэсир итте, әллә кошлар сайравы күңеленә тирән уелып калды, соңгы арада Фуадка гармун җене кагылды. Абыйсы берәр җиргә чыгып китте исә, гармунны кулга ала да сәгатьләр буе шыңгырдатып утыра. Шулай азаплана торгач, көйгә охшаш авазлар да чыккалады, озакламый ул өздереп уйнарга да өйрәнде.

Көннәрдән бер көнне мәктәптә концерт куярга хәзерләнә башладылар. Җырчылар да, биючеләр дә табылды, ләкин менә нәфис сүз сөйләүчеләр генә юк. Укытучы: «Кем шигырь сөйләргә тели?» —

дигәч, Фуад берничә тапкыр кул күтәрергә талпынып та караган иде, тик кыюлыгы җитмәде. Ә укытучы барыбер сизгән, күңел күзе белән күреп торган икән. Габдулла Тукайның «Бала белән күбәләк» шигырендәге Бала сүзләрен Фуадка бирделәр.

Матур киемнәр киенеп, сәхнәгә чыгып баскач, ул башта югалып калды, тез буыннары калтырады, йөрәге дөп-дөп типте. Бәлки, тотлыгып бөтенләй телсез дә калган булыр иде, тик, каршында торган Күбәләкне күргәч, бөтен каушаулары онытылды. Залдагы яшьтәшләре дә, әллә кая китеп, юкка чыккан кебек булдылар... Әйтерсең ул урман аланына килеп кергән дә чып-чын күбәләк белән сөйләшә. Шигырь тәмамланып, зал кул чабуларга күмелгәч, айнып киткән кебек булды Фуад.

Озакламый ул Эшчеләр клубына йөри башлый. Гармунда үзе уйнап, үзе җырлый. Мәктәптәге һәр эштә дә Фуад башлап йөри... Уен-көлке, җыр-биюнең кеше күңелен күтәрүен аңласа да, ямаулы итек, ертык чалбар кигән яшьтәшләрен күргәч, күңеле әрни аның.

Фуад үзенең дусларын җыя да:

— Әйдәгез, концертны акчага куябыз, — ди. — Ә җыелган акчага ятим балалар өчен кием-салым алырбыз.

Моңа беркем дә каршы килми, билгеле. Берничә атнадан инде теге сәләмә малайларны курчак кебек киендереп тә куялар.

Мәктәптә дәресләр тәмамлануга, Фуад һәр көнне диярлек татар театрына килә. Үзе теләп шәһәр буенча театр белдерүләре тарата. Озакламый ул монда да үз кешегә әйләнә, аны һәр спектакльгә бушлай кертә башлыйлар.

Беркөнне афиша алырга килгәч, аны сәхнә артына чакыралар.

— Менә бу малайга бирсәк, ничек булыр? — ди артистларның берсе.

— Әйдә уйнап карасын.

Фуад башта берни аңламый тора. Аннары инде үзенә Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә» пьесасында нәни паж ролен бирүләрен белгәч, башы күккә тия. Режиссеры да кем диген? Кәрим абый Тинчурин үзе бит!

Шул рольдән соң ул тагын да канатланып китә. Актерлык күнекмәләре алу өчен Эшчеләр клубы каршындагы драма түгәрәгенә йөри башлый. Түгәрәк җитәкчесе Хан Җәмил аңа иң беренчеләрдән булып сәхнә әлифбасын өйрәтә.

Артист Шакир Шамильский Фуадның уйнавын карап тора да:

— Синдә сәләт бар, малай, училищега кер, — ди.

1975 елның 26 ноябрендә барча газеталарда Фуад Халитовка «СССРның халык артисты» исеме бирелү турындагы Указны укыгач, Фуад агайның хәтеренә үзе дә сизмәстән балачак еллары, кош авазларына күмелгән урман аланы төште. Бөтен эшен ташлап, шул чәчәкле аланга китәсе килде аның. Ләкин урманда көз, урманда шәрә агачлар гына. Шул турыда уйлый-уйлый, ул театр ягына таба атлады. Аның уйларын белеп торганнар диярсең, килеп керүгә котлый, тәбрикли башладылар, кулына чәчәкләр тоттырдылар. Теге урман аланындагы чәчәкләргә бик тә, бик тә охшаган иде алар.

*Ялкын*
*1976, № 1*

***<u>Әхәт Гаффаров</u>***

## МӘҢГЕЛЕК УТ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнә остасы Фуад Халитовка «СССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Үзеңнән яшьрәк булуы кыен. Моннан да кыенрагы — өлкәнрәк булу.

Фуад Халитов бүген шушындый ике яклы кичереш уртасында калган кебек.

— Эх, яшьрәк чак булса икән! — ди ул.

Нәрсәнедер тиешенчә эшли алмаганына үкенеч белән әйтми. Бүген тагын да күбрәк көч куеп, дәрманлырак итеп эшләр идем дигән мәгънәдә әйтүе.

Мин исә аның бу теләгенең үзенә гаять таләпчән каравыннан, ирешелгән белән канәгатьләнми торган холкыннан килүен күрәм.

Мондый кичереш — чын оста өчен гайре табигый күренеш. Әгәр дә миннән Фуад Халитовның сәхнәдәге уены яшьләрчә дәртле, өлкәннәрчә акыллы булуының серен сорасалар, мин моңа җавапны аның холык-фигыле, бөтен табигате халәтеннән эзләргә кирәк дияр идем.

Үз-үзеннән канәгать булмауны һәм осталыкка өзлексез омтылышны Фуад Халитов иҗат биеклегенә әйди торган баскычның басмалары иткән.

Инде менә аларның һәммәсе дә үтелгән кебек. Әйбәт йорт салынган, тукталыш ясап, беркадәр ял итәргә мөмкин шикелле.

Юк икән. Гомер сәфәрендә үтелгән кичерешләр, күрелгән манзаралар, баеган акыл һәм остарган кул тынгылык тапмый — әйтерсең лә йорт салу мәшәкатеннән әле арынып җитмәгән агай, тынгысызланып, тәрәзә яңакларына берсеннән-берсе камил һәм нечкә бизәкләр, кәрнизләргә чуар нәкышьләр тезә башлый. Һәммәсендә аның тормыш тәҗрибәсе һәм осталыгы чагыла.

Фуад Халитов та шундый гаҗәеп бер тырыш кеше. Иҗат кешесе. Сәхнәдә уйналган һәрбер яңа роль, иҗат ителгән һәм тамашачының аңына, күңеленә тәкъдим ителгән һәрбер яңа образ соңында ул, рәшәдә чагылган урманны күргән кебек, яңа персонажлар «урманы» күрә. Фуад Халитов гел эзләнә, үтелгән иҗат баскычына яңа басмалар тезә.

Ул басмалар намус белән ясалган капка, тиз онытылмасын дип язылган китап, киләчәк буын да карап соклансын дип агачлары тәртип белән утыртылган бакча сыман — озакка. Күпме яшь артист, театрның яңа алмашы атлый ул басмалардан.

— Аның һәр уены мәктәп кебек, — ди шул алмашның берсе, республикабызның халык артисты, Тукай премиясе лауреаты Ринат Таҗетдинов.

Р.Таҗетдинов үзе дә сәхнә остасы инде, ләкин хәзер дә Фуад Халитовны зур остазы дип таный, аннан өйрәнә, димәк, аның киңәш-табышына ихтыяҗлы, әҗәтле икән. Ул гына түгел, Ф.Халитовның сәхнә тормышы — иҗат лабораториясе — Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрындагы күпләр өчен мәктәп булырлык икән.

Фуад Халитов кайчандыр үзе дә бер иҗат «мәктәбенә» — СССРның халык артисты Хәлил Әбҗәлиловка табына иде. Хәлил Әбҗәлилов вафат булгач, аның эстафетасын кабул итүчеләрнең берсе була ул. Ул бөек артист уйнаган Хуҗа ролендә чыгыш ясый башлый. Әбҗәлиловча киң диапазонлы артист булып җитлегүе шул вакыттан.

«Каян килә бу?» — дип сорыйм мин үз-үземнән. Җавапны Фуад ага Халитов сүзләреннән эзлим.

— Эзләмәсә, тормышны өйрәнә белмәсә, вакыт сулышы белән яшәмәсә, халык белән бармаса, кеше язучы, артист, рәссам була алмый, гомумән, һәр хезмәт иясе үз өметенә ирешә алмый, — ди ул. — Сәнгать ул — тәмле ризык, ул чәчәк шикелле. Аңа саф йөрәк белән, чиста кул белән генә якын килеп була... Станиславский шуңа өйрәтеп калдырды... Иҗат эше шәхси эш кенә түгел бит ул...

Ф.Халитовның актерлык сәнгате — югары идеялелек, социаль типиклаштыруның үткенлеге һәм ачыклыгы, халык характерын тирәнтен аңлау, кешенең рухи дөньясын төрле яктан ачу, иҗат итү формасының тәэсирлелеге — аның менә шушы сүзләреннән башлана дип уйлыйм мин.

Бу хакта «Правда» газетасы болай дип язган иде: «Театрдан алган тәэсирләр һәрвакытта да ниндидер аеруча күренекле вакыйга белән генә бәйле түгел. Кайчак син бар нәрсәне онытып торып, сәхнәдә чагылдырылган кеше язмышы белән бирелеп киткән аерым минутлар истә калучан. Шундый кадерле мизгелләрнең берсе — «Тыныч бул, эни!» дигән спектакль күренеше. Монда элеккеге солдат Вано абзый армиягә баручы туганнан туган энесенә үзенең сугышчан тормышы хакында сөйли. Фуад Халитов башкарган... Вано тетрәндерерлек ачыклыкка, җан сафлыгына, эчке матурлыкка ия. Халыкның фашизм белән көрәштә исәпсез-хисапсыз көчен барлыкка китергән әхлакый тамырлар ачык аңлашыла башлый. Тыйнак картның бөтен сүзе тамаша залын тирән дулкынландыра».

Ф.Халитов уйнаган Прибытковны (А.Островский «Соңгы корбан»), Сысой Псоичны (А.Островский «Агай-эне ак мыек»), Шәехмирзаны (К.Тинчурин «Американ»), Шадринны (Н.Погодин «Мылтыклы кеше») шуларга өстик. Болар сәхнә остасының иҗади үсеш юлын билгеләгән сәхнә геройлары, аның сәхнә тормышы маяклары. Шулардан Прибытков образын Мәскәү театр белгечләре актер Москвин уйнавы белән тиңләштерәләр, Ф.Халитовның үзенә генә хас иҗат алымының кайбер отышлы якларын билгеләп үтәләр.

Тагын шунысын да әйтик: Ф.Халитов өчен кечкенә яки зур рольләр юк. Аның өчен бөтенесе бер үк дәрәҗәдә зур һәм әһәмиятле. К.Тинчуринның «Назлы кияү» комедиясендәге карта сугучы мещанны ул әнә нинди итеп — акчага сатылган, акча корбанына әйләнгән байлар-мещаннар даирәсен һәм шул заман рухын берничә дистә сүз, сәхнә минуты белән тамашачы хәтерендә урын алырлык итеп уйный.

Бу көннәрдә Фуад Халитов Г.Боровикның «Канлы күләгәләр» драмасындагы журналист Карлос ролен өйрәнү белән мәшгуль. Бу аның 45 еллык сәхнә тормышында ничәнче вакыйга икән инде? Анык хәтерләми ул. Ике йөзләп алар җыенысы...

Сандамыни эш? Аның өчен шунысы мөһим: аларның һәммәсе аның белән. Алар аның күңелендә күпме дулкынлану, сер, борчылу, сихрилек, шатлык, бөтенесен бергә җыеп әйткәндә, йөрәк уты кабызган.

Аның күңелендәге утның сүнәсе юк әле. Аңа яңадан-яңа утлар өстәлә, кушыла торыр.

Чын мәгънәсендә мәңгелек утка ия кеше һәм актер ул.

*Социалистик Татарстан*
*29 ноябрь, 1975*

**Дорогой Фуад Ибрагимович!**

Меховщики Татарии с огромной радостью восприняли указ Президиума Верховного Совета СССР о присвоении Вам высокого звания народного артиста СССР.

Эта весть с молниеносной быстротой облетела наше объединение. Многие ветераны помнят Вас еще молодым, черноволосым, с пытливыми глазами. Помнят они и Ваши первые шаги на меховой фабрике и на сцене клуба. У нас до сих пор тепло вспоминают о выступлениях рабочего театра. Самым активным участником этого театра были Вы, дорогой Фуад Ибрагимович! Образы, которые Вы умели создавать еще тогда, запомнились надолго.

Теперь Вы — профессиональный артист, посвятивший театру всю свою жизнь и яркий талант. Меховщики считают Вас своим рабочим, своим артистом. Мы с гордостью говорим о Вас: «Он — наш, потомственный меховщик!»

Ваше искусство артиста, такое искреннее и талантливое, глубоко волнует нас, помогает стать лучше, справедливее, добрее, ненавидеть все, что мешает нам жить честно и красиво.

Вы, Фуад Ибрагимович, — любимый артист всего татарского народа. Для нас, меховщиков, присвоение Вам звания народного артиста СССР — это большой праздник.

Горячо поздравляем Вас с присвоением самого высокого звания — народного артиста СССР, желаем Вам вечной молодости, доброго здоровья, больших творческих удач, долгих лет, огромнейшего счастья.

Генеральный директор
Татмехобъединения *Н.С.Рахимов*
Секретарь парткома *Т.М.Мухитова*
Председатель фабкома *М.К.Закирова*
Секретарь комитета ВЛКСМ *Р.М.Шаймарданов*

*1 декабря 1975 года*

***Хәйдәр Гайнетдинов***

## ЯШЬЛЕК БУЛЫП КАЙТА

*СССРның халык артисты Фуад Халитовка 70 яшь*

Тамаша тәмамлануга, зал алкышларга күмелде. Кул чабулар хәтта грим бүлмәсенә дә ишетелә.

Артистлар йөзендә арыганлык сизелә. Әмма бу арыганлык сәхнә тормышыннан тую түгел, ә бәлки рәхәт бер талчыгу гына.

Яшь артистлар Фуад ага янына нәкъ шушы вакытта җыела.

— Фуад ага, бүген ничегрәк уйнадым? Фикерләремне тамашачыларга җиткерә алдыммы икән?

— Фуад ага! Артык хәрәкәтләр ясамадыммы бу юлы? Сезгә ошадымы?

Өлкән артистның җавабы әзер аларга. Чөнки һәр тавышны йөрәге белән тоя, һәр хәрәкәтне күңеле белән күрә ул. Һәм барысын да хәтерендә калдыра. Үз киңәшләрен биргәннән соң, өенә җыена башлый Фуад ага. Ял итәргә кирәк.

...Төнге урам. Күп кенә йорт тәрәзәләрендә утлар сүнгән. Шәһәр татлы йокыга талган. Фуад ага әкрен генә урамнан бара. Аның күңелендә тамашачылар, театр, артистлар...

Тамашачы. Бу сүзгә бөтен төшенчәләр җыйналган. Чөнки дөньяның барча хәлләреннән хәбәрдар бүгенге тамашачы. Кичәгеләреннән кай ягы белән аерылып тора ул?

Әлеге сорауны кешеләрнең үзләренә биреп кара. Төрле-төрле җаваплар ишетерсең. Бер ноктага туплау мөмкинме бу таләпләрне?

Фуад ага уйлана. Аның яшәү рәвешендә әлеге сорауга җавап табу омтылышы бар. Шуның өчен дә ул һәрвакыт газета-журналлар укый, телевидение тапшыруларын карап барырга тырыша. Яңа гына танышкан кешесе белән дә күз ачып йомган арада уртак тел таба белә һәм тормышның иң четерекле мәсьәләләре турында сөйләшә башлый.

Ә болар артист өчен бик кирәкле сыйфатлар. Җир өчен яктылык чыганагы кояш булган кебек, сәнгатькяр өчен иҗат чишмәсе — халыкның көнкүреше ул! Бу хакыйкатьне Фуад ага яшьләргә дә әйтә килә.

70 яшь. Иҗат кешесе өчен ул бик аз. Әмма ничек иҗат итәсең бит?! Фуад ага әйтмешли, аның чиге-кырые юк! Артист үз гомерендә йөзләгән образ тудырган һәм аларны тамашачыларга бүләк иткән, ә һәр образның үз холкы, үз кыяфәте.

Хәзер инде халыкның сөекле актерына әйләнгән күренекле җәмәгать эшлеклесе Фуад Халитов репертуарында санап бетергесез образлар яши.

Берничә көн элек кенә шатлыклы хәбәр ишетелде: Фуад Халитов хөкүмәтебезнең югары бүләгенә — Халыклар дуслыгы орденына лаек булды.

Фуад ага хәзер дә әле дәртләнеп иҗат итә. З.Солтанов, Ш.Шамильский, Х.Әбҗәлилов, Камал III, Ф.Ильская, Х.Сәлимҗанов кебек атаклы артистларның бай тәҗрибәләрен, актерлык осталыкларын үзенә үзләштергән артистыбыз барча белемен яшьләр белән — Р.Шәрәфиев, Х.Җәләлов, Н.Дунаев, Ф.Хәйруллина кебек талант ияләре белән уртаклаша. Бу тынгысызлыгы аның, беренчедән, сәхнәгә яшьлек булып кайтса, икенчедән, Фуад аганың үзен да яшәртеп җибәрә, күңеленә дәрт өсти.

*Татарстан яшьләре*
*27 ноябрь, 1975*

***Назыйм Ханзафаров***

## КОЯШЛЫ КҮҢЕЛ

«...Чем-кара чәчле, үткен күзле яшүсмер малай тагын дәртләнебрәк сөйләргә кереште. Ул һәр сүзен өздереп әйтте, кискен хәрәкәтләр ясады.

— Бу малай артист булыр, — дип куйды кемдер» (Насрый Г. Кызыл Татарстан, 6 ноябрь, 1949).

Хак сүз әйткән ул кеше. Әлеге үткен малай чынлап та артист булды. Актерның да нindие генә әле — СССРның халык артисты! Аның турында «Театр» журналында (1970, № 11) менә нинди сүзләр укый алабыз: «Ф.Халитов гаҗәп актер: талант, осталык, артистизм белән бергә аңарда чын тормыш дөреслеген бирү сәләте яши. Ул Халитов белән бергә сәхнәгә керә, кояш нурыдай яктырта».

Театр белгече И.Романович зур актерыбызның күңелен кояшлы дисә, без аны сәхнә йолдызы дип зурлый алабыз. Әйе, Фуад Ибраһимович Халитов шундый хөрмәткә лаек. Аның илле елга якын сәхнә тормышындагы уңышлары татар халкы культурасының зур казанышлары рәтендә санала ала.

Талантлы артист Ф.Халитов иҗаты турында матбугатта мәгълүматлар байтак. Аның сәхнәдәге башлангыч уңышларын тәҗрибәле театр тәнкыйтьчесе, язучы Г.Кутуй, мәсәлән, болай дип билгеләп үтә: «Ромео һәм Джульетта рольләрендә театрның яшь артистлары Халитов һәм Миңлебаева чыгыш ясавын уңай факт буларак билгеләп үтәргә кирәк... Шунысы куандыра: инде хәзер үк Халитов һәм Миңлебаева уенында иҗади башлангыч, образ иҗат итүгә үзләренчә якын килергә омтылу сизелә».

Күп еллар буе театрларда эшләп, Ф.Халитов байтак талантлы режиссерларның иҗат алымнары белән таныша, осталыкка өйрәнә.

«Артист — чабыш аты ул. Чабыш аты, сабантуй якынлашканны сизеп, март-апрель айларында ук ябыга башлый» дигән чагыштыруны ярата Фуад Халитов. Аның бу сүзләрендә зур мәгънә бар: актер үзе нечкә хисле, табигать җанлы кеше.

Олы актерның иҗат лабораториясеннән бер деталь. Бүген спектакль буласы дигән көнне Халитовлар гаиләсендә аерым бер киеренкелек, җитдилек яши. Үз-үзенә таләпчәнлек, чын сәнгатькә ихтирам, яраткан эшенә мәхәббәт хисе гаилә башлыгын бүтән кеше итеп каядыр алып китә, ул әйткәнне ишетмәс, куйганны күрмәс була, үзенә бер эмоциональ-психологик әзерлек дөньясында яши. Ихтимал, сәнгатькә чын күңелдән бирелгән яшьләрне яратуы да, ялкынсызларны өнәмәве дә әлеге тойгыларына аваздашлык эзләүдән киләдер. «Башыңдагы бөтен дөнья мәшәкатьләреңне оныт, дикъкатеңне, бар булдыгыңны сәнгатькә бир. Шулай булмаганда, театр, сәнгать белән саубуллаш», — ди ул бу турыда. «Театр — халыкныкы. Без — халык хезмәтчеләре. Бу зур җаваплылык йөкли. Артист иң элек үзенә үзе хаким, судья булырга тиеш. Бу инде җәмгыять, халык алдында иң югары җаваплылыкка китерә» — аның актерлык критерийлары, тормыш принциплары әнә шундый.

Ф.Халитов иҗаты уңышларының сере беренче карашка бик гади: актер тормышны, кешене, җәмгыятьне тирән өйрәнә. Фәкать талантка таянып кына ерак китеп булмаганлыгын аңлый ул.

Аның иң зур университеты — тормыш. 1930 елларда театрга мехкомбинат коллективыннан килүе, сәхнәгә менгәнче эшчеләр арасында көн күреп, акыл җыюы аның әнә шул тормышны практик өйрәнүләренең башлангычы, оеткысы иде. Актер шул кыйммәтле хәзинәсен еллар буе тулыландырды, аның сәхнә өчен «кояш нурыдай» кадерле булуын аңлады.

Өлкән актерның сәхнә көчен, кояшлы күңелен театр режиссерлары бүген дә яңа әсәрләрне халыкка җиткерүдә бик белеп файдаланалар. Мәсәлән, Аяз Гыйләҗевнең «Китмәгез, тургайлар» әсәрендәге элекке укытучы Түрәй. Фуад Халитов башкаруындагы бу образ безнең күз алдына яшәүнең

зур җаваплылык икәнен тоючы, үз принципларына ахыргача тугры кала ала торган көчле шәхес булып килеп баса.

Татар театрының күркәм демократик традицияләрен үстереп, театрыбыз данын күтәрүгә зур өлеш керткән Ф.Халитов иҗаты чын мәгънәсендә гуманистик, халыкчан, интернациональ. Татар, рус, Көнбатыш Европа классикасы һәм совет драматурглары әсәрләрендәге дистәләгән характерларны заман таләпләре югарылыгында ачып, тамашачылар мәхәббәтен казанган өлкән артистыбызның тууына 70 ел тулу бәйрәме көннәрендә аңа нык сәламәтлек, сүрелмәс илһам, яңа иҗади уңышлар телибез!

*Социалистик Татарстан*
*17 февраль, 1979*

***<u>Флорид Әгъзәмов</u>***

**ФУАД АГАНЫ БЕЛМӘСКӘ СОҢ!**

Көз айларының бер көнендә мөхәррирebез Шәмси ага Хамматов мине үзенең эш бүлмәсенә чакырып кертте. Ул чакта мин «Социалистик Татарстан» газетасында әдәбият-сәнгать бүлегендә эшли идем. Килеш-килбәтеннән үк ниндидер бер йомыш юллыйсы сизелеп тора. Ул исә редакция эшенә бәйле булмаган берәр төрле йомыш йөкләгәндә йә шәхсән гозерен җиткергән чакта аны рәсми «тырышлык»ка төреп бирә белә иде. Шуңа күрә аны мәҗбүри дип кабул итә идек.

Ә бу юлы ул алай итмәде. Кәнәфиеннән торып, өстәле артыннан чыкты да янга килеп басты һәм, маңгайга төбәп:

— Син Фуад Халитов дигән артистны беләсеңме? — дип сорады.

Күңелемнән әллә ничә юраманы искә алдым. Йә Шәмси ага мине әдәбият-сәнгать бүлеге мөдире буларак сыный, йә әүвәлге язмаларда миңа дәгъва белдерерлек бер-бер хата киткән. (Шәмси ага хата җибәргәнне гафу итми торган иде.)

— Сез бигрәк инде, Шәмси ага, Фуад аганы белмәскә соң! СССРның халык артистлары безнең Татарстанда бер кул бармакларына да җитми, — дидем мин. Йөземә үпкәләү галәмәте чыкканын күргәндер, шәт.

«СССРның халык артисты» дигән югары дәрәҗәгә лаек булган Фуад аганы, шәхсән таныш булмасам да, театрдагы соңгы иҗаты аша шактый ук яхшы белә идем.

Без — газета-журналларда әдәбият-сәнгать тормышын яктыртуга җаваплы журналистлар — республика театрларында сәхнәгә куеласы һәр спектакльне тапшыруда катнаша һәм премьерасын карап бара торган идек. Тамашаны тапшыру бик кызыклы үтә. Анда театр тәнкыйтьчеләре, артистлар, язучылар, КПССның өлкә, шәһәр комитетлары, Мәдәният министрлыгы, хезмәткәрләр, журналистлар, җәмәгатьчелек вәкилләре җыела. Спектакль тәмамлангач, аны күмәк тикшерергә керешәләр. Режиссер чыгыш ясый, тәнкыйтьчеләр — сирәк булса да — артистлар... Спектакльләргә бәя бирүне әзерләгәндә, мондый тикшерүләрнең, җәмәгатьчелек фикере буларак, безгә зур файдасы тия иде.

Әнә шул тикшерүләрдә төп рольләрне башкаручыларның, шул җөмләдән Фуад аганың артистлык осталыгы турында байтак фикерләр ишетергә туры килде. Шуның өстенә мин беренче чиратта тамашачы бит әле. Фуад аганың җаваплы рольләрен күреп, әллә ничәмә тапкыр сәхнәдә сокланганым булды.

...Шәмси ага миңа:

— Белсәң, шул: аңа бераз ярдәмең кирәк булыр. Аны республика профсоюзлар өлкә комитеты әгъзасы итеп сайлаганнар. Шушы арада комитетның пленумы була. Фуад агага әнә шунда чыгыш ясарга кушканнар... Әнә аста машина көтеп тора, — дип, кулыма Фуад аганың адресын тоттырды.

Без ул кушканны үтәргә күнеккән. Әмма республиканың, Камал театрының йөзек кашы янына барасын башта абайлап та бетермәгәнмен. Машинага кереп утыргач кына, анда олуг шәхес белән очрашу, аның фикерләрен тыңлау, аларны кәгазьгә төшерү торганы башыма сукты, дулкынлану хисе чолгап алды. Ләкин озак дулкынланып утырырга туры килмәде. Бауман урамындагы Матбугат йортыннан Мәктәп тыкрыгына барып җиткәнне сизми дә калдык.

Кыңгырау басуыбызга, ишекне Фуад ага үзе ачты. Бусагада мине күргәч, йөзенә аптырау галәмәте сызылып киткәндәй булды. Ул, күрәсең, саллырак затны көткәндер. Каршысында исә малайлыгы яңа чыгып өлгергән егет басып тора. Аптырау чалымнары күз ачып йомганчы юкка чыкты.

— Әйдә, улым, рәхим ит, түргә уз, — дип гөрелдәде Фуад ага, карлыкканрак яңгырый торган тавышы белән.

Чишенгәч, залга уздык. Квартирда үзе генә иде шикелле. Зал уртасындагы түгәрәк өстәл янына утырдык. Ул бүлмә буйлап йөренергә кереште.

— Көтмәгәндә бер йөкләмә тапшырдылар бит әле, — дип сөйләп китте ул. — Мин нотык тотарга яратмыйм. Урыным әнә — сәхнә. Миңа драматурглар язып биргәннәр нәрсә сөйләсемне. Профсоюздан шылтыратып әйттеләр, зинһар, чыгыш ясый күр, диделәр. Җитмәсә, урыс телендә кирәк, ди. Ризалашырга туры килде инде.

Эшне Фуад ага белән чыгышта ниләр булырга тиешлеген аныклаудан, ягъни, мәсәлән, булачак нотыкның планын корудан башладык. Әйтергә тиешмен, ул заманда зур форумнарда ясала торган чыгышлар билгеле бер кагыйдәләр буенча корыла иде. Без дә шул кагыйдәләрне сакладык. Профсоюз комитеты пленумы КПСС Үзәк Комитетының — хәтеремдә калмаган — пленумынамы, әллә карарынамы багышлап уздырыласы икән. Чыгышның керешен язу әллә ни кыен булмады. Кабул ителгән сценарий буенча керештә бөтен интеллигенция исеменнән партия карарын хуплау тиеш, аның иҗат кешеләренә илһам канаты куюын раслау тиеш. Аннары театр әһелләре алдына куела торган бурычларны барлап чыктык. Шул бурычлар яктылыгында бүгенге театрлардагы, аерым алганда Камал театрындагы уңышларга күзәтү ясадык.

Мондый төр чыгышларда аерым кимчелекләр дә күрсәтелергә тиеш бит инде. Репертуар ярлылыгын, хезмәт дисциплинасының аксавын, иҗат интеллигенциясенең ялын оештыру, сәламәтлеген саклаудагы җитешсезлекләрне атадык.

Ул вакытта куелган таләпләргә җавап бирердәй матур гына чыгыш килеп чыкты.

Эшне түгәрәкләү белән саубуллашып китәсе иткән идем, Фуад ага кырт кисте, ай-ваема карамыйча, чәй эчәргә күндерде. Без әдәбият-сәнгатькә кагылышлы сүзләр сөйләшеп чәй эчтек. Өстәлгә нинди ризык-нигъмәтләр куелган булгандыр, истә калмаган. Ә менә хәтердә уелганы бар.

— Менә бусыннан авыз ит, — дип кыстый да кыстый Фуад ага.

Минем андый ризыкны кая ул ашау, күргәнем дә юк. Шуны сизепме, Фуад ага бер телем күмәч алып май якты, өстенә калай савыттагы кара әйберне сылап, миңа тоттырды. Кара уылдык дигәннәре шул икән. Шулай итеп, мин гомеремдә беренче тапкыр аксөякләр деликатесыннан — кара уылдыктан авыз иттем. Тел йотарлык тәмле икән, каһәр. Әле дә җае чыккан саен капкаларга яратам мин аны һәм ашаган саен Фуад агайны елмаеп искә төшерәм.

...Рәхмәт әйтеп, мин китәргә җыендым. Фуад ага, яныма килеп, маңгаемнан үбеп алды.

Бу очрашудан соң без Фуад ага белән якын танышлар булып киттек. Күрешкән саен хәл-әхвәл сораша торган булдык. Хәтта бер тапкыр интервью да алдым әле.

Берчак КПСС Үзәк Комитетының ниндидер бер карары чыкты. Гадәт буенча, аны күренекле затлардан хуплатырга кирәк иде. Фуад агага шылтыраттым, гозеремне җиткердем. Ул газета аша фикерен укучыларыбызга җиткерергә риза булды.

Очрашу турында сүз кузгаткач, Фуад ага әйтте:

— Улым, вакыт әрәм итеп, мәшәкатьләнеп йөрмә. Телефон аша сөйләшү дә җитәдер. Сиңа күп сүз кирәкмидер бит. Менә болайрак яз. — Ул берничә фикер бирде. Аннары өстәде: — Син үзең әмәллә инде. Сез журналист халкының андый эшкә кулы шомарып беткән.

Мин бу әңгәмәне «Социалистик Татарстан»да икенче көнне үк бастырып чыгардым.

*Мәгърифәт*
*6 июнь, 1998*

## КҮРӘЗӘЧЕ

*(Хатирә)*

1963 елның көзендә Кремльнең Съездлар сараенда уздырылган СССРның XIII профсоюзлар съездында Татарстанның 31 кешедән торган делегатлары арасында Фуад Халитов та бар иде.

Ул елларда мин Казан моторлар төзү берләшмәсендә завком рәисе булып эшли идем. Күренекле артистыбыз белән бер купега туры килдем. Вагонда театр турында күргән-белгәннәремне сөйләдем. Сүзем туган авылым Лашман турында булды. Мин Лашман театры хакында сөйли башлагач, Фуад абый миннән тәфсиллерәк итеп сөйләвемне үтенде. Безнең авыл сәхнәсе аны шулкадәр кызыксындырды, ахры, хәтта съездан кайтканда да шуны дәвам итәргә булдык.

...Без — СССР профсоюзларының XIII съездында. Татарстан делегациясе залның уң ягында, ә безнең өстә — партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре. Минем урын Фуад абый белән бер тирәдәрәк. Бүген дә күз алдымда: шау-шулы алкышлар астында сәхнәгә партия, хөкүмәт җитәкчеләре күтәрелде. Иң алда — СССРның Югары Советы Рәисе Л.И.Брежнев. Ул, үзенең озын буеннан оялгандай чүгепчүгеп, сәхнәгә чыкты. Кул чабып, тәбәнәк буйлы, түгәрәк корсаклы, КПССның беренче секретаре Н.С.Хрущевны тәбрикләп каршы алдык.

Шул ук көнне кичен съездан кунакханәгә кайткач, Фуад ага, миннән фикерен яшермичә: «Кара әле, малай, Брежневка артист булырга иде: нинди матур уйный лакей ролен!» — диде.

Мин, шикләнеп, шыпырт кына: «Зинһар, кычкырып әйтмәгез!» —дидем. Ул, көлемсерәп: «Син минем өстән донос язмассыңдыр бит? Күңелем сизә, бу кара кашлы полковник кайчан булса да кукуруз агрономы урынына менеп утырачак!» — диде.

Урта Идел Совнархозына кергән Татарстан, Башкортстан һәм Куйбышев делегацияләре «Украина» кунакханәсенә бергә урнашты. Съезд делегатларын өч тапкыр бушлай ашаталар иде. Безнең делегация башлыгы Габделхак Бәдыйгов хәмергә чик куйды. Ә күрше бүлмәдәге Башкортстан һәм Куйбышев делегатлары һәр кич диярлек җырлап-биеп күңел ачтылар.

Фуад ага еш кына иртән яисә төшке аштан соң үзенең Мәскәүдәге күпсанлы дус-ишләренә кунакка китә иде. Ул миңа: «Бигайбә, биредә яңа сүз булмас, мине Брежнев комедиясе туйдырды инде», — дип, үзенең канәгатьсезлеген яшерми иде.

Съезд бер атна барды. Ул вакытларда Кытай белән дуслыгыбыз суынып бара иде. Съезд президиумы Татарстан делегациясе башлыгы Г.Бәдыйговка Кытай делегатлары белән элемтәгә керүне тапшырды.

Мәскәүдә соңгы кичебез. Съездны тәмамлап, саубуллашу мәҗлесенә утырыштык. Минем бер ягымда — Бәдыйгов, икенче ягымда — Фуад Халитов. Ул миңа шыпырт кына: «Син бит Бәдыйговның бик якын кешесе... Соңгы кичтә дә бераз күңел ачып булмас микәнни?! Без башкортлардан һәм самаралылардан киммени? Эш беткәч, уйнарга ярый». Шуны ишеткән Габделхак Бәдыйгов берәр рюмкага гына рөхсәт бирде. Без съезд хөрмәтенә тост күтәрдек. Фуад ага сәхнәдәге зур рояльгә ишарәләп: «Җәмәгать! Берәрегез уйнап күрсәтсәгез иде!» — дигәч, бер дә көтмәгәндә безнең тыйнак Бәдыйгов, урыныннан кузгалып, миңа: «Менә син тостны бик актив күтәрештең, әйдә, алай булгач, киттек сәхнәгә, җырлап та бирерсең»,— дип, мине җилтерәтеп сәхнәгә алып китте.

Нишләмәк кирәк, миңа «артист» булырга туры килде. Ул, рояль янына утырып: «Нинди көйгә җырлыйсың?» — дигәч, мин дә эре генә: «Классик җырларны яратам, «Эшче» операсыннан Нигъмәт ариясе минем репертуарымда», — дип шаяртып сәхнәгә менеп барганда, ике яктан башкорт туганнар һәм Самара руслары килеп чыктылар. Мин, бераз шүрләп калсам да, җитди күренергә тырышып:

— Иптәшләр! Безнең Совнархоз өч милләттән — татар, башкорт һәм руслардан тора. Мин сезгә тәкъдим иткән «Эшче» операсын да шушы милләт композиторлары һәм шагыйре иҗат иткән. З.Виноградов, С.Габәши, Г.Әлмөхәммәтов һәм Мәҗит Гафурилар, — дидем.

Үземне кулга алып, Нигъмәт ариясенең ике куплетын да уңышлы гына ерып чыктым. Көтмәгәндә яңгыраган көчле алкышлардан шүрләп калдым. Сәхнәдән качам дигәндә генә, Бәдыйгов, туктатып: «Ашыкма, тагын нәрсә уйныйбыз?» — дигәч, мин Салих Сәйдәшевнең «Хуш, авылым»ын башкардым.

Урыныма төшеп утыруга, Фуад ага, мине ике куллап тәбрикләп: «Коеп куйган артист бит син, ташла заводыңны, станокларыңны», — дип күңелемне күтәрде.

Фуад ага белән Мәскәүдән дә бер купеда кайттык. Ул тагын салпы ягыма салам кыстыргач, мин, көрсенеп: «Рәхмәт сезгә, мин — гомерлек инженер, миңа сәхнәгә күтәрелергә соң инде», — дип куйдым.

Әйе, миннән артист чыкмады. Ләкин күренекле сәхнә йолдызларыбыз, халкыбызның яраткан кешесе Фуад ага Халитов белән бер атна буена күрешеп сөйләшүләр хәтеремдә нык уелып калды.

Фуад аганың күрәзәчелеге тормышка ашты бит. Н.Хрущевны шома гына төшереп, Л.Брежнев аның тәхетенә менеп утырды.

*Татар иле*
*Сентябрь, 2002*

***<u>Ильтани Илялова</u>***

## СМЫСЛ ЕГО ЖИЗНИ

*К 70-летию народного артиста СССР*
*Фуада Халитова*

Народный артист. Это звание как нельзя лучше определяет личность Фуада Халитова — человека, не представляющего себя вне сцены. Актер в течение всей своей 50-летней творческой деятельности горячо и страстно утверждал и утверждает созидательный пафос нашей жизни, высокие моральные принципы.

Роли, роли… Их наберется не один десяток. Разных героев — старых и молодых, добрых, злых, волевых и слабых. Сколько они доставляли счастья, радости и огорчений! Непрерывные поиски образа, поиски характера. То ты превращаешься в разведчика, идущего тропинками и большими дорогами, то поднимаешься на высокие горы, то проваливаешься в пропасть, и, кажется, не выбраться из нее.

В Татарском академическом театре имени Г.Камала Халитов возмужал, вырос в актера, которого сегодня все знают и любят. Он — подлинный представитель школы переживания, понимает, что главное — психологический анализ роли. Но он также помнит, что, стремясь к глубине психологической разработки, ни в коем случае нельзя забывать о внешней стороне образа, его форме. Без техники, артистизма не получится создать полнокровный, запоминающийся образ. У актера должны быть безупречными все средства внешней выразительности — голос, дикция, пластика, служащие в конечном счете раскрытию сущности человеческого характера.

Халитов в молодости интуитивно, а потом уже осмысленно постигал премудрости мастерства. Он ритмичен, прекрасно двигается на сцене. Все это позволило ему создать ряд замечательных образов, ставших в один ряд с лучшими творениями мастеров советской сцены.

Все то, что зрело годами, накапливалось по крупицам, Халитов щедро, самозабвенно дарит зрителю.

В 50—70-е годы наступил расцвет его творчества. В этот период им созданы такие яркие образы, как Муса Джалиль в одноименной трагедии Н.Исанбета, Сагдетдин («Шамиль Усманов» А.Гилязова и А.Яхина), Прибытков («Последняя жертва» А. Островского), Аглиулла («День рождения Миляуши» Т.Миннуллина), Шехмирза («Американец» К.Тинчурина), Рисположенский («Свои люди — сочтемся» А.Островского), Ахтям («Мужчины» Т.Миннуллина), Абдульхамит («Фатима Сабри» С.Джамала).

Реалистическое актерское искусство — это не застывшие формы, в которые вливается новое содержание, это необычайно гибкая категория, которая меняется под воздействием отражаемой им действительности; это, образно говоря, чуткий, всеулавливающий сейсмограф. Искусство всегда массово, объединяюще. Артист обращается не к отдельной личности, а к обществу. В зрительный зал вместе с публикой входит сегодняшняя «злоба дня», она предъявляет свои требования, ждет от него ответа на многие вопросы. Актер должен утвердить себя на протяжении жизни того поколения, которое его выдвинуло. Именно потому, что искусство театра, в отличие от всех других искусств, творится только исключительно для современников, его связи с сегодняшней жизнью чрезвычайно обострены.

В этом отношении Фуад Халитов добился многого. Его глубоко гражданственное творчество всегда созвучно мыслям и чувствам современников.

Халитов всю свою сценическую жизнь старается быть на уровне требований времени, не отстать от века. Он живет напряженной жизнью, он — в постоянной работе, в энергичном поиске. А это требует, в свою очередь, настойчивой учебы, неустанного совершенствования мастерства.

Актер понимает, что диалог в сегодняшнем спектакле должен быть кратким, ясным, афористичным, ибо темп нашей жизни чрезвычайно стремителен. Понимание условий действительности приводит к точному решению образов. Причем по-сегодняшнему трактованными оказываются в игре Халитова не только персонажи современных пьес, но и герои классических произведений.

Множеством штампов, как правило, обрастают при исполнении роли в пьесах классиков, Халитов же всякий раз уверенно избегает повторов. Блестящим доказательством тому служат роли Прибыткова и Рисположенского, сыгранные им в спектаклях по произведениям Островского.

На сцене Халитов ни на секунду не выключается из действия. На протяжении всего спектакля зритель чувствует его внутреннюю жизнь, которую на театральном языке называют вторым планом роли. Для актера очень важной частью образа остается внутренний монолог, который он ведет на протяжении всего спектакля. Потому-то, как правило, образы его героев так глубоки и объемны.

В спектаклях последнего десятилетия Халитов совместно с режиссерами ищет новые выразительные средства, пути углубленного раскрытия характеров. Он достигает безупречного логического развития своих персонажей, глубины перевоплощения. Жизненно достоверен, точен, например, Ахтям («Мужчины»), сыгранный в близком татарскому театру стиле психологической драмы. Актер раскрыл противоречивую натуру своего героя, несущего крест страдальца и мученика и цинично наблюдающего за проносящейся мимо бурной жизнью.

В 70-е годы Халитов еще более пристально вглядывается в современность. Этот вдумчивый взгляд чувствуется в ролях, которые он создает в новых советских пьесах. Ученый Арсланов («Суд совести» Д. Валеева), начальник цеха Хисами («Узы родства» Ю. Аминова), директор крупного завода («Человек со стороны» И. Дворецкого), чилийский журналист Карлос Бланка («Интерью в Буэнос-Айресе» Г. Боровика), Турай («Не улетайте, жаворонки!» А. Гилязова), Магнави («Я вернулся на твое место» Р. Хамидуллина) — все эти герои, живущие в одно время с самим актером, интересны

ему. Поэтому в них он ищет и характерные, индивидуальные черты, и общие признаки людей второй половины XX века.

Фуаду Халитову исполнилось 70 лет. За его плечами богатый жизненный путь, отмеченный большими и малыми творческими победами. Актер видит смысл своей жизни в служении народу, поэтому сцена для него — это прежде всего место, где он выполняет свой гражданский долг.

Театр, позволяющий утверждать возвышенные, благородные мысли и чувства, стал смыслом и содержанием жизни народного артиста СССР Фуада Халитова.

*Советская Татария*
*1979, 18 февр.*

***Р.Элин (Рустем Халитов)***

## ТАЛАНТ, ОТДАННЫЙ ЛЮДЯМ

Сегодня общественность республики торжественно отмечает семидесятилетие народного артиста СССР, старейшего актера Татарского ордена Ленина государственного академического театра им. Г. Камала Фуада Ибрагимовича Халитова.

Закончен спектакль. Опустел зрительный зал. Машинисты сцены убирают декорации, и на пустом пятачке остается лишь треножник с небольшой лампочкой.

В эти минуты Фуад Халитов любит спуститься со сцены в зал, сесть где-нибудь в ряду двадцатом, на крайнее место, — и вспоминать. Он глядит на огонек, что светится на сцене, и в его воображении встают десятки образов, созданных им в этом театре за сорок с лишним лет.

Сколько их было? Однажды он с карандашом в руках попытался составить точный перечень, но сбился со счета. А потом, уже ночью, вспомнил еще несколько ролей, сыгранных в Рабочем театре в начале 30-х годов.

В те годы он мог переплыть Волгу в самом широком месте, без передышки пробегал на лыжах 30-километровую дистанцию, сгибал в узел железную кочергу, а после тяжелого трудового дня приходил в Клуб меховщиков и участвовал чуть не во всех постановках и агитвыступлениях молодежной группы.

...Не устаю удивляться его наблюдательности. Идет по улице — и вдруг обернется и долго смотрит вслед прохожему. А потом, когда смотришь новый спектакль с его участием, невольно вспоминаешь того случайного прохожего, узнаешь его в характерном жесте, в походке.

Каждый человек для него — загадка, которую надо разгадать. Он стремится распознать характер и душу каждого, «впитывая» чужие слова и жесты, улыбки и привычки, чтобы потом принести все это на сцену.

Он всегда в работе, даже тогда, когда отдыхает. Как истинный художник, он ни минуты не может быть свободен от забот и проблем времени, в котором живет, от радостей и стремлений людей, для которых работает. Вот почему такой точностью и силой обобщения отличаются созданные им образы журналистов Карлоса Рафаэля Бланко в спектакле «Интервью в Буэнос-Айресе» по пьесе Г.Боровика, архитектора Ахтямова в «Мужчинах» Т.Миннуллина, Вано в пьесе Н.Думбадзе «Не беспокойся, мама!»

В 1975 году Фуад Ибрагимович был удостоен высшего актерского звания — народного артиста СССР. А совсем недавно он награжден орденом Дружбы народов. Но самая дорогая для артиста награда — любовь зрителей. Фуад Халитов пользуется у нас в республике поистине всенародным признанием. Зрители с нетерпением ждут новых его работ.

*Вечерняя Казань*
*1979 г., 12 марта*

*** * ***

**Фуад Ибраһимович Халитов**

Совет театр сәнгате гаять зур югалтуга дучар булды. Озакка сузылган каты авырудан соң совет сәхнә сәнгатенең күренекле остасы, СССРның халык артисты, 1936 елдан КПСС члены Фуад Ибраһимович Халитов вафат булды. Үзенчәлекле художник, оптимизм белән сугарылган зур талант иясе безнең арадан китте.

Ф.И.Халитов 1909 елда Казан шәһәрендә туа. Табигать биргән зур таланты, хезмәт сөючәнлеге, үз дигәнендә нык торуы белән ул эшчедән һәм үзешчән сәнгатьтә катнашучыдан алып профессиональ совет сәхнәсенең зур остасына кадәр юл үтте. Үзенең иҗат эшчәнлеген Ф.И.Халитов 1932 елда

Эшче театрында башлый. Аннары ярты гасырга якын Г.Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театрында эшли. Әлеге театр сәхнәсендә аның зур сәләте аеруча тулы ачылды һәм чәчәк атты.

Бу елларда Фуад Ибраһимович дөнья, рус, совет һәм татар классикасы спектакльләрендә, шулай ук хәзерге заман драматургиясе әсәрләрендә 150 дән артык төрле характердагы роль уйнады, аларның күбесе милли театр сәнгате үсешендә җуелмас эз калдырды. Аның Кент, Ромео (В.Шекспир «Король Лир», «Ромео һәм Джульетта»), Рисположенский, Флор Федулыч, Незнамов (А.Островский «Агай-эне ак мыек», «Соңгы корбан», «Гаепсездән гаеплеләр»), Скроботов (М.Горький «Дошманнар»), Шадрин (Н.Погодин «Мылтыклы кеше»), Сәүдәгәр (Г.Камал «Бәхетсез егет»), Исмәгыйль (М.Фәйзи «Галиябану»), Шәехмирза (К.Тинчурин «Американ»), Хуҗа Насретдин, Муса (Н.Исәнбәт «Хуҗа Насретдин», «Муса Җәлил»), Гыйльманов, Мостафа (М.Әмир «Миңлекамал», «Тормыш җыры»), Әхтәм (Т.Миңнуллин «Ир-егетләр») кебек һәм совет театр сәнгатенең алтын фондына кергән күп кенә башка хезмәтләре артистның иҗат диапазонының киңлеген һәм талантының күпкырлы булуын күрсәтә. «Правда» газетасы язганча, аның актерлык осталыгына реалистик конкретлылык, тарихны дөрес тою, үткен театральлек хас иде.

Ф.И.Халитовның якты иҗаты республикабыздан читтә дә яхшы мәгълүм иде. Ул Мәскәү, Ленинград, Ташкент, Фрунзе, Алма-Ата, Свердловск, Уфа, Чиләбе, Саратов, Әстерхан, Ульяновск һәм башка шәһәрләрнең театр сәхнәләрендә чыгыш ясады. Һәм һәркайда аның үзенчәлекле талантын, реалистик осталыгын, актер буларак гаҗәеп сизгерлеген, бай рухи дөньясын билгеләп үттеләр.

Ф.И.Халитов яшь актерлар һәм драматурглар белән эшләүгә күп көч һәм энергия куйды, алар белән үзенең бай иҗат тәҗрибәсен уртаклашты.

Ул иҗат эшен күптөрле җәмәгать эшчәнлеге белән уңышлы бәйләп алып барды. Күп тапкырлар театрның партия бюросы составына, җирле комитетка, художество советына сайланды. Предприятиеләрдә эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре, Совет Армиясе сугышчылары алдында еш чыгыш ясады.

Коммунистлар партиясе һәм совет хөкүмәте Ф.И.Халитовның иҗади хезмәтен югары бәяләде. Ул «СССРның халык артисты» дигән мактаулы исемгә лаек булды. Халыклар дуслыгы ордены һәм СССР медальләре белән бүләкләнде.

Совет театр сәнгатенең күренекле эшлеклесе, коммунист, гүзәл кеше Ф.И.Халитовның якты истәлеге күңелләребездә мәңге сакланыр.

*Р.М.Мусин, С.Г.Батыев, Г.И.Усманов, В.С.Дергунов, М.Ф.Вәлиев, Б.М.Исаев, М.К.Рәмиев, М.М.Репеев, Ф.А.Садыйков, Л.М.Смагин, С.Г.Сафин, Ш.Р.Агеев, Р.К.Беляев, А.В.Гнеденков, И.Х.Галиев, Н.В.Фролов, М.Х.Хәсәнов, М.М.Мусин, Ю.М.Воронин, Ә.С.Миндубаев, А.Г.Кадыйрова, И.Н.Алеев, А.И.Бондаренко, М.М.Латыйпов, Г.А.Ахунов, М.З.Яруллин, Ә.И.Тумашев, Р.А.Җиһаншина, И.Н.Алексеев, К.Г.Әхмәтов, М.М.Таишев, А.З.Аббасов, Ш.Х.Биктимеров, Н.Г.Җиһанов, А.Р.Шамуков, М.Х.Сәлимҗанов, Ф.С.Ильская, Н.И.Дунаев, Ф.Х.Хәмитова, Г.С.Ишкова, Н.С.Исәнбәт, Т.А.Миңнуллин, Р.М.Харисов, Л.Г.Космылина, Х.Ю.Сәлимҗанов*

*** * ***

## Күмүне оештыру комиссиясеннән

Ф.И.Халитов белән хушлашу 18 мартта иртәнге сәгать 10 да Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында була.

*Социалистик Татарстан*
*17 март, 1981*

#### Фуад Халитов уйнаган рольләрнең исемлеге

*Эшче театрында*
**1933—1936**
Мәхмүт — «Козгыннар оясында» *(Ш.Камал)*
Парторг — «Шатлык җыры» *(Г.Кутуй)*
Сәйфулла — «Гармун сөйләр» *(Ә.Мәҗит)*
Рәүф — «Ут» *(Ш.Камал)*
Франц Раш — «Катарродан матрослар» *(Ф.Вольф)*
Незнамов — «Гөнаһсыз гаеплеләр» *(А.Островский)*
Исмәгыйль — «Галиябану» *(М.Фәйзи)*
Мингали — «Яшь йөрәкләр» *(Ф.Бурнаш)*
Николай Александрович — «Сакла, шартламасын» *(К.Тинчурин)*
Годун — «Разлом» *(Б.Лавренев)*

*Г.Камал театрында*
**1937**

Вәли — «Аршын мал алан» *(У.Гаджибеков)*
Греков — «Дошманнар» *(М.Горький)*
Хабул — «Ташкыннар» *(Т.Гыйззәт)*
Капитан — «Чик сакчылары» *(В.Билль-Белоцерковский)*
Хәмзә, Рәхмәтулла — «Галиябану» *(М.Фәйзи)*
Сәләхи — «Бишбүләк» *(Т.Гыйззәт)*
**1938**
Надир — «Намус» *(Г.Мдивани)*
Сәйфулла — «Шәмсекамәр» (*М.Әблиев)*
**1939**
Сәлим — «Күзләр» *(Х.Фәтхуллин)*
Печән базары сатучысы — «Тукай» *(Ә.Фәйзи)*
Незнамов — «Гаепсездән гаеплеләр» *(А.Островский)*
**1940**
Бики — «Хуҗа Насретдин» *(Н.Исәнбәт)*
Гәрәй — «Гөлчәчәк» *(Г.Минский)*
Герман — «Таня» *(А.Арбузов)*
Ромео — «Ромео һәм Джульетта» *(В.Шекспир)*
Исерек — «Бәхетсез егет» *(Г.Камал)*
**1941**
Бикташ — «Наемщик» *(Т.Гыйззәт)*
Шамил — «Таймасовлар» *(Т.Гыйззәт)*
Салих — «Очрашу» *(Ш.Мәҗит)*
**1942**
Таһир — «Мәйсәрәнең хәйләсе» *(Х.Хәмзә)*
Федерико — «Печән өстендә эт» *(Лопе де Вега)*
Розенберг — «Рус кешеләре» *(К.Симонов)*
Шәмаил сатучысы — «Тукай» *(Ә.Фәйзи)*
**1943**
Сафарьян — «Мәрьям» *(Н.Исәнбәт)*
**1944**
Хәлим, Гыйльманов — «Миңлекамал» *(М.Әмир)*
Кент — «Король Лир» *(В.Шекспир)*
Гарәп — «Җирән чичән белән Карачәч сылу» *(Н.Исәнбәт)*
Антон — «Аталар яшьлеге» *(Б.Горбатов)*
Кудряш, Тихон — «Гроза» *(А.Островский)*
Хөснетдин — «Хаҗи әфәнде өйләнә» *(Ш.Камал)*
**1945**
Каюм Насыйри — «Каюм Насыйри» *(М.Гали, Х.Уразиков)*
**1946**
Притыкин — «Варварлар» *(М.Горький)*
Рекало — «Диңгездәгеләр өчен» *(Б.Лавренев)*
Эрик — «Ул килде» *(Дж.Пристли)*
Гыйният — «Изге әманәт» *(Т.Гыйззәт)*
**1947**
Басыйр — «Тормыш җыры» *(М.Әмир)*
Мочтак — «Чаткылар» *(Т.Гыйззәт)*
Кожаров — «Сүнмәс ялкын» *(Б.Полевой)*
Шадрин — «Мылтыклы кеше» *(Н.Погодин)*
**1948**
Кинжагол — «Пугачев Казанда» *(Ә.Фәйзи)*
Тимербай — «Мулланур Вахитов» *(Н.Исәнбәт)*
Ильяс — «Зур гаилә» *(Э.Шамиль)*
Газиз — «Серләр» *(Ә.Әхмәт)*
Мостафа — «Җыр дәвам итә» *(М.Әмир)*
Флориндо — «Ике хуҗаның хезмәтчесе» *(К.Гольдони)*
Морат — «Рәйхан» *(Н.Исәнбәт)*
Исмәгыйль — «Галиябану» *(М.Фәйзи)*
Незнамов — «Гаепсездән гаеплеләр» *(А.Островский)*
**1949**
Торцов — «Ярлылык гаеп түгел» *(А.Островский)*
Хлопов — «Ревизор» *(Н.Гоголь)*
Сәләхи — «Бишбүләк» *(Т.Гыйззәт)*
Шакир — «Әбли авылы» *(Ф.Хөсни)*
**1950**
Маргаритов — «Кичеккән мәхәббәт» *(А.Островский)*
Мещеряков — «Кем гаепле?» *(Г.Мдивани)*
**1951**
Колен — «Жорж Данден» *(Мольер)*
Петр Ильич — «Яшьлек иртәсе» *(Г.Хөсәенов, Р.Хәмидуллин)*
Рамазан — «Гүзәл» *(Н.Исәнбәт)*
**1952**
Исмәгыйль — «Галиябану» *(М.Фәйзи)*
**1953**

Рәхим — «Нурия һәм дуслары» *(С.Кальметов)*
Воробьев — «Тынгысыз картлык» *(Л.Рахманов)*
Яго — «Отелло» *(В.Шекспир)*
Заманов — «Кадерле минутлар» *(Г.Насыйри)*
**1954**
Айдар — «Зифа» *(Н.Исәнбәт)*
**1955**
Исерек — «Бәхетсез егет» *(Г.Камал)*
Суфи — «Кара йөзләр» *(М.Гафури)*
**1956**
Кент — «Король Лир» *(В.Шекспир)*
Ат карагы — «Зәңгәр шәл» *(К.Тинчурин)*
? — «Еллар-юллар» *(Ф.Хөсни)*
**1957**
Гыйльманов — «Миңлекамал» *(М.Әмир)*
Муса — «Муса Җәлил» *(Н.Исәнбәт)*
**1958**
? — «Рәүфә» *(Ә.Фәйзи)*
Лу Гуй — «Тайфун» *(Цао-Юй)*
**1959**
Туйск — «Юлдан язган» *(Э.Раннет)*
Кленов — «Мәңгелек каләм» *(И.Шток)*
Кыям — «Беренче чәчәкләр» *(К.Тинчурин)*
Иршат — «Таң атканда» *(Ш.Шахгали)*
**1960**
Сельсовет рәисе — «Хөррият» *(М.Әмир)*
Малтабар — «Умырзаялар» *(Ю.Әминов)*
**1961**
Мыеклы кеше — «Киек Каз Юлы» *(А.Гыйләҗев)*
Китс — «Мәхәббәт утравы» *(А.Парнис)*
Рәхмәтулла — «Рәхим итегез» *(Х.Вахит)*
**1962**
Яппар — «Җырланмаган җыр» *(М.Кәрим)*
Хисами — «Хәерле юл» *(Г.Әпсәләмов)*
**1963**
Скроботов — «Дошманнар» *(М.Горький)*
Хафиз — «Гөлҗамал» *(Н.Исәнбәт)*
Чураев — «Зифа» *(Н.Исәнбәт)*
**1965**
Гайнетдин — «Һиҗрәт» *(Н.Исәнбәт)*
Пичигин — «Ата хакы — Тәңре хакы» *(В.Лаврентьев)*
**1966**
Муса — «Муса Җәлил» *(Н.Исәнбәт)*
Хуҗа — «Хуҗа Насретдин» *(Н.Исәнбәт)*
Гариф — «Миркәй белән Айсылу» *(Н.Исәнбәт)*
Әхмәт — «Фәтхулла хәзрәт» *(Ф.Әмирхан)*
**1967**
Габделхәмит — «Фатыйма Сабри» *(С.Җамал)*
Сәгъдетдин — «Шамил Усманов» *(А.Гыйләҗев, А.Яхин)*
**1968**
Әһлиулла — «Миләүшәнең туган көне» *(Т.Миңнуллин)*
Нигъмәтҗан — «Илһамия» *(Х.Вахит)*
Прибытков — «Соңгы корбан» *(А.Островский)*
**1969**
Каюм Насыйри — «Каюм Насыйри» *(М.Гали, Х.Уразиков)*
Шәехмирза — «Американ» *(К.Тинчурин)*
**1970**
Гвоздилин — «Баһадирлар» *(Н.Погодин)*
Хәйрулла — «Канат җәйгәндә» *(Н.Әсәнбаев)*
Ат карагы — «Зәңгәр шәл» *(К.Тинчурин)*
**1971**
Әхтәм — «Ир-егетләр» *(Т.Миңнуллин)*
Арсланов — «Намус хөкеме» *(Д.Вәлиев)*
Вано — «Борчылма, әнием!» *(Н.Думбадзе)*
**1972**
Рисположенский — «Агай-эне ак мыек» *(А.Островский)*
**1973**
Плужин — «Чит кеше» *(И.Дворецкий)*
**1974**
Хисами — «Кан кардәшләр» *(Ю.Әминов)*
**1975**
Миргалим — «Назлы кияү» *(К.Тинчурин)*
Карлос Бланка — «Канлы күләгәләр» *(Г.Боровик)*
**1978**

Мәгънәви — «Синең урыныңа кайттым» *(Р.Хәмид)*
Түрәй — «Китмәгез, тургайлар!» *(А.Гыйләҗев)*
**1979**
Гарәфи — «Банкрот» *(Г.Камал)*

**ЭЧТӘЛЕК**

***Марсель Сәлимҗанов.*** «Безгә аның белән эшләве җиңел...»
***М.И.Закирова.*** «Уйламаган булыр кендек әби...»
***Ильтани Илялова.*** Эшче һәм Эшче театры
Г.Камал театрында
Фуад абыйның кечкенә генә дәфтәргә татарча һәм русча язып  калдырган фикерләре
Актер. Размышления о профессии
***Шәүкәт Биктимеров.*** Заманында театрны тоткан кеше
***Нәҗибә Ихсанова.*** Фуад абый
***Наил Дунаев.*** Фуад абыйга хөрмәтем бик зур
***Әнвәр Гобәйдуллин.*** «Мин Фуад абыйның сәләтенә гашыйк кеше идем...»
***Рауза Хәйретдинова.*** Онытылмас шәхес, яки Зур талант иясе
***Асия Галиева.*** Халык артисты
***Фирдәвес Хәйруллина.*** Фуад абыйның Марзушы
Матбугат битләреннән
***Хәким Сәлимҗанов.*** Тынгысыз йөрәк
***Ильтани Илялова.*** Если бы он рассказал о себе.
Плечо товарища
СССР Верховный Советы Президиумы Указы
Котлыйбыз!
***Разил Вәлиев.*** Балачактан килгән чәчәкләр
***Әхәт Гаффаров.*** Мәңгелек ут
Дорогой Фуад Ибрагимович!
***Хәйдәр Гайнетдинов.*** Яшьлек булып кайта
***Назыйм Ханзафаров.*** Кояшлы күңел
***Флорид Әгъзәмов.*** Фуад аганы белмәскә соң!
Күрәзәче
***Ильтани Илялова.*** Смысл его жизни
***Р.Элин (Рустем Халитов).*** Талант, отданный людям
Фуад Ибраһимович Халитов
Күмүне оештыру комиссиясеннән
Фуад Халитов уйнаган рольләрнең исемлеге